ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 2 (361)
ФЕВРАЛЬ 2022

200 ПРОЦЕНТ КҮРҮ НИ ӨЧЕН КИРӘК?

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Ксения Сёмина,
Луиза Шарова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: «Корд» офтальмология клиникасы баш табибы
Антон Демидов. Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О-0334
Басарга кул куелды: 11.02.2022
Басмадан чыкты: 17.02.2022

Коммерция директоры: Рашит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7 9600 487 900

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ФЕВРАЛЬ ПРОФЕССИОНАЛЛАРЫ

Игътибар иткәнегез бармы: һөнәри бәйрәмнәрнең күбесе елның иң кыска ае – февральдә икән. «Татарстан» шулай дип тапты. Һәм бөтен бәйрәм итүчеләрне онлайн-конференциягә җыеп, алардан үз һөнәрләре турында барысын да сорашты – хыялланган профессияләре, бөтенләй уйламаган-хыялланмаганнары хакында. Әңгәмәдә гаять кызыклы нәрсәләр ачыкланды. Мәсәлән:

- барменнар өчен иң яхшы мәктәп – тормыш мәктәбе, һәм нәкъ менә шуңа күрә дә алар университетлар тәмамламый һәм үз һөнәрләренә беркайда да укымый. Әгәр, әлбәттә, шеф-бармен булырга хыялланмаган булсалар (Халыкара барменнар көне – 6 февраль);
- хәрби топограф эшендә кечкенә генә хата да эштән куылу белән яный (Хәрби топографлар көне – 8 февраль);
- очучы самолёты белән исәнләшә һәм очыш алдыннан кырынмый (Гражданлык авиациясе хезмәткәрләре көне – 9 февраль);
- саран стоматологны яхшы хезмәт хакы белән кызыктырып булмый (Халыкара стоматологлар көне – 9 февраль);
- дипломатларга «климат шартлары өчен» махсус өстәмә акчалар түлиләр (Дипломатия хезмәткәрләре көне – 10 февраль);
- таныштыру агентлыклары хезмәткәрләре, кияүләрне баетып, кәләшләрне матурайтып, ялгыз кешеләрнең мөмкинлекләрен киңәйтә (Халыкара таныштыру агентлыклары көне – 12 февраль);
- тәрәзәләрне яхшы юа белүче хатын-кызларны пыяла юарга алмыйлар (Пыяла юучылар көне – 26 февраль).

Ә инде бәйрәмнәре февраль аена сыймаган һөнәр ияләренең серләре турында «Татарстан»ның бүгенге санында укыгыз. Һәм шунысын да онытмагыз: иң яхшы һөнәрләр үзегез туган, язмышыгызны тапкан урын – Татарстанда!

Сезнең профессиональ редакциягез

Редакция советы:
ӘЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

КАЗАН КӘЛӘШЕ

Гүзәл Услада белән Меньшиков арасында бәхетле очрашу Санкт-Петербургта була. Алар арасында мәхәббәт бер күрүдән кабына. Бу пар 28 ел бергә яши, дөньяга 16 аю баласы китерә. Шунысын да әйтергә кирәк: Услада ике тапкыр икешәр аю баласы, бер тапкыр өчәрне таба. Гиннесслар китабына кертерлек кызыклы факт: әлеге ак аюлар гаиләсе Арктикада түгел, Санкт-Петербург шәһәре зоопаркында көн күргән. Герой ана аю исә Казан зоопаркында туган. Услада бер ел элек җан тәслим кыла – аңа 34 яшь була (кеше гомеренә күчерсәк – 105 яшь). Ә Казан аюының балалары бүгенге көндә Австралия, Кытай, Корея, Чехия, Япония һәм Россия зоопаркларында яши.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. **Фаразлар тормышка аша. Яисә ашмый**
20 ел элек нинди һөнәрләргә ихтыяҗ булган

8. **Ясалма интеллект йогынтысы**
Хезмәт базарыннан кемне кысрыклап чыгарачаклар

12. **Юкка чыга баручы һөнәрләр**
Кем гаепсездән гаепле булачак

14. **Яңа һөнәрләр**
Пилотсыз очкычлар белән кем идарә итә

18. **Президент, хоккей йолдызы, җырчы...**
Безнең кумирлар кем булырга хыялланган һәм кем булган

24. **Татарстан кораблары диңгезләрне гизә**
Ни өчен суасты корабында «Ак Барс» өчен җан аталар

игелекле эшләр

34. **Киләчәк диагностикасы**
Роботлар рентген сурәтләрендә COVIDны ничек күрә

40. **Яшьлек һәм борынгылыкның мөлаемлеге**
Татарстан ни рәвешле туристлык рейтингының беренче унлыгына эләккән

44. **Туган як манзарасы**
Кышкы һәм җәйге Югары Ослан

52. **Аш-су**
Ни өчен Менделеевск прокуроры Кукмараны сагына

58. **Тормыш линиясе**
Марат Кәбиров нигә фантастик әсәрләр язмый

62. **Ватанны саклаучылар көне**
Әти сүзе

мәңгелек кыйммәтләр

66. **Иман нуры**
Ислам ни рәвешле җирле уңай традицияләрне үзенә сеңдергән

70. **Тарихи сәхифә**
Галимҗан Ибраһимов татар тарихында нинди эз калдырган

74. **Безнең киштәдә**
Нинди фильм зур бәхәсләр уятты

78. **Татар авыллары**
100 еллык авыл ничек яши

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

13.01

Алексей Кудрин, Хисап палатасы җитәкчесе, – Гайдар форумында «Бюджет федерализмын ничек үстерергә?» дискуссиясе барышында:

– Бүген мин үзәк һәм төбәкләр арасында салым керемнәрен бүлү механизмын яңартуны илне үстерү һәм икътисадый үсеш тизлеген арттыру юнәлешендә иң төп мәсьәләләрнең берсе дип атар идем. Төбәкләрнең керемнәре генә түгел, вәкаләтләре дә булырга тиеш. Субъектлар тарафыннан башкарыла торган эшне төрле нормалар һәм регламентлар белән артык катлауландырырга кирәк түгел. Алтын урталыкны табу зарур. Көйләү сыгылмалырак булырга тиеш, төбәкләргә үз эшчәнлекләрен алып бару өчен ирекле ресурсларны күбрәк калдырырга кирәк.

26.01

Максуд Шадаев, РФ цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры, – видеоконференция режимында, ТР Министрлар Кабинеты һәм ТР Элемтә министрлыгы коллегиясенең уртак утырышы барышында:

– Татарстан социаль мөһим дәүләт хезмәтләрен цифрлы төрдә күрсәтү өчен аларны бердәм порталга чыгару эшен беренчеләрдән булып тәмамлады. Республикада әлеге эш яхшы темпларда барды. Татарстан беренчеләрдән булып хисап тапшырды, ләкин шуны аңларга кирәк: бу әле эшнең башы гына. Безнең алда барлык процессларны тулысынча үзгәртеп кору, хезмәт күрсәтү вакытын кыскарту бурычы тора. Без Татарстан җитәкчелегенең әлеге үзгәрешләрне тормышка ашыру белән кызыксынуын күрәбез. Татарстанда төбәк һәм муниципаль дәүләт хезмәтләрен оптимальләштерү буенча төбәк компетенцияләр үзәген оештырырга мөмкин дип саныйбыз. Республикада тупланган тәҗрибәне башка төбәкләргә таратырга кирәк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

17.01

Артемий ЛЕБЕДЕВ, дизайнер:

– Казан соңгы берничә ел эчендә бик нык үзгәрде һәм Мәскәүдән бер дә калышмый. Яңа елны каршы алган шәһәр үзгенең берничә урамын ут белән яктыртылган бизәкле арка-капкалар бизи. Ә «Черек күл» паркы миңа бөтенләй затлы-зиннәтле булып күренде, ул чын-чынлап Европа форматында эшләнгән. Каравы күңелле!

Фото: Олег Яковлев/РБК, lenta.ru, Global Look Press

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

акыллы гамәлләр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Соңгы 20 ел эчендә **КАЙСЫ** һөнәрләр юкка чыккан

Роботлар **КЕМНЕ** алыштыра алачак

Яңа һөнәрләргә белгечләрне **КАЙДАН** алырга

Хыяллар **НИЧЕК** тормышка аша

ХЫЯЛГА ТАБА БЕРЕНЧЕ АДЫМ





Якын киләчәктә нинди һөнәрләргә ихтыяҗ булачак, ә кайсыларына бөтенләй юкка чыгу куркынычы яный? Сорау алай ук җиңелләрдән түгел һәм шактый актуаль. Бигрәк тә тормышта үз юлын сайларга җыенучыларга яисә озак уйланганнан соң ниһаять эшчәнлек төрен алыштырырга җөрьәт итүчеләргә. Нәрсә дисәң дә, киләчәк хыялларның никадәр төгәл уйланылып бетүенә дә бәйле бит.

«Татарстан» әлеге мөһим сорауларга абруйлы экспертлар ярдәмендә җавап эзләргә булды. Кем белә, бәлки, безнең басмада дөнья күргән язмалар кем өчендер хыялга таба беренче адым булыр.

Фото: Ната Смирнова

ҺӨНӘРЕМНЕ ТАШЛАРГАМЫ?

Дөнья без уйлаганга караганда күпкә тизрәк үзгәрә. 2000 елда, мәсәлән, яңа фильм алыр өчен, күпләребез кибеткә бара иде, яңалыкларны телевизордан карап белдек, газета-журналлар укыдык. Халык фотоларны фотосалоннарда бастырып чыгара иде һәм өйдәге стационар телефоннан сөйләште.
Нинди һөнәр ияләренә ул вакытта якты киләчәк фаразладылар, ә кемгә эшен алыштырырга киңәш иттеләр? Белгечләр фаразының барысы да тормышка аштымы соң?

ДӨНЬЯ ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДА ВАЗГЫЯТЬ

2000 елда дөньяда ниләр булып ятканын искә төшерик. Глобализация, сәяси интеграция, түләү системаларының унификациясе процесслары бик тиз үсә бара... Бөтен дөньяда кулланучылар товар һәм хезмәтләрне почта, каталоглар һәм интернет аша сатып алу мөмкинлеге ала. Хезмәт базарында исә үз чиратында беренчелекне менеджерлар яулый. Гади менеджерлар гына түгел, ә маркетинг буенча менеджерлар. Икенче урында – сату менеджерлары.

Программистлар, система администраторлары, компьютер куркынычсызлыгы буенча белгечләр, веб-дизайнерларга ихтыяҗ шактый зур булды. Юристлар һәм табиблар да күп кирәк иде.

Сәнәгать җитештерүенең алга таба үсешенә зур өметләр баглап, Россия халкы президент сайлауларының нәтиҗәләрен көтте. Шуңа күрә базарда инженер белгечлекләре белән кызыксыну сизелде. Кадрлар агентлыкларының барысы да диярлек инженер-технологларга, фән белән турыдан-туры бәйле тармакларда, катлаулы җиһазларны көйләү һәм файдалану өлкәсендә эшләячәк белгечләргә ихтыяҗ артуын фаразлады.

КЕМГӘ ӨМЕТЛЕ КИЛӘЧӘК ВӘГЪДӘ ИТЕЛДЕ?

Әлбәттә, тәҗрибәле идарәчеләргә һәм администраторларга, универсаль сатучыларга,

Фото: tv360.ru

киң профильле һәм салым өлкәсен яхшы белгән бухгалтерларга. Аналитикларга, финанс менеджерларына һәм финанс директорларына. Предприятиеләрнең нәтиҗәлелеген бәяләп, аларны финанслар ягыннан савыктыру чараларын күрә алачак, җитештерү өлкәсендә эш тәҗрибәсе булган финанс белгечләренә. Компьютер технологияләре өлкәсендә маркетологларга һәм белгечләргә.

Ә КЕМНӘР «ЛАЕКЛЫ ЯЛ»ГА ОЗАТЫЛДЫ?

Белгечләр фикеренчә, тегүче, журналист, логист, туристлык агенты, лектор, маши-

нист, нотариус, копирайтер, китапханәче, юл-патруль хезмәте инспекторы, почтальон, курьер һөнәрләре юкка чыгарга тиеш иде инде. Исемлектә дистәләгән һөнәр. Тик менә курьер һөнәре белән шулкадәр ялгышырга кирәк бит! Бүген ул – иң кирәкле һөнәр ияседер, мөгаен. Т

ЮККА ЧЫККАННАРЫ

- Театр киоскында сатучы
- Өй телефоннарын ремонтлау остасы
- Фото ясау һәм түләүләр кабул итү кибетендә сатучы
- Видеопрокат һәм музыка кибете консультанты
- Машинистка
- Линотипист-җыючы
- Телефончы, телеграфчы
- Стенографчы

РОБОТЛАР БИК КАТЫ ЭШЛИ! АЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ – КЕШЕ ДӘ

Фотолар Иннополис Университетыннан алынды

Ольга Туманская

Хәтерлисезме, робот Электроник маҗаралары турында совет фильмындагы Серёжа Сыроежкин бөтен мәшәкатьләр турында онытырга мәҗбүр итәчәк прогресс турында җырлый. Кырык елдан артык вакыт үткән инде, ә без һаман элеккегечә – кул белән эшлибез. Болай озак дәвам итәрме? Якын киләчәктә ясалма интеллект хезмәт базарыннан нинди һөнәрләрне кысрыклап чыгарыр, ә кайсыларына, киресенчә, ихтыяҗ артыр?

– Әйдәгез карыйк әле, безнең дрон нихәл икән анда, – Антон бармагы белән тачпадка төртә. Монитор экранында кошлар очу биеклегеннән төшерелгән видео пәйда була. Бөтерелеп өскә күтәрелгән төтен эченнән вулкан авызы күренә.

– Менә видеосы бар, экспертлар фикерләре дә күренә. Ә безнең хисләр дизайнеры кайда соң?

– Менә, бөтен тоемлаулар чын булсын өчен, көек-корым һәм көл исләрен эшләп бетереп утыра идем! – дип җаваплый чандыр гына бер егет...

Ворлдскиллсның «Яшь профессионаллар» берлеге һәм кайбер зур компанияләр белән бергә Стратегик инициативалар агентлыгы (СИА) тарафыннан әзерләнгән Яңа һөнәрләр атласы 3.0 нең соңгы версиясендә киләчәк редакциясе якынча шулай тасвирлана. Сүз уңаеннан,

Антон – контент агрегаторы редакторы. Ул үзе тапшырган бирем буенча кеше һәм дроннар гына түгел, шулай ук бот һәм нейрочелтәрләр җибәргән мәкалә һәм видеолардан хәбәрләр лентасын формалаштыра. Аның коллегасы – хисләр дизайнерының бурычы исә – контенттан файдаланучыларның төрле сизү органнарына ничек тәэсир итү турында кайгырту. Шул исәптән картриджлардагы төрле исләрне кушарга сәләтле принтерга охшаган аппарат – ароматранслятор аша да. Көек-корым һәм көл исен исни-исни вулкан турында укып утыру бик кызык бит, әйеме? Футурологлар, тиздән болар барысы да бик гадәтигә әйләнәчәк, дип ышандырырга тырыша.

Атлас башында атаклы язучы-фантаст Айзек Азимовның сүзләре китерелә: «Хәзерге вакыт – нәкъ менә бүгенгенең безнең күз алдында киләчәккә әйләнә торган чагы». Ләкин минем кичәге көнем искә төшә. Төгәлрәге – 2016 ел, ул чакта мин редакция кушуы буенча Әлмәт торба заводына репортаж язарга киттем.

Анда мине шаккатырган иң беренче нәрсә гаҗәеп чисталык һәм тәртип булды. Махсус костюм кигән хезмәткәрләр идарә пультында утыра, алар эшче һөнәрен башкаручыларга караганда күбрәк офиста утыручыларны хәтерләтә. Әзер торбаларны төрү операциясе дә кешенең минималь дәрәҗәдә катнашуын күз уңында тота. Әйе, дүртенче сәнәгать революциясе инде башланды, әмма аның нәтиҗәләрен якынча 2025 елларда гына яхшылап сизә башлаячакбыз, дип саный СИА экспертлары.

Технологияләрнең кушылуы, тере табигать, физик процесслар һәм «цифра» арасында чикләрнең юылуы җитештерүнең төп үсеш тенденцияләре булачак. Әлмәткә баргач, без физика һәм исәпләү ресурсларын кушкан нәкъ менә шул «киберфизика системалары»ның тәүге үрнәкләрен күрдек. Киләчәктә алар сәнәгатьнең «әйберләр интернетына» берләшәчәк һәм, бер-берсе белән бәйләнеп кенә калмыйча, шулай ук укый-өйрәнә һәм үзләреннән-үзләре җайлаша да алачак. Эш урынының баетылган виртуаль чынбарлыгы хезмәткәрләргә булышачак һәм хәтта кайбер проблемаларны хәл итүдә катнашачак. Безнең җитештерү эшләренең яңа форматы шундый булачак. Сүз уңаеннан, AR-технологияләрдән Boeing, Audi, BMW, Boch, Hyundai заводларында файдаланалар инде.

Болар барысы да, әлбәттә, хезмәт базарына яңа таләпләр куя һәм яңа профессияләргә ихтыяҗ тудыра. Бәлки, бик тиздән интернет-рекрутмент сайтларында сәнәгать роботы операторына гына түгел, тулы бер предприятиенең цифрлы моделе белән идарә итәргә тиешле цифрлы модельләштерү инженеры яисә төрле машина-роботлар, станцияләр, смартфоннар белән ерактан торып эш итә белүче, виртуаль һәм баетылган чынбарлык интерфейсларында эшләүче белгеч – киберсистема диспетчеры кебек һөнәрләргә вакансияләр пәйда булыр.

«Виртуаль» һөнәрләр барлык тармакларда диярлек барлыкка киләчәк. Мода өлкәсеннән мисал – техностилист, ул киемне төрле максатлар куелган гаджетлар белән тулыландырачак. Әйтик, сез моңа ничек карыйсыз: парлы итеп тегелгән «кочаклашу футболкасына» беркетелгән махсус тапшыргычлар аның «игезәк» сыңарын кигән кешегә синең виртуаль кагылуыңны тоярга мөмкинлек тудыра. Яисә, әйдәгез, туристлык индустриясенә күз салыйк: анда тиздән территорияләрнең баетылган чынбарлык дизайнерлары таләп ителәчәк. Нәкъ менә шундый белгеч Кызыл мәйданны карап йөргәндә сезне Явыз Иван чорына яисә мода, дизайн һ.б. өлкәләрдә гаять зур яңалыклар алып килгән алтмышынчы еллар чорына «кертәчәк».

Хәер, цифрлаштыру – бүгенге көндә киләчәкнең «карьера базарын» формалаштыруга йогынты ясаучы бердәнбер тренд түгел. Мондый



«Из машины» фильмыннан кадр.

тенденцияләр күп. Мәсәлән, якынлашып килгән глобаль экологик һәлакәт куркынычы виртуаль түгел, ул реаль чынбарлыкка якый. Шул ук мода индустриясендә материалларны белгән-аңлаган кием рециклингы белгечләренә инде ихтыяҗ бар. Алар, иске киемнәрне эшкәртүгә җибәреп, аларны икенче мәртәбә кулланышка кертүне җайларга тиеш. Иң кәттә дизайнерлар, әйтик, үз коллекцияләрен булдыруда океанда җыелган пластик яисә төзелеш сәнәгате калдыкларын эшкәртүдән ясалган материаллар кулланылуы турында зур горурлык белән хәбәр итәчәк. Предприятиеләрдә һәм шәһәр хакимиятләрендә калдыксыз җитештерүне һәм чүпчарны дөрес файдалануны көйли алырлык zero waste* менеджерларына ихтыяҗ зур булачак.

ЯҢА КИЛГӘНГӘ КЕМ?

«Ресепшен артында сөйкемле генә бер кыз басып тора… Юк, туктагыз! Кыз түгел, андроид икән. Артык ак чырай һәм киң ачылган аксыл-шәмәхә күзләр, дүрт кулы берьюлы ике клавиатурага баса…»

Әйе, роботлар безнең тормышка ныклап кереп бара, дип саный СИА футурологлары. Иннополис Университетында эшләгән коллегалары да шулай дип уйлый. Мәсәлән, **Иннополис Университетының компьютер фәннәре факультеты деканы Джианкарло Суччи,** мануаль, ягъни кул хезмәтенә бәйле һөнәрләр шактый тиздән юкка чыгачак, дип саный.

– Әйе, мин күрәзәче түгел, ләкин без инде бүген үк шулай фаразларга мөмкинлек бирә торган роботлар ясыйбыз. Мәсәлән, миңа катлаулы ризыклар – пилмән, равиоли, тәмле тортлар пешерү ошый, әмма бу артык күп вакыт таләп итә. Киләчәктә мондый эшләрнең 99 проценты роботлаштырылачак, дип уйлыйм.

Сез дөрес аңладыгыз, сүз гадәти, әчпошыргыч эшләр яки куркынычка бәйле белгечлекләр турында гына түгел, югары квалификация таләп итүче һөнәрләр турында да бара! Сүз уңаеннан, беренче чиратта роботлаштыру транспорт өлкәсенә, шулай ук медицинага кагылачак. Робот-хирурглар, робот-офтальмологлар, робот-стоматологлар пәйда булачак көннәр инде ерак түгел, дип саный Джианкарло. Алай гына да түгел, бүген моңа охшаш җайланмалар инде бар – әлегә көндәлек тормышта түгел, лабораторияләрдә генә.

Дөньяда өлкәннәрне тәрбияләп-карап торучы роботлар һәм анализ нәтиҗәләрен дөресрәк, төгәлрәк күрсәтүче цифрлы лаборантларны тест рәвешендә сынаулар инде бара… Табиб булу канына сеңгән кешеләр нишләр? СИА экспертлары тынычландырырга ашыга: алар өчен дә эш җитәрлек булачак. Дөрес, табиблык төшенчәсенең мәгънәсен башкачарак аңларга туры киләчәк, чөнки асылда табиб күп нәрсәләрдә медицина программистына әйләнәчәк – диагностика технологияләренең үсеше һәм дистанцион медицинага йөз тоту шуны таләп итә.

Әйтик, мәсәлән, медицина роботлары операторы яисә киберпротез һәм имплантатларны эшләүче кебек белгечлекләргә ихтыяҗ зур булачак. Бирелгән параметрлар буенча, шул исәптән нәселдән килә торган авыруларны кисәтү өчен, геном программалаштырырга сәләтле белгеч – ИТ-генетик яисә диагностика җайланмалары биргән мәгълүматны эшкәртү нигезендә киңәшләрен һәм бәяләмәләрен бирүче генетика консультанты таләп ителәчәк.

Сүз уңаеннан, роботлар табибларга гына «янамый». Алар – һич көтелмәгән хәл! – хәтта менеджмент позицияләренә кагылырга да «омтыла».

– Якын киләчәктә акыллы гамәлләр – бүген кеше катнашуын таләп иткән эшләрне башкарырга сәләтле роботлар күбрәк пәйда булыр, дип уйлыйм, әйтик, җитәкче эшчәнлегендә, – дип аңлата Джианкарло Суччи. – Юк, сүз, әлбәттә, топ-менеджерлар турында бармый, әмма кайбер очракларда урта буын җитәкчеләрен робот алыштыра алачак. Һәм моның үз уңайлыклары бар! Алар һәрвакыт «салкын акыл» белән эш итә. Өстәвенә, кул астында эшләүчеләренә кычкырмый, алардан ачуын алмый, аның сөйгән-сөймәгәннәре юк… Боларның барысын да оештыру «сәләтләре» белән бергә программага гына кертергә кирәк. Без, программистлар, мондый программаларны эшләргә яратабыз, һәм безнең университетта хәзерге вакытта шуңа охшаш проект эшләнә.

Сез аңлагансыздыр инде, роботлар тормышыбызның барлык өлкәләренә үтеп керү сәбәпле, киләчәктә иң зур ихтыяҗ робот техникасы һәм роботлар программалаштыру белгечлекләренә булачак. Һәм тагын – роботлар базарында брокер эше. Әлеге белгеч сезнең конкрет бурычыгыз буенча робот табарга булышачак. Әгәр инде андый робот юк икән, аны эшләү өчен техник бирем ясарга тиеш.

БАРЫСЫ ДА ҮЛӘЧӘК, Ә МИН КАЛАМ

Илдә беренче тулысынча роботлаштырылган KRAVT Innopolis отеле Россиянең иң инновацияле шәһәренә килгән кунакларны инде киләсе елга ук шаккатырырга планлаштыра. Рецепциядә, номерларда һәм ресторанда кунакларга тавышлы голографик ярдәмче хезмәт күрсәтәчәк. Куркынычсызлык өчен робот-полицейскийлар җавап бирәчәк, номерларны роботлар юачак, тәртипкә китерәчәк, заказларны робот-официантлар китерәчәк, кунакларга отельгә керү юлын дроннар күрсәтәчәк... Футуристик концепция кунакларны үзенең технологиялелегe белән генә түгел, яшәү хакы белән дә шаккатырып дип уйлый мондый отельне төзүчеләр, чөнки роботлар персоналга чыгымнарны шактыйга киметергә мөмкинлек бирәчәк.

«Тимер» һәм «цифра» белән ярышта без, кешеләргә, бары тик иҗади эшләр генә калыр төсле... Хәер, ясалма интеллект бу өлкәгә дә үтеп керде кебек. Хәтта «Игра престолов» сериалының «дөрес», ягъни мантыйкка ярашлы финалын да яза алды! Инде бүген табигый телдә текстны генерацияләү системасы эшләнгән, система теләсә кайсы бирелгән теманы дәвам итә һәм урыны-урыны белән кеше дәрәҗәсенә бик якын итеп ача. Якындагы берничә елда тагын да көчлерәк ясалма интеллект барлыкка киләчәк. Һәм аның белән бергә – «аларның» яңа текст һәм әсәрләрендә инде үлгән кешеләрне яңадан терелтү мөмкинлеге дә пәйда булачак.

Кешеләрнең түбән квалификацияле гадәти эшләрдән югары интеллектуаль, аналитик һөнәрләргә күчә баруы белем алуга бөтенләй башка мөнәсәбәтне таләп итәчәк, дип саный КФУ Социаль-фәлсәфи фәннәр институтының фән буенча директоры урынбасары, социологик фәннәр докторы Мария Ефлова.

– Бездә яңа тенденция барлыкка килде – гомер буе белем туплау. Инде бүген үк без үзебезнең студентларга аларның белгечлек түгел, компетенцияләр алырга килүен аңлатабыз. Ә алга таба алар әлеге компетенцияләрне куллана алырлык белгечлекләрнең шактый киң спектрын үзләштерәчәк. Әмма һөнәрләрнең даими рәвештә реструктурлашып торуы, ягъни кайберләренең юкка чыгуы, икенчеләренең барлыкка килүе аркасында, хәзер инде дүрт ел буе хисапчыга укып, алга таба гомер буе әлеге эшеңнән керем алу мөмкин булмаячак. Белем алуны даими рәвештә яңартып торырга туры киләчәк.

Киләчәктә хезмәт базарында пәйда булырга тиешле тагын бер тенденция, Мария Ефлова сүзләренә караганда, «кешелеклелеккә кайту» булачак.

– Пандемия аркасында без бүген мәҗбүр булган дистанцион белем алу буенча социаль эксперимент шуны күрсәтте: кешелеклелек сыйфатлары бигрәк тә нык бәяләнгән белгечлекләр бар. Социологик тикшеренүләр, шул исәптән КФУ тарафыннан уздырылганнары да, студентларның күпчелегенең «йөзгә йөз очрашып» белем алу яклы булуын раслады. Аларга тере кеше – үзенчә аңлатучы, эмоцияләрен бирүче эксперт җитми.

Менә бит көтелмәгән борылыш. Димәк, киресенчә, кешеләр, мәсәлән, шеф-поварның авторлык ризыгы әзерләп, аның нәрсәләрдән ясалганын аңлатып, үзе кунакка китереп бирүе өчен акча түләргә әзер булачак вакытлар җитәргә тиеш.

– Безнең сайлау мөмкинлеге булыр дип уйлыйм мин, – дип төгәллек кертә сүзенә Мария Ефлова. – Стандарт, роботлаштырылган хезмәт өчен түләүдә экономияләргәме яисә аерым хезмәт күрсәткән өчен түләргәме? Әйе, безгә һаман да аралашу җылылыгы кирәк булачак. Җыештыручы тузан суырткыч – бу, бик әйбәт, әлбәттә, әмма кунакханәдә сине ачык чырайлы администратор каршы алса, аның белән сөйләшү, хисләреңне уртаклашу мөмкинлеге калса – минемчә, кешеләр мондый тере аралашу өчен, бигрәк тә киләчәктә, кыйбатрак түләргә әзер булачак.

– Минем бер таныш профессорым кайчандыр, 2000 елда без атнасына өч кенә көн эшләячәкбез, дия иде, – дип сөйли Джианкарло Суччи. – Ләкин урамда инде 2022 ел, ә без һаман әле, ким дигәндә дә, атнасына биш көн хезмәт куябыз. Әйе, инде бүген үк ясалма интеллект хәтта сезнең зәвыгызга туры килә торган сәнгать әсәрләре – музыка, картиналар тудырырга сәләтле, әмма алай да ниндидер алгарыш, ачыш ясый алмый әле. Димәк, без – кешеләрнең күбрәк кызыклы эшләре барлыкка киләчәк.

Хәер, социологлар кисәтә: ихтимал, нәкъ менә бу юлда кешегә яңа авырлыклар белән очрашырга туры килергә мөмкин. Һәрхәлдә, безнең илдә.

– Бүген без җәмгыятьнең икътисадый бүленешен күзәтәбез, – дип сөйли Мария Ефлова. – Соңгы 15-20 елда урта сыйныф эреп юкка чыкты диярлек. Халыкның зур өлеше, фәкыйрьлек чигендә булмаса да, аңа бик якын яши. Перспектива шундый: бөтенебезгә дә эксперт булырга бик ерак әле. Монысы төп-төгәл. Кулы белән эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән эшче сыйныф нишләр, нәрсә белән шөгыльләнер? Әлегә бу сорауга җавап бирү бик кыен. Вакыт күрсәтер.

* Zero waste – ноль калдык (инглиз теленнән тәрҗемә).



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА БЕРАЗ ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕЛӘР

Әлеге язмабызда «Во всем виноват стрелочник» дигән мәгълүм әйтемдәге һәрвакыт һәм һәрнәрсәдә гаепле юл күчерүчеләрнең хәзер квалификациясен үзгәртүе хакында сөйләшәбез. Төгәлрәге, башка һөнәр ияләренең юл күчерүчегә әйләнүе турында фикер йөртәбез.

Алсу Троицкая

КЕШЕСЕЗ БУЛМЫЙ ӘЛЕ

– Идел буеннан Тамань ярымутравына кадәр бик мөһим тимер юл магистрале тулы куәтенә эшли башлады, – дип дәртләнеп сөйли журналист үзәк федераль телеканаллардан берсендә. – Краснодар краендагы участокта тарая торган урын юкка чыкты... 94 юл күчерү җайланмасы монтажланды. Хәрәкәт белән идарә итү тулысынча диярлек автоматлаштырылды...

Репортаж станциягә күчә, анда кизү торучының галәмәт зур җиһазлары урынында хәзер заманча компьютер системасы тора, станциядә кизү торучы исә тимер юл укларын шул техника ярдәмендә ничек җиңел генә күчерүен күрсәтә.

Сүз дә юк, шаккатыра! Тик иртән тагын гаҗәпкә калырга туры килә: Казан янындагы тимер юл станциясендә бер егет укларны кулдан күчереп йөри. Юллар бихисап, һәм шуларның барысын да кулдан күчерергә кирәк! Классика! Димәк, юл күчерүче һөнәре бөтенләй юкка чыкмаган әле?

– Тимер юлда күп кенә белгечлекләрне яңа технологияләр кысрыклап чыгарды. Хәзер, чыннан да, дистәләрчә юл күчерүче эшен станциядәге кизү торучы бердәнбер кеше пульт артында утырган килеш башкара ала. Уклар үзләре беркая да китмәгән, әлбәттә, әмма алар белән идарә итү тулысынча диярлек автоматлаштырыл-

«ЮЛ КҮЧЕРҮЧЕ – ТИМЕР ЮЛДА УКЛАРНЫ КҮЧЕРҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮЧЕ ЭШЧЕ. МӘГЪЛҮМ БУЛГАНЧА, УК БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ӨЧЕН ЮЛ КҮЧЕРҮ ПРИВОДЫ КУЕЛА. Элек ул кул белән хәрәкәткә китерелгән һәм буй-буйлы ук яки турыпочмаклы фонарь кебек күрсәткечләр белән билгеләнгән. Әлеге җайланма белән шул постта кизү торучы – юл күчерүче идарә иткән».

Дмитрий Ушаковның 1935–1940 еллардагы аңлатмалы сүзлегеннән.

ган, – дип аңлата Самара дәүләт тимер юллары көллияте Казан филиалының 3 курс студенты **Глеб Топоров**. – Ихтимал, кечкенә станцияләрдә кулдан юл күчерүчеләр бардыр әле, әмма бездә инде юк диярлек. Мин хәзер поездлар урнаштыручы һөнәрен үзләштерәм. Нигездә вагоннарны бер юлдан икенчесенә күчерү эше белән идарә итәм. Әмма! Кирәк булганда мин укларны да күчерәм. Резервта яки вагоннарсыз локомотивта барганда, укның кая каравы шундук күренә. Һәм әгәр ул маршрут буенча карый икән, үтеп китәсең. Әгәр маршрут буенча булмаса, төшеп кулдан күчерәсең дә юлны дәвам итәсең...

Бу исә нигездә кышын була – кар яву һәм салкыннар аркасында. Кизү торучының пультыннан идарә ителә торган электрлаштырылган уклар туңа, кар белән каплана. Менә әле бер атна элек кенә көчле буран вакытында бөтен юллар кар белән капланды, һәм кизү торучы, эшчеләр юлларны кардан чистартканчы, укларны күчерә алмады. Кайвакыт исә уклар җимерелә. Бу очракта да кешедән башка төзәтеп булмый.

РОБОТ БЕЗНЕ АЛЫШТЫРМАЯЧАК

Укудан бушаган вакытында Глеб поездлар урнаштыручы һөнәрен үзләштерә.

– Ерак киләчәктәме, әллә инде бик якындамы бернинди машинист та кирәк булмаячак. Ихтимал, робот поездларны урнаштырыр, локомотив белән идарә итәр, – ди ул. – Вагоннарда җаваплы кешеләрне роботлар алыштырыр, уклар исә электр белән җылытылыр, вандаллыкка каршы система белән җиһазлар куелыр. Шулай да роботлар беркайчан да диярлек кешене тулысынча алыштырмаячак әле.

«КЫЗЫКЛЫ» ОЧРАКЛАРСЫЗ

Шәһәр яны электричкасы станциядә туктый. Пассажирлар ишектән чыга, ә анда –... платформа юк. Нишләргә? Кешеләр баскычтан җиргә сикереп төшәргә мәҗбүр була. Сикерешәләр, сүгенешәләр. Тагын юл күчерүче гаеплеме?

– Тимер юлда бөтен нәрсә бер-берсенә бәйле. Биредә мондый «кызыклы» очраклар булырга тиеш түгел. Берәр гадәттән тыш хәл килеп чыкса, бөтен кешегә эләгәчәк. Тимер юлда эш шулкадәр җаваплы ки, син үз коллегаларыңа 100 процентка ышанырга тиеш, – ди Глеб. – Сез, пассажирлар, билет сатучы кассирларны һәм вагондагы җаваплы кешеләрне генә күрәсез. Әмма биредә әле юлларны карап торучы, вагоннарны ремонтлаучы, локомотивлар йөртүчеләр дә күп... Һәркем үз эше өчен җаваплы. Димәк, без барыбыз да бераз гаепле булып чыга...

«ЮЛ КҮЧЕРҮЧЕ ГАЕПЛЕ» ӘЙТЕМЕНӘ КИЛГӘНДӘ ИСӘ, УЛ ИНДЕ КҮПТӘН ПӘЙДА БУЛГАН. Менә канатлы сүзләр һәм гыйбарәләр энциклопедия сүзлегеннән өземтә: «Россиядә тимер юл һәлакәтләрен тикшергәндә һәрвакыт юл күчерүче гаепле булып чыккан – ул йә укны вакытында күчермәгән, яисә кирәкмәгән вакытта үзгәрткән һ.б. Шунлыктан Думадагы оппозиция хөкүмәт уңышсызлыкларда гаепле дип игълан иткән түрәләрне (кагыйдә буларак, түбән чиндагы) «стрелочник» («гаепсездән гаепле» мәгънәсендә) дип йөртә башлаган».

Фото: Ксения Семина, ГТХМның ТР буенча баш идарәсе матбугат хезмәте

ШТУРВАЛМЫ? ПЛАНШЕТ!

Ксения Сёмина

Денис Морозов моннан өч ел элек әле рәсми рәвештә бөтенләй теркәлмәгән һөнәр иясе – пилотсыз очу аппараты операторы булып эшли.

Планшет экранында – өстән караганда күренгән агач ябалдашлары, елга юллары, ызаннар. Һәм менә кинәт кечкенә генә төсле тап пәйда була. Камера нәкъ аның өстендә туктап кала, аска төшә башлый. Тапның җирдә яткан кеше икәне ачыклана. Ул хәрәкәтләнә. Квадрокоптер операторы төймәгә баса да, дрон йөген ташлый. Анда – протеинлы батончик, фонарь, антисептиклар, яраны төзәтү һәм бәйләү өчен кирәкле препаратлар: берничә тәүлек элек урманда адашкан һәм, ихтимал, җәрәхәтләнгән кеше коткаручылар килеп җиткәнче үзенә бераз булса да ярдәм итә алачак.

– Аптечка үз урынында, – дип хәбәр итә оператор. Адашкан кешене эзләүче коткаручылар теркәлгән координаталар буенча ярдәмгә юнәлә.

Аптечка төшерү маневрын Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәгенең пилотсыз авиация системаларын (камера, тапшыргыч һәм башка җайланмалар куелган квадрокоптерлар шулай атала) куллану төркеме белгечләре әлегә өйрәнүләр вакытында гына эшләп караган, ә менә дрон ярдәмендә урмандагы кешене чынлап эзләгәннәр: адашкан пенсионер исән, ярдәм вакытлы күрсәтелгән.

КОТКАРУ БИЕКЛЕГЕ

Һавага квадрокоптер җибәрү һәм аның белән идарә итүнең берниндиди кыенлыгы юк кебек тоелса да, әлеге һөнәрнең нечкәлекләре шактый. Нәкъ менә һөнәрнең – хәзер пилотсыз очу аппаратлары операторларын яллый торган компанияләр алардан сертификат күрсәтүләрен таләп итә. Әлеге сертификатны алуы кыен түгел – мондый хезмәт күрсәтүгә лицензиясе булган оешмада кыска вакытлы курслар тәмамлау җитә. Әмма мондый квадрокоптерлар белән Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында, Росгвардиядә, армиядә эшләү өчен төплерәк белем кирәк булачак.

– Мин 2012 елда КАИ тәмамладым, диплом эшем пилотсыз аппаратлар белән идарә итүгә һәм мәгълүмат куркынычсызлыгына багышланган. Инде ул чакта ук бу юнәлешнең өметле булачагы аңлашыла иде. Дозиметрия, һаваның сыйфатын тикшерү, нефть һәм газүткәргеч торбаларны контрольдә тоту, чикне саклау... – пилотсыз очу аппаратларын куллану күп тармаклар өчен файдалы, – ди Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе эчке хезмәте өлкән лейтенанты Денис Морозов. Ул Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәгенең пилотсыз авиация системаларын куллану төркемен җитәкли. Үзәктә берничә пилотсыз очу аппараты, шул исәптән DJI Phantom 4 PRO квадрокоптеры һәм самолет тибындагы Supercam S350 һава судносы бар.

«Фантом» уенчыкны хәтерләтә. Әмма телекамера куелган бу «уенчык» сәгатенә 70 километр тизлек белән очарга, ярты километр биеклеккә күтәрелергә, 2 чакрым ара үтәргә, аннары кире кайтырга сәләтле. Чикләнгән территориядә нәрсәдер эзләү яки коткаручыларга барып җитүе кыен урыннарга аптечка китереп китү өчен бу рәхәтләнеп җитә. Моннан тыш, ретранслятор куелган «Фантом» кәрәзле элемтәсез урыннарда күчмә вышка булып та хезмәт итә ала.

Берничә сәгать буе эзләүне яки һавадан мониторинглауны Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре республика Эзләү-коткару хезмәтенең Supercam S350 аппараты ярдәмендә башкара. Әлеге квадрокоптер һавада 4,5 сәгать буе тора һәм 240 километрга кадәр ара үтә ала. Аңа шулай ук камералар яки гадәттән тыш хәл зонасындагы кешеләрне кисәтү өчен репродуктор беркетеп куеп була. Supercam ярдәмендә урманда адашкан кешеләрне яки бозда агып китүчеләрне эзләп була, республикабыз өчен бу бик кирәкле ярдәм – Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кисәтүләренә карамастан, балыкчылар язгы куркыныч боз өстенә чыгуларын һаман туктатмый.

XXI ГАСЫР КАРТОГРАФИЯСЕ

Әмма республика сулыклары һәм аларга якын урнашкан торак пунктлар Денис Морозов һәм аның коллегалары өчен башка куркыныч – язгы су басулардан саклау җәһәтеннән зур кызыксыну уята. Татарстан территориясендә кечкенә елгалар күп, карлы кышларда аларда зур боз таулары хасил була. Язгы ташу башлангач, елгалар ярыннан чыга да, авыл хуҗалыгы җирләрен һәм торак пунктларны су баса.

Ел саен шартлатучылар аеруча куркыныч урыннарга юнәлә һәм боз тауларын шартлата. Былтырдан бирле аларга бу эшләрендә квадрокоптерлар булыша.

– Без пилотсыз очкычны җибәрәбез дә 150 метр биеклектән боз күп өелгән урыннарны ачыклыйбыз. 50 метр биеклектән шартлаткыч куеласы урынның координаталарын тапшыра һәм аның янына барып җитүнең иң кыска юлын исәпли алабыз, – ди Денис Морозов. – Белгеч шартлаткыч куя, мин дронны җибәрәм дә, әлеге зонада кешеләр булмавын тикшерү өчен, территорияне әйләнеп чы-

1

Республика сулыклары һәм аларга якын урнашкан торак пунктлар Денис Морозов һәм аның коллегалары өчен башка куркыныч – язгы су басулардан саклау җәһәтеннән зур кызыксыну уята.

2

«Фантом» уенчыкны хәтерләтә. Әмма телекамера куелган бу «уенчык» сәгатенә 70 километр тизлек белән очарга, ярты километр биеклеккә күтәрелергә, 2 чакрым ара үтәргә, аннары кире кайтырга сәләтле.

ПОДВИЖНЫЙ ПУНКТ УПРАВЛЕНИЯ

гам. Боз шуннан соң гына шартлатыла. Элек 3-4 көн таләп ителгән эш пилотсыз очкыч ярдәмендә бер көн эчендә башкарыла.

Су басудан саклау белән бергә, әлеге проектның гади халыкка башка файдасы да бар. Ташу җәелгән зоналарга дроннар җибәреп, Денис Морозов төркеме җирлекнең меңләгән фотосурәттән торган архивын булдырган. Алар нигезендә ел саен су баса торган кишәрлекләрнең 20 дән артык ортофотопланы эшләнгән. Асылда бу – язгы ташуның төрле сценарийларын исәпләп карап була торган 3D-модель. Хәзер бозның тулысынча эреп бетүеннән берничә атна алдан ук шактый төгәл фаразлар ясарга була. Планнары зурдан: күперләр, кичүләр, юлларны һәм башка объектларны да кертеп, республикадагы су басу ихтималы булган барлык кишәрлекләрнең моделен төзү. Татарстандагы Росреестр белән уртак проектны да эшләп бетерү карала. Ул чакта, мәсәлән, кеше йорт, җир кишәрлеге һәм башка мөлкәтне сатып алганчы әлеге объектның нинди һава шартларында су астында калу ихтималын ачыклый алачак. Тыелган зонада йорт салырга яратучылар үз гамәлләре өчен җаваплылыкны моннан соң дәүләткә сылтый алмаячак инде.

КВАДРОКОПТЕР ӨЧЕН КАГЫЙДӘЛӘР

Бүген Татарстанда пилотсыз очкыч операторы һөнәрен КАИда гына түгел, кайбер көллиятләрдә, мәсәлән, Лаеш һәм Тәтеш районнарында да алып була. Һөнәрнең популярлыгы артуга квадрокоптерлар санының һаман ишәюе дә булыша. Россия законнары 30 килограммга кадәр авырлыктагы дроннардан шәхси файдалануны рөхсәт итә. Әгәр массасы 250 граммнан артыграк икән, пилотсыз аппаратны Росавиациянең Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә теркәү зарур (бу бушлай эшләнә). Очу аппаратларының бәяләре дә артык кыйбат түгел. Тик нәкъ менә шул җиңел теркәлү һәм җиңел сатып алу мөмкинлеге Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәге кебек эксплуантатларга шактый проблема тудыра да инде.

4

– Былтыр җәй без Казан янындагы бер бистәдә газ януын тикшерергә киттек. Инде караңгы төшкәнгә, территорияне карау өчен дроныбызны җибәрдек. Ә анда аппарат бар икән инде – бер журналист төшерә булып чыкты. Сигнал утлары кабызмаган иде. Килеп бәрелмәс өчен, безгә шактый тырышырга туры килде, – дип сөйли Денис Морозов.

Рөхсәт ителгән шәхси квадрокоптерны оператор күреп торырлык 150 метр биеклеккә һәм тәүлекнең якты вакытында гына күккә күтәрергә ярый. Башка шартларда очышны, шулай ук кайбер шәһәрләр, шул исәптән Казан өстеннән очуны да берничә оешмада килештерергә кирәк. Әмма күп кеше болай эшләми.

– Әлегә дрон хуҗалары Юл хәрәкәте кагыйдәләрен санларга өйрәнмәгән. Әмма эш бара, норматив документлар төзелә, – ди Денис Морозов.

Аның өчен хәзер – иң кызык вакыт. Ул пилотсыз авиация системалары белән аралашу даирәсен формалаштыруның башында тора. Денис һәм аның коллегалары иң яхшы чишелешләрне эзли һәм таба, киләчәк тармагының нигезен тәшкил итәчәк тәҗрибә туплый ала.

3

Ярдәмгә мохтаҗ кешегә аптечка төшерү маневрын төркем белгечләре әлегә өйрәнүләр вакытында гына эшләп караган.

4

Берничә сәгать буе эзләүне яки һавадан мониторинглауны ГТХМ хезмәткәрләре республика Эзләү-коткару хезмәтенең Supercam S350 аппараты ярдәмендә башкара. Әлеге квадрокоптер һавада 4,5 сәгать буе тора һәм 240 километрга кадәр ара үтә ала.

НӘРСӘ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНГАН? НӘРСӘДӘН БАШЛАГАН? КЕМ БУЛГАН?

Бала чакта һәркем киләчәктә кемдер булырга хыяллана: кемдер очучы, кемдер космонавт, кемдер трамвай йөртүче. «Татарстан» республиканың кайбер күренекле кешеләренең бала чакларында **кем булырга хыялланауын**, хезмәт юлын **ничек башлауларын** һәм бүген **кем булып эшләүләрен** карарга тәкъдим итә.

Алексей Потапов, Богдан Кузьмин, Катя Семисотова рәсемнәре

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ

Техника ярата идем, шуңа күрә инженер булырга **хыялландым**

Хезмәт юлымны Саба районы «Авыл хуҗалыгы техникасы» берләшмәсендә диагностика инженеры **вазыйфасыннан башладым**

Татарстан Республикасы Президенты **булдым**

НАИЛ МӘГАНОВ

Нефтьче булырга **хыялландым**

«Елховнефть» нефть-газ табу идарәсендә скважиналарны тикшерү операторы **вазыйфасыннан башладым**

«Татнефть» ГАҖ генераль директоры **булдым**

ЗИЛӘ ВӘЛИЕВА

Очучы булырга **хыялландым**

Хезмәт юлымны журналист һөнәреннән **башладым**

ТР Иҗтимагый палатасы рәисе **булдым**

ДИНӘ ГАРИПОВА

Табиб, актриса, җырчы һәм хәтта тегүче булырга **хыялландым**

6 яшьтән вокал белән **шөгыльләндем**

Популяр Россия җырчысы булуга **ирештем**

ГҮЗӘЛ ЯХИНА

Киноларга сценарийлар язарга **хыялландым**

Маркетология, PR һәм реклама өлкәсендә **эшли башладым**

Язучы **булдым**

ТИМУР
ӘХМӘРОВ

Хирург, самолетлар проектлаучы инженер булырга **хыялландым**

Программалы тәэмин ителешне уйлап табучы булып эшли **башладым**

«БАРС Груп» компаниясенең генераль директоры **булдым**



СЕРГЕЙ
ШӘКҮРОВ

Актёр булырга **хыялландым**

Хезмәт юлымны актёр буларак **башладым**

Актёр **булдым**

САЛАВАТ
ФӘТХЕТДИНОВ

Сөйләм жанры артисты булырга **хыялландым**

Хезмәт юлымны клуб мөдире буларак **башладым**

Эстрада җырчысы **булдым**

ДАНИС
ЗАРИПОВ

Спортчы булырга **хыялландым**

15 яшемдә беренче мәртәбә рәсми матчта **катнаштым**

Дүрт мәртәбә Гагарин Кубогы иясе булуга **ирештем**

ИРИНА
ВОЛЫНЕЦ

Адвокат, хирург яисә актриса булырга **хыялландым**

Хезмәт юлымны журналист буларак **башладым**

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил **булдым**

АК КӘГАЗЬДӘН БАШЛА

TeamSoft компаниясен оештыручы һәм бизнес-тренер Гүзәл Хисмәтуллина ничек тормышны өр-яңадан башлауга тәвәккәлләү һәм үзгәрешләрнең актив фазасын кузгатып җибәрү хакында фикерләре белән уртаклаша.

Киләчәк турында без нәрсә беләбез соң? Ул үзгәрүчән.

Үзебез яшәгән дөнья турында ниләр беләбез? Ул бик хәтәр-хәвефлегә, алдан фаразлап булмый торганга әйләнде.

Ата-аналар миннән киңәш сорый – киләчәктә кирәкле белгеч булу өчен, балаларына нинди һөнәр сайларга кирәк?

Ә мин белмим. Беркем дә белми. Әлбәттә, белгечләр фаразларга тырыша, әмма моны бер дә төгәл дип әйтеп булмый. Тәгаен шуны гына беләм: аларга акча эшләргә мөмкинлек бирә торганны сайлау мәслихәт. Чөнки безнең балалар үз гомерләрендә әллә ничә һөнәр алыштырачак әле. Аларга бөтен мөмкинлекләр тудырылган, һәм барысын да татып карыйсылары килә. Әгәр беренче һөнәрләре аларга акча эшләү мөмкинлеге тудырса, үзләренә ышанычлары да артачак: «мин булдырам», «мин акча эшли алам». Һәм үзләре нәрсә теләгәнне аңлаган вакытка моннан ничек файдаланырга кирәклеген дә беләчәкләр. Ә инде нәрсә теләгәннәрен хәзер үк беләләр икән, димәк:

– яхшылап тыңлагыз, сүз белән дә, күз карашы белән дә тәнкыйтьләмәгез;

– планын күрсәтүен сорагыз һәм, план сезне инандырса, инвестор булырга әзер икәнегезне әйтегез;

– һәм балага мөмкинлек бирегез. Тәнкыйтьләмәгез, бәяләмәгез.

Шуны тәгаен беләм: бүгенге ата-аналар буыны яшьләрне «бәяләп бетерми», чөнки беренче чиратта үзләренә бәя биреп җиткерми.

Яше 35 тән өлкәннәрнең консультациягә килгәч иң еш биргән соравы мондый: «Ничек тормышны өр-яңадан башларга тәвәккәлләргә, һөнәрне үзгәртергә, үз эшеңне башларга?»

1 нче адым. Һәм мин сорауга үзем дә сорау белән җавап кайтарам: «Әгәр син үзеңә 100% ышанган кеше булсаң, нишләр идең?» – дим. – Әйдә, шул очракта ничек буласын фаразлап карыйк. Сиңа моннан бер зыян да юк бит, күзалларга тырышыйк».

Һәм әлеге теләк (хыял) артында бернәрсә дә булмавы ачыклана, бу вакытта инде үткәннәргә генә таянырга туры килә.

Ә инде күз алдына китерсәгез, планыгыз пәйда була, нәрсәдән башларга кирәклеге ачыклана, әле бераз куркыныч булса да, юл бар, кая барасы, ниләр эшлисе анык билгеле инде.

2 нче адым. Үз бурычларыңа ревизия ясa: чынына һәм уйлап чыгарылганнарына.

Уйлап чыгарылганнары – гаеп хисе, бурычлылык хисе. Бу вакытта үзеңә яхшылап уйлап сайлау мөмкинлеге бирү мәслихәт.

Чыннары – үзеңә финанс тотрыклылыгы бирү: «Яшәргә/ипотекага ничек акча табарга?» – дигән сорауга җавап эзләү. Бер-бер хәл була калса, беренче вакытта очны-очка ялгар өчен миңа кимендә никадәр акча кирәк булачак, дип уйлану.

Мәсәлән, минем янга бер кыз килде, уңышка ирешкән җитәкче үзе, шул ук вакытта йога-тренер һөнәрен дә үзләштергән, ял көннәрендә йога дәресләре алып бара. Минимум турындагы сорауга – 30 мең, дип җавап бирде, хәзер 15 мең эшли. 30 мең сумны ничек һәм кайда эшләп табачагын хәл иттек тә, шундук чираттагы адымга күчтек.

3 нче адым. Китү кагыйдәсе. Сәбәп табу, ниндидер «исәп ноктасын» яки «уңай моментны» булдыру: хобби ярдәмендә 30 мең сум эшли башлагач; яки балам мәктәпне тәмамлагач; яисә ипотеканың 70% түләп бетергәч; йә «беренче вакытка» 200 мең сум акча туплагач кебек, мәсәлән. Сез инде бер аягыгыз белән гүя анда һәм киләсе адымны ясарга уңайлы мизгелне көтәсез. Һәрнәрсәнең үз вакыты.

4 нче адым. Үзгәрешләрнең актив фазасын эшләтеп җибәрү. Үзегезгә бөти сатып алыгыз яки татуировка ясатыгыз. Яңа эшегезгә конкрет вакыт билгеләгез, мәсәлән, көненә бер сәгать; социаль челтәрләрдә үзегез һәм яңа эшегез хакында языгыз, тормыш активлыгыгызны арттырыгыз, үзегезгә уйламый гамәл кылырга рөхсәт итегез. Үзегезгә ярдәм төркеме белән сөйләшегез: бу аек фикерле кеше, һәм ул гел сезнең яклы булсын. Мәсәлән, һәрнәрсә өчен борчылучы әниегез янына киңәш сорап барырга кирәкми, ул сезне яңа эштән баш тартырга үгетләячәген болай да беләсез бит. Тормышка җиңелрәк карый башлагыз.

5 нче адым. Эшкә керешегез. Инде хәзер үк. Яңа эшегезгә файда китерерлек нинди гамәлне хәзер үк кыла алуыгызны барлагыз. Яшәү рәвешен тулысынча үзгәртмичә генәниләр эшләп буласын планлаштырыгыз. Мәсәлән, безгә таныш йога-тренер коллегаларына бушлай дәресләр бирергә тәкъдим иткән, ә җитәкчесе исә: «Нигә бушлай, без сиңа моның өчен түләргә дә әзер», – дигән. Һәм проблема урынына тагын бер мөмкинлек туган. Тәвәккәлләгез!

Без барыбыз да куркабыз. Бу норма. Әмма син, үз куркуларыңны белеп, алга яки артка атларга кирәклеген үзең сайлыйсың.

Кеше үзе теләгәнчә яши. Димәк, тәвәккәлләргә кирәк!

Иллюстрация: Челин Санхуан Пикеро

ДИҢГЕЗЛӘРДӘ ТАТАРСТАН РУХЫ

Сафа Гәрәев

«Татарстан», «Казан», «Казанец», «Град Свияжск», «Зелёный Дол»... Йөрәккә якын, һәркемгә таныш атамалар. Нигә куштырнаклар эчендәме? Чөнки бу очракта сүз республика, аның башкаласы, шәһәрләре һәм халкы турында түгел, бәлки илне теләсә нинди дошманнан сакларга сәләтле куәтле корал – кораблар хакында бара. Әлеге кораблар – илнең горурлыгы. Һәм Татарстанның диңгез-океаннардагы бер кисәкчеге.

Фото: korabel.ru

«Казан» суасты атом ракета крейсерында Андрей әләме 2021 елның 7 маенда Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин катнашында күтәрелде. ХДФ башкомандующие Николай Евменов, хәрби-диңгез байрагын «Казан» командиры, беренче ранглы капитан Александр Бекетовка тапшыргандa, горурланып шуны искә төшерде: «Ясень-М» проекты крейсеры – илдәге ракета йөртүче иң заманча суасты корабы ул.

1
«Ясень-М» проектының «Казан» атом суасты ракета крейсеры – илнең ракета йөртүче иң заманча суасты корабы ул.

«КАЗАН» КӨЙМӘСЕ ОКЕАН ГИЗӘ

Безнең потенциаль дошман куып тота алмаслык тизйөрешле яңа суасты көймәсе дүртенче буын канатлы ракеталары белән җиһазландырылган. Ихтимал булган дошман да суасты көймәсенә югары бәя биргән. Америка Хәрби-диңгез тикшеренүләре үзәге эксперты Майкл Кофман «Казан» көймәсен «АКШ Хәрби-диңгез көчләренә кайчан да булса очрашырга туры килгән иң куәтле дошман корабы» дип атаган.

Иң куәтле көймәнең кают-компаниясендә меңьеллык Казан күренешләре белән хозурланырга һәм Татарстандагы иң популяр – «Ак Барс» хоккей, «УНИКС» баскетбол, «Зенит» волейбол, «Рубин» футбол командалары логотиплары төшерелгән спорт свитерларын киеп карарга була. Флот экипажында әлеге командаларның җанатарлары байтак. Хәер, спорт экипировкасы нәкъ менә алар сораганга крейсерга килеп эләккән дә инде.

Шефлары тырышкан. «Казан» күпмаксатлы суасты көймәсе экипажы белән Казан муниципалитеты арасында хезмәттәшлек итү һәм шефлык элемтәләре турында килешү гамәлдә. Диңгезче балаларының Татарстан шифаханәләрендә ял итүен, морякларның ТР башкаласына сәфәрен, шулай ук Казан яшь армиячеләре һәм ветераннарының Северодвинскига кунакка баруларын оештыру шул программа буенча башкарыла.

Шефлык – әллә ни күңелгә ятарлык сүз түгел. Тәгъләргә бар – дуслык. Әгәр сез майда, алмагачлар чәчәк атканда, Җиңү паркына килсәгез, экипаж һәм шәһәр дуслыгына мисалларны үз күзегез белән күрә аласыз. Биредә чәчәк атып утырган алмагачларның берсен Александр Бекетов, янәшәдәгесен шулай ук беренче ранглы капитан һәм шулай ук «Казан» АСК командиры Игорь Кравцов утырткан, бүген рубкасы Җиңү паркына куелган әлеге көймә 1970 еллардан 2004 елга кадәр хәрби хезмәттә булган.

Ә Казандагы 78 нче лицейда флотка – «Казан» атом суасты көймәсенә эләгү турында хыялланган малайлар укый. Моның нинди горурлык икәнен алар бер ел элек, Ватанны саклаучылар көне алдыннан каперанг Александр Бекетов үзе үткәргән батырлык дәресендә аңлаган. Аеруча үзсүзлеләре исә математика, физика һәм информатиканы тырышып өйрәнә – аларны яхшы белмәсәң, суперзаманча көймәгә эләгү турында хыялланма да. Бергәләшеп «Марш подводников» – экипаж җырының сүзләрен өйрәнәләр. Аны диңгезчеләр шефлыкка алган балалар өчен Казанда махсус иҗат иткәннәр.

«ЗЕЛЁНЫЙ ДОЛ» ТЕРРОРЧЫЛАРНЫ ӨРКЕТӘ

«Зелёный Дол» кече ракета корабы (КРК) «Серпухов» корабы белән бергә Сүриядәге мишеньгә төбәп аткач, 2016 елның 19 августында, бөтен дөньяга танылган. Меңнәрчә километр ара үтеп, канатлы ракеталар Дар-Таазза районында «Җәбхәт ән-Нусрә» төркеме террорчылары базасын һәм җитәкчелек пунктын, шулай ук Алеппо провинциясендә сугыш кирәк-яраклары заводын һәм зур корал складын юк иткән.

Яшел Үзәндә экипажның уңышына үзләренең казанышларыдай сөенгәннәр. Корабның каланың адашы булуы өчен генә дә түгел. «Зелёный Дол» корабы биредә, Татарстанда, үзләрендәге Горький исемендәге заводта төзелгән бит. Шефлар исә – шәһәр һәм район – каюта һәм кубрикларда хәрби вахтадан соң рәхәтләнеп ял итәрлек шартлар тудырган.

2015 елның җәендә «Зелёный Дол» корабын армиягә, тәгъләргә флотка, озату да бик җылы үткән. Заводта морякларга Габделхәмит хәзрәт һәм протоиерей Святослав үз фатихаларын биргән. Хакимият башлыгы Сергей Тыгин исә: «Корабны ничек атыйсың, ул шулай йөзеп тә китә...» – дип искәрткән һәм экипажга йөзгә кызыллык китермәскә кушкан. Кораб капитаны Владимир Дербетов данлыклы шәһәр атамасына тап төшермәслек хезмәт итәргә вәгъдә биргән.

2

«Зелёный Дол» кече ракета корабы Татарстанда, Горький исемендәге заводта җыелган.

3

«Казанец» көймәләр һөҗүменә каршы кече корабы флотта инде күптәннән хезмәт итә.

Өченче ранглы капитанның сүзләрен тикшереп карауга бер ел вакыт җиткән. 2015 елның декабрендә корабта Андрей әләме күтәрелгән, февральдә исә инде «Зелёный Дол» Урта диңгездә РФ ХДФ даими төркеме составында биремнәр үтәүгә керешкән... Анңары канатлы ракеталардан атып террорчылар юк ителгән, хәрби өйрәнүләр, йөрешләр булган. 2016 елда кораб, сигез ай коры җиргә чыкмыйча, 21 мең диңгез миле үткән. Экипаж да, Татарстанда ясалган техника да сынатмаган.

Беренче елда ук «Зелёный Дол» Россия Хәрби-диңгез флотының иң яхшы кече ракета корабы, Кара диңгез флотында иң яхшы кораб дип табылган һәм РФ Хәрби-диңгез көчләре башкомандующиеның ракета атышлары буенча бүләгенә лаек булган. Владимир Дербетов исә, флоттагы конкурста җиңеп, «Диңгез бүресе» номинациясендә иң яхшы командир исемен яулаган. Шунысы гаҗәп: үзләренең хәрби хезмәте турында моряклар әле фильм да төшерергә өлгергән. «Зелёный Дол». Кораб тормышы» лентасы – экипажның беренче ел хезмәт иткән дәверендәге вакыйгалар турында документаль хикәят.

Бүген «Зелёный Дол» Балтыйк диңгезендә, ракета катерлары бригадасы составында хезмәт итә. Командиры – икенче ранглы капитан Сергей Дидусенко.

«КАЗАНЕЦ» – БАЛТЫЙК БУЕНДА ДАН КАЗАНГАН КОРАБ

«Казанец» көймәләр һөҗүменә каршы кече корабы флотта инде күптәннән – 1986 елдан бирле Балтыйк диңгезендә хезмәт итә. Үлчәмнәре дә, экипажы да зур түгел, ә менә осталыгы сокландырырлык. 80 морякның бурычы җаваплы: яр буе һәм якын диңгез зонасын саклау, зарурлык туганда дошманның тизйөрешле суасты көймәләрен эзләп табу һәм юк итү. Саклау зонасы – үзебезнең Кронштадттан Швециянең Готланд портына кадәр, тагын Балтыйк диңгезенең Калининград янындагы көньягы да керә.

Экипажның үз бурычын ничек үтәвен җитәкчелек яхшы беләдер. Без исә бер факт кына китерәбез. 2017 елда, ХДФ көнендә Төньяк башкалада беренче тапкыр төп хәрби-диңгез парады үткәрелгәндә, Кронштадт рейдында хәрби кораблар сафын нәкъ менә «Казанец» җитәкләгән. Флот армадасын җитәкләп бару – җаваплы һәм бик катлаулы бурыч.

– Билгеләнгән нокталар аша кораб 30 секундка кадәр төгәллек белән үтәргә тиеш, – дип аңлата кораб командиры ярдәмчесе, капитан-лейтенант Евгений Петров. – Алдан баручы кораб калганнар өчен темпны билгеләп, алар исә дистанцияне саклап барырга тиеш. Бер ай буе әзерләндек. Ачык суда да,

Кронштадт рейдының тар җирендә дә. Сынатмадык!

Моннан соң экипаж парадларда тагын дүрт тапкыр катнашкан әле. 2018 елда, төп хәрби-диңгез парадын Россия Президенты кабул иткәндә, «Казанец» Петропавловск ныгытмасы янындагы кораблар сафында рейдта торган. Барысы да ап-ак парад формасы кигән моряк экипажлары палубаларда тезелеп баскан, ә Югары башкомандующий аларны сәламләп үткән.

Бәйрәм ул елына бер генә була. Калган көннәрдә исә киеренке хезмәт көтә. Иртәнге сәгать 6 да йокыдан торганнан алып кичке 11 дә йокларга ятканчы. Флотта тәртип булырга тиеш, һәрнәрсә җәдвәл буенча эшләнә, туклану да гел билгеле бер вакытта каралган. Бу кече корабта көненә дүрт тапкыр ашаталар. Иртәнге, төшке, кичке аштан тыш, татлы тәм-том белән кичке чәй дә бар. Аш исә көненә ике тапкыр мәҗбүри – төш һәм кич.

Кече ракета корабында зурсында булган бөтен нәрсә бар. Ашханә, кухня, медпункт, хәтта кечкенә генә спорт залы да. Йокы бүлмәсе – кубрикларның һәркайсы 14–15 кешегә исәпләнгән. Офицерлар каюталары, һәм аерым – командирныкы бар. Интернет һәм смартфоннар тыела. Ә күңел өчен нәрсә бар соң?

Күңел өчен – экипажның штаттан тыш әгъзасы, һәркем яраткан «Кот» кушаматлы мәче. Әйе, корабның үзенең Казан мәчесе дә бар. Казан мәчеләре кайчандыр Эрмитажны коткарган булса (тычканнардан), бу песинең исә бервакыт үзен коткарырга туры килгән. Суга егылып төшкән мырау артыннан диңгезгә матрос Максим Толкач сикергән...

Татарстан «Казанец» корабына 1998 елдан бирле шефлык итә. Шәһәр хакимияте башлыгының шул елдагы карары нигезендә кораб экипажына 150 комплект шәхси гигиена чарасы һәм 2 тонна буяу материаллары бүленгән.

Бүген, болганчык 90 нчы еллардан аермалы буларак, диңгезчеләрнең сабын, теш пастасы һәм буявы җитәрлек, һәм шефлык элемтәләре нәрсәдер бирүгә генә кайтып калмый. «Казанец» корабында Татарстаннан килгән кунакларны һәрвакыт сөенеп каршылыйлар, Казанда исә кардәш корабтан килүчеләргә хөрмәт күрсәтәләр. Дөрес, соңгы елларда элемтәләр әллә ни тыгыз түгел. Бәлки, экипажда Татарстаннан чакырылучылар булмагангадыр?

4
«Татарстан» бөтен Россия Хәрби-диңгез флоты өчен зур вакыйгага әйләнә.

5

Каспий флотилиясенең хәрби-диңгез парадында.

«ТАТАРСТАН»: МИНЕМ КЕБЕК ЭШЛӘ

«Татарстан» бөтен Россия Хәрби-диңгез флоты өчен зур вакыйгага әйләнә. Каспий флотилиясен кабаттан җиһазландыру шул корабтан башлана.

2003 елда су өсте корабларының 106 нчы бригадасы составында яңа сугышчан берәмлек пәйда булуны хәрби эксперт, запастагы беренче ранглы капитан Василий Дандыкин шулай бәяләгән. «Татарстан» артыннан Каспий флотындагы искергән корабларның берсе артыннан берсе заманча хәрби кораблар белән алыштырылган. Үзенең сугышчан мөмкинлекләре белән флотилияне таң калдырган «Татарстан» корабы исә, 2003 елның 31 августында үзендә Андрей әләме күтәрелгәннән соң ук, Кызыл байраклы Каспий флотилиясенең флагманына әйләнгән.

Барысы да Президентның җиңел кулыннан башланган. Яшел Үзәндә судноны төзүчеләр белән бергә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев һәм РФ Хәрби-диңгез флоты башкомандующие Владимир Куроедов корабны хезмәт итү урынына озатырга килгән. Хәер, «Татарстан»га протекция таләп тә ителмәгән.

– Бу кораб ул чакта ут куәте буенча бездә иң алдынгы иде, су сыйдырышлыгы да зур, – дип сөйли Василий Дадыкин. – «Татарстан» палубасында – «Уран» ракеталары. Шуңа өстәп, «Калибрлар»...

Кораб авыр чорда, туксанынчы елларда, илдә хәрби кораблар кайгысы булмаган чакта төзелә башлый. Һәм әгәр республиканың, шулай ук Горький исемендәге завод җитәкчелеге һәм коллективының үҗәтлеге булмаса, «Татарстан» корабының диңгез биографиясе бәлки башланмас та иде.

Әлеге ракета корабы – флотта әйтелгәнчә, киленнән алып клотигына кадәр Татарстанныкы. Аны башта Яшел Үзәндәге проектлау-конструкторлык бюросында уйлап табалар, аннары үзләре үк төзиләр дә. Шунлыктан шефларның аны аеруча җылылык белән кайгыртуы бер дә гаҗәп түгел. Хәрби-диңгез флоты көнендә завод делегациясе корабка кунакка килә. Әлбәттә инде, буш кул белән түгел – экипаж, шулай ук аеруча тырыш моряклар өчен бүләкләр төяп.

«Татарстан» ун елга якын Каспий флотилиясенең флагманы була. Шул вакыт эчендә хәрби бурычларын үтәгәндә һөнәрмәндлек һәм сугышчан осталыгын даими күрсәтә. Моряклларның бурычлары исә җитди: икътисадый зонаны һәм территориаль суларны саклау. Су өстендәге корабларны, катер һәм судноларны эзләү һәм юк итүгә, кораб һәм берләшмәләрне һава һөҗүменнән саклауга экипаж һәрвакыт әзер булырга тиеш.

Бүген «Татарстан» үзенең флагманлык вәкаләтләрен шулай ук Яшел Үзәндә төзелгән «Дагестан» ракета корабына тапшырган. Әмма безнең экипажның эше моңа карап кына бер дә кимемәгән. Кораб элеккечә үк флотилиянең төп диңгез һөҗүм көчләре составында, аның сугышка әзерлеге өйрәнү һәм маневрларда даими камилләштерелә, ял иткән арада исә «Татарстан» Каспий бассейны илләре портларына дустанә сәфәр кыла.

P.S. Мәгълүм булганча, «Татарстан» ракета корабы күптән түгел Әстерхан суднолар ремонтлау заводына китерелгән. Бирегә аны ремонт һәм яңарту көтә. Корабның тагын да куәтлерәк кораллар һәм яңа радиолокация чаралары белән җиһазландырылуы да ихтимал. Димәк, «Татарстан» тагын да куәтләнәчәк әле.

12+
«КИТАП»
ТЫҢЛА!
КИТАП МИЛЛИ радио
КАЗАН 98,6 FM
АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834
Реклама

ШИНЫ, РТИ И КАУЧУКИ
ШИНЫ, РТИ И КАУЧУКИ • TIRES & RUBBER
24-Я МЕЖДУНАРОДНАЯ СПЕЦИАЛИЗИРОВАННАЯ ВЫСТАВКА РЕЗИНОТЕХНИЧЕСКИХ ИЗДЕЛИЙ, ШИН, ТЕХНОЛОГИЙ ДЛЯ ИХ ПРОИЗВОДСТВА, СЫРЬЯ И ОБОРУДОВАНИЯ
26–29 АПРЕЛЯ 2022
Россия, Москва, ЦВК «ЭКСПОЦЕНТР»
МИНПРОМТОРГ РОССИИ
ТПП РФ
РОССИЙСКИЙ СОЮЗ ХИМИКОВ
ufi Approved International Event
РОССИЙСКИЙ СОЮЗ ВЫСТАВОК И ЯРМАРОК
Организатор: АО «ЭКСПОЦЕНТР»
При поддержке:
• Министерства промышленности и торговли РФ
• Российского Союза химиков
• ОАО «НИИТЭХИМ»
• ФГУП «НТЦ «Химвест»
Под патронатом ТПП РФ
ЭКСПОЦЕНТР
www.rubber-expo.ru
12+
Реклама

Акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Роботлар рентген сурәтләрендә COVIDны **НИЧЕК** күрә

Менделеевск прокуроры **НИ ӨЧЕН** Кукмараны сагына

Марат Кәбиров **НИГӘ** фантастик әсәрләр язмый

ИКЕНЧЕ ФИКЕР – РОБОТНЫКЫ

Ксения Сёмина

Иннополис Университеты галимнәре машинаны рентген сурәтләрендә COVID-19 билгеләрен табарга өйрәткән. Алга таба нәрсә?

Ике ел элек ММЧында Иннополис Университетында уйлап табылган нейрочелтәр (бер-берсе белән бәйләнгән күпләгән ясалма нейроннар челтәре) үпкәнең цифрлы рентген сурәтен тикшерергә һәм анда коронавирус инфекциясе билгеләрен ачыкларга өйрәнгән диган хәбәр пәйда булды. Сынау үрнәгендә машина һәм табиб-рентгенолог бер-берсенә бәйсез рәвештә COVID-19 шиге булган пациентларның үпкә сурәтләренә анализ ясый. 80% очракта патологиянең барлыгы һәм юклыгы турындагы алгоритм бәяләмәсе табиб фикере белән туры килә.

ДИАГНОСТИКАГА БЕР МИНУТ ҖИТӘ

Исегезгә төшерик: пандемиянең башлануы турында БСО 2020 елның 11 мартында игълан итте. Ә Татарстан нейрочелтәренең казанышлары турында мәгълүмат 26 мартта пәйда булды. Яңалыкны укыган күпләр ул вакытта моны фейк дип уйлады. Шундый кыска вакыт эчендә шундый бик төгәл система төзергә мөмкинме икән? Әлбәттә, әгәр әлеге проектка алты ел элегрәк әзерләнергә тотынсаң. Һәм эш биредә бөтенләй конспирациядә түгел.

– Рентген сурәтләренә анализ – безнең университетта ясалма интеллект өлкәсендә-

ге проектлар шуңардан башланды. 2014 елда медицина сурәтләренә компьютерлы анализ лабораториясе төзелде. Мин аны үстерү белән шөгыльләндем, – дип сөйли Иннополис Университетының Ясалма интеллект институты директоры Рамил Кулиев.

Тикшеренүләр предметын сайлау шактый җиңел аңлатыла. 2014 елда медицина учреждениеләре цифрлы рентгенны шактый киң куллана, бу ысулга күпләп күчә башлый. Табиб-рентгенологның диагностикасын автоматлаштыру өчен медицина сурәтләрен анализлау хезмәтен эшләү бик перспективалы проект санала.

– Рентген-сурәт ясау – иң киң таралган скрининг тикшерүе. Россиядә ел саен якынча 80 млн флюорографик тикшерү уздырыла. Элек пленкадагы сурәтләр ачык чыкмый иде, аларны лупа аша диярлек карап өйрәнделәр. Бүгенге цифрлы рентген сурәтләренең төгәллеге бик югары, алар төрле тайпылышларга дифференциаль, шул исәптән автомат рәвештә машина алгоритмнары ярдәмендә диагностика үткәрергә мөмкинлек бирә, – дип аңлата Рамил Кулиев.

Галим һәм аның хезмәттәшләре тарафыннан эшләнгән алгоритм төрле мәгълүмат базаларындагы сурәтләр нигезендә өйрәтелә. Медицина оешмалары белән тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә өйрәтү өчен Татарстан Республикасы хастаханәләрендәге рентген сурәтләре кулланыла. Шулай ук мәгълүмат базасына ачык киңлектә булган сурәтләр дә кертелә. Пандемия башланганда машина төрле тайпылышлар булган дистәләгән мең үпкә сурәтен «караган» һәм истә калдырган була, норма саналганны норма булмаганнан аерырга өйрәнә. 2019 елда Иннополис Университеты нейрочелтәре рентген сурәтендә үпкәдә пневмония булуын автомат рәвештә ачыклау буенча халыкара конкурста икенче урын ала. Шуңа күрә 2020 елда аны эшләүчеләргә нейрочелтәрне COVID-19 китереп чыгарган тайпылыш сурәтләрен аерырга бераз гына өйрәтеп бетерәсе генә кала. Әлеге технологияне киң кулланышка кертү табибларның эшен җиңеләйтергә һәм диагноз куюны тизләтергә тиеш була. Ләкин алгоритм әле һаман ярдәмче генә, тулы канлы диагност түгел. Ул тәҗрибәле рентгенолог белән бертигез дәрәҗәдә патологияләрне ачыклый ала, әмма эксперт дәрәҗәсенә җитә алмый

Рамил Кулиев һәм аның хезмәттәшләре тарафыннан эшләнгән алгоритм төрле ачык мәгълүмат базаларындагы сурәтләр нигезендә өйрәтелә.





Нейрочелтәр ачыклаган үпкә патологиясе.

әле, гәрчә Татарстан галимнәре тәҗрибәсендә нейрочелтәрнең табиб күрмәгән тайпылышларны күргән очраклары булса да.

– Рентген сурәтендә озак дәваланмаган коронавирус инфекциясенең үпкәгә китергән зыяны ачык күренә. Процессның башы, мәсәлән, тоныкпыяла симптомы бөтенләй күренми диярлек. Шуңа күрә визуаль диагностиканың алтын стандарты – компьютер томографиясе. Ләкин хәтта пандемия шартларында да томография рентген кебек массакүләм тикшерү саналмый. Без бурычларны планлы рәвештә хәл итәбез, – ди Иннополис Университетының Ясалма интеллект институты директоры. – Инде хәзерге вакытта ук алгоритм тиз арада рентген сурәтләрен патологияле һәм патологиясезгә аера ала. Һәм бу бик мөһим, чөнки, мәсәлән, сүз үпкәләр турында барганда, нигездә, алар нормада, ләкин табиб аларның барысын да карый, моның өчен күп көч түгә. Күз арый, нәтиҗәдә ул патологияле үпкә сурәтен күрми калырга мөмкин. Моннан тыш, системаны шундый итеп көйләргә мөмкин: ул белгечкә сурәтләр арасыннан нормадан иң көчле тайпылыш күренгәннәрен сайлап алып, беренче чиратта ярдәм таләп ителгән пациентларны ачыкларга булыша ала.

Рамил Кулиев һәм аның хезмәттәшләре уйлап тапкан алгоритмның мөмкинлекләре коронавирус инфекциясен күреп алу белән генә чикләнми. Хәзер институт Мәскәү шәһәре Сәламәтлек саклау департаментының нур диагностикасына компьютер күзе технологиясен кертү буенча экспериментал проектта катнаша. Проектның зур бер өлеше – мәгълүмат челтәренә берләшкән табиб-рентгенологларның эш урыннары өчен башкалада булдырылган сыйфатлы инфраструктура. Иннополиста нейрочелтәр Мәскәүдәге табибтан сурәт кабул итә, аңа анализ ясый һәм ачыкланган патология һәм аның урнашкан урыны турындагы мәгълүматны кире башкалага юллый. Җавап кайтару да исәпкә алынган бөтен процесс бер минуттан да азрак вакыт эчендә башкарыла. Хәзерге вакытта нейрочелтәр рентген сурәтләрендә 80%тан да артыграк төгәллек белән үпкәләрдәге 15тән күбрәк төрдәге патологияне ачыкларга сәләтле. Гәрчә диагноз куйганда соңгы сүзне барыбер табиб әйтсә дә, нейрочелтәрнең җавабы – белгеч өчен оператив ярдәм, үзенә күрә икенче фикер.

Нур диагностикасы.

Мәскәү проекты кысаларында нейрочелтәр 700–800 мең тикшерү үткәргән инде.

– Мәскәүләр белән эшләүнең безнең өчен зур уңай ягы шунда: алар челтәргә берләшеп, диагнозлары куелган цифрлы сурәтләр базасын булдырган. Нейрочелтәр өчен моны дата-сет, уку-укыту карточкалары җыелмасы диярgә була. Аларны өйрәнеп, алгоритм үзенең белемен киңәйтә, төгәллеген арттыра, – дип аңлата Рамил Кулиев.

ФИЗИКАНЫ ҮЗГӘРТЕП

Татарстандагы хастаханә, поликлиника, диагностика үзәкләре белән дә эш алып барыла. Мондый хезмәттәшлекне алып бару өчен табиб цифрлы сурәтләрне карый, шулай ук аны безгә интернет яисә башка элемтә каналы аша юллый алырга тиеш. Рамил Кулиев фикеренчә, якындагы ике ел эчендә әлеге хезмәттәшлек китергән уңай нәтиҗәләрне күрергә тиешбез.

Галим алдынгы медицина учреждениеләренең тагын бер уңай эш юнәлешен атый – диагностикага комплекслы якын килү, ягъни бер тикшерү вакытында кешенең төрле органнарына бәйле нәтиҗәләрне алу.

– Башка КТ үткәргәндә без кан тамырлары, нерв тукымасы, сөяк тукымасы һ.б.ларга караган патологияләрне ачыклый алабыз. Ләкин әлегә безнең нейрочелтәр бу юнәлештә тулы канлы куллану өчен җитәрлек сандагы сурәтләрне карап чыкмаган, – ди Рамил Кулиев. – Шулай да без якын араларда компьютер томографиясе нигезендә баш мие инсульты, умыртка баганасы патологиясе диагностикасын, патоморфологик диагностика һәм башка хезмәт күрсәтүләрне башлап җибәрергә уйлыйбыз.

Хәзерге вакытта нейрочелтәрне уйлап табучылар медицина белгечләренә бердәм стандарт буенча тикшерүләр беркетмәсен төзергә мөмкинлек бирүче коралларны булдыру юнәлешендә эшли. Төрле табиблар бер үк тикшерүнең нәтиҗәләрен төрлечә яза: кемдер тулырак итеп, кемдер кыскарак; төрле төшенчәләр, формулировкалар кулланыла. Әлеге мәгълүматны бердәй итү, ягъни унификацияләү дата-сет булдыру процессына ярдәм итәр һәм нейрочелтәр өчен өйрәнүне тизләтер иде.

Рамил Кулиев җитәкчелек иткән проектның киләчәге бик кызыклы. Бүгенге көндә Иннополис Университетының Ясалма интеллект институты Россиядә ясалма интеллект буенча алты федераль тикшеренү үзәге программасына керә. 2024 ел ахырына кадәр институт командасы берничә программа продуктын эшләргә тиеш, шул исәптән – яңа материалларны булдыру өлкәсендә дә. Мондый проектлар – сәнәгать һәм ясалма интеллектның берләшүенә караган төп дөнья трендларының берсе. Узган елда DeepMind (Google структурасына керә) Америка компаниясе Isomorphic Labs бүлендек компаниясен ачты, ул машина өйрәтүе ярдәмендә дарулар ясау белән шөгыльләнәчәк.

– Без нейрочелтәрне өйрәтү буенча эшлибез, ул материалларның структурасы буенча аларның үзлекләрен һәм, киресенчә, үзлекләре буенча структураларын алдан әйтә алачак. Шул ук DeepMind аминокислоталары эзлеклелеге буенча аксымның өч үлчәнешле структурасын алдан әйтергә мөмкинлек бирүче алгоритмны төзеде инде. Аның үзлекләре нәкъ менә структурасына бәйле, – дип аңлата Рамил Кулиев. – Мондый технологияләр матдә һәм материаллар физикасын аңлавыбызны үзгәртергә һәм фармацевтика, электроника, фотоника, нефть химиясе һәм башка тармаклар өчен чимал җитештерүне йөзләрчә мәртәбәгә тизләтергә сәләтле. Бу искиткеч прогресс.

Теләгә булган һәр кеше институтның әлеге алгарышлы проектында катнашу мөмкинлегеә өчен ярыша ала. Февраль аенда Иннополиста беренче Global AI Challenge хакатоны оештырыла. Командалар ясалма интеллект нигезендә бирелгән үзлекләргә ия молекулаларны автоматлаштырылган сайлап алу алгоритмын төзергә тиеш була. Иң яхшы проектлар, ихтимал, даруларның өр-яңа төрләрен җитештерү өчен нейрочелтәр эшләүнең нигезенә салыныр.

Хәзерге вакытта нейрочелтәр рентген сурәтләрендә 80%тан да артыграк төгәллек белән үпкәләрдәге 15тән күбрәк төрдәге патологияне ачыкларга сәләтле.



«КОРД» КЛИНИКАСЫ: МЕНӘ ДИГӘН ҺӘМ АННАН ДА ШӘБРӘК

200 процент күрү сәләтенә ия кеше дөньяны ничек күрә, шуны беләсезме?.. Медицина өлкәсендә нәрсәдә һәм ни өчен экономиялиләр? Ничек итеп һәм ничә яшьтә күзлектән мәңгегә бөтенләйгә котылып була? Кайсы мөһимрәк – табиб тәҗрибәсеме, әллә соңгы буын җиһазлармы? Бу сорауларга «Корд» офтальмология клиникасының баш табибы җавап бирде.

Антон Демидовның эш өстәлендә медицина карталары өелгән. Ул кулына эләккән беренчесен ачып карый.

– Менә, операциядән соң пациентның күз күреме – 120 процент. Һәм ул беренче көнне үк шулай – алга таба яхшырак кына булачак. Бу – көндәлек очрак. Яңа буын җиһазлар алганнан соң, мондый нәтиҗә пациентларның күбесендә күзәтелә, ә әле күптән түгел генә исә андый нәрсә гайре табигый күренеш дип карала иде. Хәзерге көндә без ирешкән иң соклангыч нәтиҗә – ике күзнең дә ике йөз процентка күрүе. Кеше мөмкинлекләренең чиге юк диярлек.

– Ә бу, гомумән, кешегә кирәкме соң? – дип, бу мәгълүматны аңымда эшкәртергә тырышам. – Мондый гайре табигый күз күреме нәрсә бирә?

– Мондый үткен күзлелек күздәге оптик системаның ни дәрәҗәдә яхшы эшләвен күрсәтә. Димәк, анда оптик тайпылышлар минималь дәрәҗәдә. 200 процентлы күз күреме булганда, бер үк төрле ераклыктан ике тапкыр күбрәк детальләрне күрәсең. Башкача әйткәндә, вак детальләр йөз процентлы күз күреме белән чагыштырганда ике тапкыр зуррак ераклыктан да күренә. Әйе, мондый үткен күзлелек яхшы яктылык шартларында әллә ни зур әһәмияткә ия түгел, әмма, мәсәлән, төнлә рульдә барганда хәлиткеч роль уйный, андый вакытта хәтта күз күремендәге егерме процент аерма да тормыш өчен әһәмиятле булырга мөмкин.

Клиника офтальмологларына әлегәчә күрелмәгән мондый югары үрләргә ирешергә былтыр сатып алынган Ziemer Швейцария компаниясе җиһазы мөмкинлек биргән. Антон Демидов сүзләренчә, бүген ул аппарат – дөньяда иң заманча лазерларның берсе.

СӘЛАМӘТЛЕКНЕ НЫГЫТКАНДА АКЧАНЫ НИЧЕК ЯНГА КАЛДЫРЫРГА?

– Хәзерге медицина тармагында төрле клиникаларда бер үк хезмәтнең бәясе нык аерылып торуын еш күрергә була, – дип сөйли Антон Демидов. – Әмма бер үк заводта җитештерелә торган һәм бер үк сыйфатка ия телефон яки телевизордан аермалы буларак, теге яки бу клиникадагы медицина хезмәте төрле булып чыга.

Төрле җиһазлар, төрле көндәлек материаллар, белгечләрнең квалификациясе – болар барысы да хәлиткеч мөһим аерымлыклар, тик алар күзгә бәрелеп тормый һәм аларны һәркем дә күрә белми. Медицинаның кайбер өлкәләрендә без моңа күнеккән инде, ә кайберләрендә әле төшенеп җитә алмыйбыз. Медицинада теләсә нинди экономиянең, тормышның башка өлкәләрендәге кебек үк, һәрвакыт сыйфатка йогынты ясаганын кабул итү читен. Әйтик, без стоматологта теш яматканда, бюджет клиникасындагы бик очсызлы пломбаның абруйлы клиникадагы кыйммәтле пломбадан күпкә азрак вакыт хезмәт итәчәген аңлыйбыз. Тик мондый аерма башка медицина хезмәтләренә дә кагылганын бөтен кеше дә аңлап бетерми. УЗИ тикшеренүен генә алыгыз – яхшы аппаратта табиб баланың җенесен йөклелекнең башында ук аера, ә очсыз аналогта – хатын-кызның йөккә узганмы-юкмы икәнен дә бик авыр күрәчәк. Арзанлы наркоз препаратлары кыйммәтлесенә караганда бөтенләй башка тәэсиргә ия. Арзанлы тикшеренү аппаратурасы бик төгәл нәтиҗә бирми. Бөтен җирдә дә шулай. Төп фикер төрле клиникаларда бер үк хезмәтнең төрлечә башкарылуыннан гыйбарәт. Һәм аерма чын мәгънәсендә шаккатарлык булырга

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Фото «Корд» офтальмология клиникасыннан алынды. Реклама.

мөмкин. Димәк, бәясе дә аерылып торачак. Кызганыч, чынбарлыкта барысы да шулай.

Без аппаратураны үзебез өчен экономияне күздә тотып түгел, ә «иң яхшылар арасыннан иң яхшысы булсын» принцибы белән сайлыйбыз. Искергән һәм очсызланган аппаратларны яки инде кулланышта булган техниканы сатып алмыйбыз.

– Андый нәрсә дә буламыни?

– Әлбәттә. Медицина җиһазлары, автомобильләр кебек үк, тормышлары дәвамында еш кына өч һәм аннан да күбрәк «хуҗа»ны алыштыра. Ни кызганыч, яңа клиникаларның барысы да яңа аппаратурада эшли дигән сүз түгел. Базар икътисадының үз кануннары!

ТЕХНОЛОГИЯМЕ, БЕЛГЕЧМЕ?

Зур экранда – бик нык зурайтып күрсәтелгән күз. Бөтен микроскопик нечкәлекләре белән. Каршыдагы кәнәфидә пациент утыра. Чит кеше күзе түгел – аның үзенеке. Видеоязма табибка проблеманы ачык итеп аңлатырга һәм аны нинди юллар белән хәл итеп булуы турында сөйләргә, дәвалауга кадәрге һәм аннан соңгы аерманы күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Бу клиникада авыру белән һәр очрашу әнә шулай уза. Әйе, биредә заманча алымнар дәвалауда гына түгел, ә һәркайда кулланыла. Бина эчләренең дизайны һәм уңайлылыгы булсынмы (аларны күргәч, «Корд»ны «хастаханә» дип атарга тел әйләнми башлый), яисә пациентларның барлык материалларын һәм карталарын электрон рәвештә алып барырга мөмкинлек бирә торган яңа документ әйләнеше технологияләре булсынмы – һәр юнәлештә файдаланыла.

– Медицина җиһазлары җитештерә торган әйдәп баручы ширкәтләрнең инженерлары бездә еш кунак була. «Корд» – безгә күрергә насыйп булган иң яхшы клиникаларның берсе, дигәннәрен һәрчак ишетәбез, – ди Антон Демидов. – Әйе, бездә урнаштырылган җиһазлар теләсә кайсы белгечне таң калдыра ала. Әмма мондый җиһазларның мөмкинлекләрен ача алу, һәр технологиянең иң нечкә урыннарын да ачыклый белү мөһим. Моны бары тик югары квалификацияле белгечләр булганда гына эшләргә мөмкин. Һәм бу мәсьәлә алдынгы җиһазларга караганда мөһимрәк.

– Заманча офтальмология «Формула 1» дөнья чемпионаты узышларына бик охшаган! – дип дәвам итә Антон Демидов. – Бу исә пилотларның һәм команданың осталыгы гына түгел, материалларга, запас детальләргә һәм техникага карата бик югары таләпләрнең дә әһәмияте бик зур дигән сүз. Бер генә нәрсәдә житешсезлек булса да, җиңү күрмисең. Бездә дә шулай. Югары класслы хирург, тиешле дәрәҗәдәге заманча корал, аппаратура һәм дарулар булмаса, искиткеч нәтиҗәгә ирешә алмый. Һәм киресенчә, аларда эшләрлек кеше юк икән, иң яхшы җиһазлар да мәгънәсен югалта. Шуңа күрә без үз клиникабызда ике якка да игътибар бирәбез.

Бүген «Корд» клиникасында тиңдәшсез белгечләр эшли. Әйтик, бөтен Россиягә танылган офтальмолог, күзнең челтәр катлавына бик катлаулы, югары технологияле операцияләр башкара торган профессор Александр Николаевич Самойлов кебек. Яки күзнең челтәр катлавын лазерлы дәвалауда танылган белгеч, башка клиникалар тарафыннан өметсез дип санап кире кагылган күп кенә пациентларның күзләрен коткарып калган Артем Николаевич Коробицин сыман осталар хезмәт куя биредә.

«Корд» клиникасында кулланыла торган кайбер процедураларны дөньяда нибары берничә клиника гына башкара. Мәсәлән, мөгез катлаудагы төрле тоныклануларны дәвалау. Бу патология төрле җәрәхәтләр яки җитди авырулар нәтиҗәсендә барлыкка килергә мөмкин һәм, гадәттә, әлеге проблеманы күзнең мөгез катлавын күчереп утырту ярдәмендә хәл итәләр. Мондый катлаулы процедура көтелгән нәтиҗәне кайчак биреп бетерми – әйтик, чит мөгез катлауны организм кабул итмәскә мөмкин. Тик уңышка ирешкән очракта да пациентның күз күреме өлешчә генә – уртача алганда 30–50 процентка гына торгызыла. «Корд» клиникасында мондый тоныклыкны алып ташлый беләләр, шул ук вакытта кешегә мөгез катлауны күчереп утыртмыйча, аның үзенекен саклап калалар. Мондый дәвалауның төп нәтиҗәсе – бик югары, тотрыклы күрү сәләте, организм тарафыннан кире кагылмау, ялкынсынулар булмау. Шул ук вакытта, күчереп утыртуга караганда, болай дәвалау берничә тапкыр арзанрак та килеп чыга.

– Клиникабызда мондый хезмәтләр саны арта бара, безгә пациентлар Россиядән генә түгел, БДБның башка илләреннән, Якын Көнчыгыш һәм Европа дәүләтләреннән дә килә. Алай гына да түгел, без бер генә төр проблема белән шөгыльләнмибез, ә төп күз авыруларының барысын да диярлек дәвалау өчен, белгечләр һәм җиһазлар тупладык инде.

– Димәк, клиникагыз күзнең күрүе белән бәйле теләсә нинди проблемаларны хәл итү генә түгел, моны гаять үзенчәлекле итеп тә башкара ала?

– Нәкъ шулай. Бездә һәр чирне дәвалау өчен махсус «алдынгы» технология сайлап алынган, – ди Антон Демидов. – Без мондый технологияләрне максатчан рәвештә күзәтеп барабыз, исемлекне даими яңартып торабыз, өйрәнәбез һәм гамәлгә кертәбез. Безнең эш принцибы шундый: хезмәтебезнең һәр юнәлешендә иң яхшысы булу. Күптән түгел, мәсәлән, балаларда күз күремен яхшырту мәсьәләсен хәл иттек, ә андый проблема белән безгә еш мөрәҗәгать итәләр. Моның өчен бик шәп төнге контактлы линзалар технологиясен керттек. Яки, әйтик, бездә глаукомалы пациентны һәрдаим тамчылар белән дәвалап торудан котылырга мөмкинлек биргән аппаратура бар. Гомумән, күз диабетын дәвалау – клиниканың бер мактанычы ул. Соңгы сатып алынган җиһазыбыз – яңа Ziemer лазеры мультифункциональ аппарат булып тора һәм күз күремен коррекцияләү генә түгел, ә күз ясмыгын алыштыру һәм мөгез катлау пластикасы операцияләренең дә нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирә. Без әлеге лазерның базарга чыгуын берничә ел юкка гына көтмәдек! Бу чагыштырмача кечкенә прибор әле күптән түгел генә клиниканың горурлыгы булган һәм дөньяда күп кенә белгечләр тарафыннан иң шәп дип саналган югары технологияле берничә аппаратны берьюлы егып салды.

ХӘЗЕР ҮК САЛЫП ТАШЛАГЫЗ МОНЫ!

– «Корд» – кеше күзлектән котыла ала торган урын ул. Өстәвенә, теләсә кайсы яшьтә! – дип сөйли Антон Демидов. – Бүген мин әүвәл 30 яшьлек, ә аннары 55 яшьлек ир-атка операция ясадым һәм ахырда – 80 яшьлек пациентка. Өчесе дә иртән күзлектән килде, ләкин инде аны бүтән кимәячәкләр.

– «Корд»та күз күремен яхшыртуның дөньяда булган бөтен ысуллары тәкъдим ителгән, – дип йомгак ясый әңгәмәбезгә Антон Демидов. – Клиникаларның һәркайсы да моның белән мактана алмый. Шулкадәр аппаратура безгә нигә кирәк? Гадәттә, клиникалар пациентларга проблемадан үзләрендә булган технологияләр ярдәмендә котылырга тәкъдим итә. Әмма мондый ысул белән эш иткәндә технология теге яки бу очрак өчен иң яхшысы булачак дигән сүз түгел әле. Без исә, заманча офтальмологиянең бөтен мөмкинлекләренә ия булып, иң яхшы нәтиҗә бирәчәген тәкъдим итәбез. Бу – безнең төп принцибыбыз. Башкача мөмкин дә түгел.

ТУРИСТЛАРНЫ ҖӘЛЕП ИТҮЧЕ ТӨБӘКЛӘРНЕҢ «АЛТЫН УНЛЫГЫ»

МИЛЛИ ТУРИСТЛЫК РЕЙТИНГЫ–2021 ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА*

1

КРАСНОДАР КРАЕ

КАЙСЫ КЕМ

Быел рейтингны Краснодар крае җитәкли. Кара диңгез яр буе диңгез һәм кояш нурлары турында хыялланган кешеләрне үзенә магниттай тарта. Төбәктә урнашкан курортлар, шул исәптән кышкы, Красная Полянадагысы, пандемия шартларында инде икенче ел рәттән килүчеләр саны буенча рекорд куя. Краснодар крае администрациясе мәгълүматларына караганда, 2021 елның 11 ае эчендә төбәк 16,2 млн туристны кабул иткән, бу 2020 ел күрсәткечләренең 47% ка артуын аңлата.

Рейтингның икенче баскычын Мәскәү өлкәсе алып тора. Мәскәү яны пандемия шартларында Россия башкаласында яшәүчеләр өчен ял итү, көч җыю урыны гына булып калмыйча, сәламәтлекләрен ныгыту урынына да әверелгән. Төбәк туристлык комитеты мәгълүматларына караганда, җәй айларында кунакханәләр 95 процентка тулы булган. Алга киткән шифаханә-курорт базасының булуы, анда ял итәргә килүчеләрнең күплеге Мәскәү өлкәсенә рейтингтагы иң якын көндәше – быел 3 нче урынны биләгән Мәскәүне тагын узып китәргә мөмкинлек биргән.

2

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ

Сергей КРАСНОПЁРОВ, «Туризм.РФ корпорациясе» АҖ башкарма директоры:

– Без киң күләмле туристлык төзелешенә килеп җиттек, нәтиҗәдә якындагы ун ел эчендә эчке туризм тулысынча яңартылырга тиеш. Әлеге максатларда дәүләт тарафыннан бөтен шартлар да тудырылды: «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» милли проекты кабул ителде, ташламалы кредитлау программасы эшләп китте, бизнеска ярдәмгә Туризм.РФ корпорациясе оештырылды, анда шәхси-дәүләт партнерлыгы шартларында перспективалы инвестицияле проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлекләре һәм инвесторларга ярдәм чаралары тупланган.

*Россия төбәкләренең туристлык җәлеп итүчәнлеге буенча еллык җиденче рейтингы, «Рейтинг» мәгълүмати коммуникацияләр үзәге белән берга, эчке һәм тышкы туризм турында «Россияда ял» журналы тарафыннан эшләнде.

3

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ

Россиянең теләсә кайсы төбәге белән чагыштырганда, чит ил туристларының саны традицион рәвештә күбрәк булган Мәскәүдә кунакханәләр базары эшен торгызу акрынрак темплар белән бара, бу ил буенча уртача алганда. Мәсәлән, Росстат мәгълүматларына караганда, башкаладагы куну-урнашу урыннары 2021 елның гыйнвар-сентябрь айларында 61,1 млрд сум керем алган, бу 2019 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 36%ка кимрәк (Россия буенча плюс 1%). Мәскәүдә кунулар саны, 2019 ел белән чагыштырганда, 6%ка, ягъни 23,7 млн сумга кадәр кимегән. Шулай да башкалада туристлык тормышы туктап калмаган. Дөнья күләмендә билгеле һәм абруйлы Michelin рейтингының «кызыл гидында» Мәскәү рестораннарының пәйда булуы башкалада гына түгел, аннан читтә дә иң күп тикшерелә торган вакыйгаларның берсенә әверелгән.

4

КЫРЫМ РЕСПУБЛИКАСЫ

МӨҺИМ

Төбәкләрдә туристлык тармагы үсешенә, аларның туристлык мөмкинлекләренә, җәлеп итүчәнлегенә бәя биргәндә түбәндәге күрсәткечләр исәпкә алына:

- Туристлык тармагы һәм кунакханә инфраструктурасы үсеше дәрәҗәсе
- Туристлык һәм кунакчыллык тармагының керемлелеге, аның төбәк икътисадына керткән өлеше
- Шифахана-курортлык тармагы үсеше
- Берничә көнгә килүче туристлар арасында төбәкнең популярлыгы
- Чит ил кешеләре арасында төбәкнең популярлыгы
- Төбәкнең туристлык уникальлеге һәм җәлеп итүчәнлеге: дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары саны
- Җинаятьчелек дәрәҗәсе
- Ял итү урыны буларак Интернетта төбәк белән кызыксыну: төбәктә ял итү турында эзләү системасына мөрәҗәгатьләр саны.
- Мәгълүмат кырында төбәкнең туристлык мөмкинлекләрен алга этәрү: массакүләм мәгълүмат чараларында төбәк телгә алынган хәбәрләр һәм язмалар саны.

Элеккеге кебек үк, «Рейтинг» мәгълүмати коммуникацияләр үзәге эш принципларына ярашлы рәвештә, тикшеренүләрдә эксперт җәмәгатьчелеге вәкилләренең фикерләре һәм бәяләмәләре исәпкә алына: бу очракта – «Россиядә ял» медиатөркеме белгечләренең. Әлеге медиатөркемгә эчке һәм тышкы туризм турында «Россиядә ял» журналы һәм сайты, берничә туристлык порталы, инглиз телле аудитория өчен Tourism & Leisure in Russia сайты һәм журналы керә.

Дмитрий ГОРИН, Россия туриндустриясе берлегенең вице-президенты (Мәскәү):

– Россиядә дә, чит илләрдә дә чикләүләр кертелү нәтиҗәсендә 2021 ел җиңел килмәсә дә, күрсәткечләр аннан алдагы елга караганда яхшырак. Бөтендөнья туристлык оешмасы бәяләмәләренә караганда, Россия эчке туризмны торгызу буенча беренче бишлеккә керде. Нәкъ менә ил эчендә оештырылган туризмны, кеше ташуларны дөрес оештыру компанияләргә эшләрен яңадан тотрыклыландырырга мөмкинлек бирде. Без пандемиягә кадәрге 2019 ел күрсәткечләренә якынлашып киләбез, ә Кырым, Краснодар крае, Калининград өлкәсе кебек кайбер төбәкләр хәтта бу күрсәткечләрне узып та китте.

5

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ШӘҺӘРЕ

6

ПРИМОРЬЕ КРАЕ

7

АЛТАЙ КРАЕ

Татарстан (рейтингта 8 нче урын) һәм аның башкаласы Казан мәдәни-танып белү туризмы белән кызыксынучылар өчен иң популяр юнәлешләрнең берсе булып тора. Быел TUI Россия туроператоры тарафыннан, Ростуризм һәм төбәк хөкүмәте ярдәмендә, беренче мәртәбә Мәскәүдән республика башкаласына чартер рейслары оештырылган. Беренче чартер 2021 елның 13 сентябрендә очкан, ә программаның икенче мәртәбә эшләп китүе Яңа ел алдыннан булган. Татарстанга турның бәясе 14,4 мең сумнан башланган. Кунаклар, традицион рәвештә күрсәтелә торган истәлекле урыннардан тыш, татар Кыш бабаенда да кунак булган.



8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

9

ТҮБӘН НОВГОРОД ӨЛКӘСЕ



10

САМАРА ӨЛКӘСЕ

Сангаджи ТАРБАЕВ, Дәүләт Думасының туризм һәм туристлык инфраструктурасын үстерү комитеты рәисе:

– РФ Президенты күрсәтмәләрен үтәү максатыннан 2021 елда РФ Хөкүмәте тарафыннан яңа «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» милли проекты тәкъдим ителде. Ул өч федераль проектны үз эченә ала: «Туристлык инфраструктурасын үстерү», «Туристлык хезмәтләрен арттыру» һәм «Туристлык сферасында идарәне камилләштерү». Милли проект эчке һәм тышкы туризмны һәм барыннан да бигрәк аның алты төрен үстерүгә юнәлдерелгән: мәдәни-танып белү, вакыйгаи, экологик, тау чаңгысы, пляж һәм шифаханә-курорт ялы. Милли проектта туризм үсешенә йогынты ясый торган дәүләт һәм төбәк программаларында каралган төрле чаралар өчен кирәкле бюджет акчалары тупланган.

Шәхси-дәүләт партнерлыгы принциплары милли проектны гамәлгә ашыру механизмының нигезенә әверелде. Бу бюджет акчаларының һәр сумына якынча 3–4 сум шәхси инвестор керткән акчаның туры килүен тәэмин иткән мультипликатив нәтиҗәлелеккә ирешергә мөмкинлек тудыра. Милли проектның финанс коралы сыйфатында «Туризмны үстерү» дәүләт программасы эшләнгән, әлеге программаны тормышка ашыру өчен «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллардагы план чорына федераль бюджет турында» 2021 елның 6 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан өч елга 166 млрд сумнан артык акча каралган. Моннан тыш, 2022 елда туристлык кешбэгы программасы дәвам иттереләчәк.

Антон СЕМЁНОВ, эчке һәм тышкы туризм турында «Россиядә ял» журналының шеф-редакторы, генераль директоры:

– Көчле һәм уңышлы Мәскәү, Санкт-Петербург, Олимпия уеннарына яңартылган Сочи, матурланган Казан, үзенчәлекле Владивосток, 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын кабул иткән башка шәһәрләр Россиянең заманча, кунакчыл, төрле телләрдә сөйләшүче дөнья туризмы башкаласы булырга теләвен һәм була алуын ачык күрсәтә. Һәм чикләүләргә, даими басымга, безнең чикләр янында барган бәрелешләр һәм революцияләргә дә карамастан бу шулай...

Фото: Георгий Захарчук, Алексей Куденко, erv.ru, must-see.top, zen.yandex.ru, @kopylov_ax

PRESSA

ЮГАРЫ ОСЛАН: ФАСЫЛЛАР БАЛКЫШЫНДА

Югары Осланга җәен генә барырга кирәк дип уйлаган кеше кем ул? Кышын беркайчан да анда булмаган кешедер. Матурлык кайчан да матурлык! Сезнең игътибарыгызга әлеге гүзәл төбәкнең туристлар һәм журналистлар тарафыннан төшереп алынган сурәтләрен тәкъдим итәбез.

Фото: Александр Ефремов


ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН


ОСТРОВ
Ф ФИГНЕР
ПАРОМ ВОЛГАРЬ
ВЕРХНИЙ
УСЛОН
ПАРИЖСКАЯ
КОММУНА
УСЛОНСКИЙ ПЕРЕВОЗ
В. ЗАСУЛИЧ
ДИНАСТИИ РЕЧНИКОВ
ОСТРОВ МАРКИЗ
ГЕРОЙ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО ТРУДА
ПУШКАРЕВ ЛЕОНИД ВАСИЛЬЕВИЧ (1926 1995)
СОЛОВЬЕВ АЛЕКСАНДР КАВАЛЕР ОРДЕНА ЛЕНИНА
ПАВЕЛ КАПИТАН ПАРОХОДА ТОКАРЕВ
МАКСИМ МОРЯК КАЗАРОВ ИВАН УЧАСТНИК РЕВОЛЮЦИИ

НИКТО НЕ ЗАБЫТ - НИЧТО НЕ ЗАБЫТО!
1945


ВЕРХНИЙ
УСЛОН

НИКТО НЕ ЗАБЫТ - НИЧТО НЕ ЗАБЫТО!
941
1945

1945

ЮГАРЫ ОСЛАН: КҮЗ САЛ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ ГҮЗӘЛ!

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

РИШАТ ШАКИРОВТАН «СПОРТ» САЛАТЫ

Татьяна Вафина

Менделеевскида макароннан – 10, ә «Доширак»тан 15 төрле ризык әзерли ала. Бу кешенең исеме – Ришат Шакиров,Татарстанның Менделеевск районы прокуроры ул. Без аның янына макаронлы-токмачлы мең төрле ризык татып карау өмете белән бардык. Әмма өметләр акланмады. Дөрес, тагын да шәбрәкләре бәрабәренә...

– Зарарлы ризык турында сүз дә була алмый! – дип өздереп әйтте прокурор. – Макарон диетасы студент чакта калды. Бүген исә – сәламәт ризык кына. «Спорт» салаты әзерләячәкбез. Мин үзем спортчы, сәламәт яшәү рәвеше алып барам, сезгә дә шуны киңәш итәм.

МАКАРОНЛЫ ДИЕТА

Дөресен генә әйткәндә, шул студентлык чорыннан соң плитәгә әллә ни якын килгәнем дә юк диярлек. Мин өлкән курс студенты белән бер бүлмәдә яшәдем, ашарга пешерү дүрт ел уку дәверендә гел минем өстә иде. Ул макаронны пешереп тәмам туйдым...

– Макаронлы ризыкларыгыз рецептларын санап китегез әле, зинһар.

– Майлы макарон, майсыз макарон. Йомырка салынган макарон, йомыркасыз макарон, макаронсыз йомырка... Яшелчә белән макарон. Помидорлы макарон... Коры доширак», сулы доширак... Беренче ашка доширак, икенчегә – макарон... Әлбәттә, рационны беraз төрлеләндерергә була, эти-әниләр акча биреп тора иде. Тик бу акчаларны без саклап кына тота идек, чөнки ял көннәрендә өйгә кайткач, йөргән кызыңны шул акчага туңдырма белән сыйларга, дискотекага алып барырга кирәк. Шуңа күрә студентлар элек ачлы-туклы яшәгән дигән сүз бер дә уйдырма түгел, ә чынбарлык. Без барыбыз да ач һәм бик төз гәүдәле идек.

– Макарон симертә, дип санала бит.

– Әгәр аны күп ашасаң, бәлки,симертәдер дә. Аз булганда, симермисең.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Салат яфраклары – 1 бәйләм;
- Аз тозлы сөләйман балыгы ите – 200 г;
- Фета сыры – 150 г;
- Кара төстәге зәйтүн җимеше – ярты банка;
- Черри помидоры – 15 данә;
- Бальзамик соусы – төменчә;
- Ярты лимон.

Фото: Александр Ефремов



1
– Хәзерге көнгә кадәр прокурор тормышында иң куркынычы – нәкъ менә шундый ихлас һәм юморлы блог алып бару дип уйлый идем. Моның нәрсә китереп чыгарасын кем белсен?.. Ә бүгеннән соң инде иң куркынычы – прокурорның алъяпкыч ябып, бөтен республикага үзенең аш-суга сәләтен күрсәтүедер, дип уйлыйм.

2
Кайчандыр иңгә погон тагып, менә шундый тормышны сайладым. Бездә, хокук саклау органнары системасында, телимтеләмим дигән нәрсә юк. Кая җибәрсәләр, шунда барасың. Боерыклар турында бәхәс куертылмый.

КЫРЫС ПРОКУРОРНЫҢ ИХЛАС БЛОГЫ

– Ниһаять, без ябыгуның гаҗәеп нәтиҗәле ысулын таптык! Ник сез аны үз блогыгызда әлегә кадәр язып чыкмадыгыз? Гомумән, мондый җитди һөнәр вәкиле ничек шулай блог алып барырга ниятләде икән, өстәвенә, ниндидер рәсми сәхифә түгел, ә игелекле, кешелекле, ихлас блог, әле юмор да кыстырып!..

– Хәзерге көнгә кадәр прокурор тормышында иң куркынычы – нәкъ менә шундый ихлас һәм юморлы блог алып бару дип уйлый идем. Моның нәрсә китереп чыгарасын кем белсен?.. Ә бүгеннән соң инде иң куркынычы – прокурорның алъяпкыч ябып, бөтен республикага үзенең аш-суга сәләтен күрсәтүедер, дип уйлыйм. Мин белгәннәремне дә оныттым инде. Өйдә хатыным әзерли. Хатын-кыз кулыннан яхшырак, тәмлерәк килеп чыга, чөнки тәҗрибәләре күбрәк – алар ешрак ашарга пешерә. Гомумән, аш-су әзерләү – авыр хезмәт ул.

– Сүзегездә кеше җенесенә бәйле ачыктан-ачык гаделсезлек күзәтелә: авыр хезмәтне нәфис хатын-кыз җилкәсенә йөклисез...

– Ашарга пешерү, җыештыру кебек авыр вазыйфаларны һәркем башкага күчерергә тели. Чыннан да шулай. Тик бүген бөтен авырлыкны үз өстемә алам, – ди дә Ришат Наил улы, пычак һәм такта алып, «Спорт» салатын әзерли башлый.

КИРТӘЛӘРСЕЗ

– Ә җитди сөйләшсәк, – дип дәвам итә ул. – Ник мин «Инстаграм»да үз блогымны алып бара башладыммы? Чөнки мөмкин кадәр ачыклык – төп эш принципларымнан берсе. «Киртәләрсез һөнәри багланыш» дигән гыйбарә бар. Бу вакытта теләсә кайсы кеше вазифаи затка теләсә нинди сорау бирә ала: район җитәкчесеме ул, полиция башлыгымы, прокурормы, йә булмаса журналның баш мөхәррирeме. Киләчәктә шулай булачак та, минемчә. Биш елдан соң бөтен өлкәгә дә кирәчәк ул. Әлегә мондый багланыш юк, шуңа күрә мин көтеп тормаска, үземнән башларга булдым. Кеше прокурорга сорау бирер өчен ник әле кабул итү көнен яки берәр җайлы очракны көтәргә тиеш, ди? Моны сорау туугач ук эшләргә була бит.

Аннары шунысы да бар – блогта прокурорның ни белән шөгыльләнгәнен барысы да күрә. Бу – эшебезне аңлату да, пропагандалау да. Мәктәп укучылары белән очрашканда, аларга һәрчак сорау бирәм: «прокурор» сүзен ишеткәч, акылга беренче нәрсә килә? Ул нинди сүз белән ассоциацияләнә: гаепләүме, әллә яклаумы? Барысы да гаепләү дип саный. Җәмгыятьтә, прокурор гаепли, гаеп эзли ул, дигән фикер яшәп килә. Югыйсә латин теленнән тәрҗемә иткәндә, «прокурор» сүзе «яклау, кайгырту» дигәнне белдерә. Һәм бу –

безнең төп функциябез. Гаепләү, штраф салу түгел, ә яклау! Әйе, кеше үтергән, караклык яки башка җинаять кылган затка каршы без судта гаепләү тарафына басабыз, тик параллель рәвештә зыян күрүчене яклыйбыз бит. Гаеплене гаепләп, зыян күрүчене яклаучы без. Гаеплене җаваплылыкка тартуга ирешеп, без зыян күрүчене генә түгел, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен дә кайгыртабыз. Җәзаның котылгысыз булу принцибы әнә шул рәвешле саклана. Кешеләр аңына сеңгән фикерне үзгәртү өчен, мин үзебезнең нәрсә белән шөгыльләнүебезне күрсәтәм. Һәм турыдан-туры вазыйфалардан тыш, без балалар белән дә очрашабыз, ветераннарга ярдәм итәбез, намуссыз эш бирүчеләр түләмәгән яки тоткарлаган хезмәт хакын алырга булышабыз, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә булышабыз...

Блогымда шулай ук спорт белән шөгыльләнүемне дә күрсәтәм. Ә анда җәрәхәтсез дә булмый: сеңерләр өзелү, кабырга сыну, кул чәрдәкләнү... Күрәсезме, менә иренне тектеләр, хоккейда алка әләкте аңа. Мондый җәрәхәтләр барысы да спортныкы. Болар һич тә читләштерми, ә сәламәт спорт дәрте, нәрсә дә булса килеп чыкмый икән, мин аны барыбер булдырам дигән теләк уята... Кешенең нинди дә булса мавыгуы булырга тиеш. Кемдер тегә, кемдер чигә, кемдер маркалар җыя. Мин исә хоккей белән мавыгам. Шуңа күрә бүгенге ризык та – «Спорт» салаты. Салат яфракларын алабыз да, матур булсын өчен, сабагын үзәккә каратып куябыз.

ФУРАЖКАСЫ – КОКАРДАЛЫ, АЕЛЫННАН – КҮЗ ЧАГЫЛА!*

– Бу һөнәрне ни өчен сайладыгыз?

– Мин үзем эшче гаиләдән. Әти-әнием Арчада яши. Гаиләбез, туганнарыбыз, дусларыбыз тормышында һәрвакыт юридик законнарны белмәү белән бәйле бик күп сораулар, авырлыклар туып торганын хәтерлим. Һәм әле балачакта ук, әгәр мондый юридик белемнәрне үзләштерсәм, туганнарыма һәм яраткан кешеләремә гап-гади мәсьәләләрне хәл итүдә булыша алачакмын, дип үзем өчен карар кылдым. Мин бик күп кешеләрнең, бигрәк тә авыл җирендә, ярдәмгә мохтаҗ икәнлеген күрдем – аларга киңәш биреп тә, хәтта кочаклап алып, юатып та ярдәм итеп була. Кыскасы, полиция хезмәткәре бөтен кешегә булыша ала дигән хис күңелгә кереп калган иде.

– Атаклы шигырьдәге милиционер дядя Степа кебекме?

– Әйе. Һәм мин юридик институтка полиция хезмәткәре булам дигән ныклы ният белән килдем. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтын тәмамладым. Ике ел полициядә тикшерүче булып эшләдем.



3
Бу районда кешеләр начар, ә монда яхшы, мөнысында – җинаятьчеләр, ә тегесендә законны бозмыйлар дип әйтеп булмый. Законга төкереп каручылар һәр җирдә дә бар. Ләкин андыйлар, Аллаһка шөкер, азчылыкны тәшкил итә.

4
Үзен бөтенләй яклый алмаучыларның авыр хәлдә калуы белән бәйле эшләр – иң катлаулысы. Балалар, өлкән яшьтәгеләр, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр турында әйтүем.

* Сергей Михалков. «Дядя Стёпа».

1 Матурлап җәябез

2 Турыйбыз

3 Сәгать теле уңаена тезәбез

4 Шакмаклап турыйбыз

5 Сәгать теленә каршы тәртиптә куеп чыгабыз

6 Урталай бүләбез

7 Түгәрәк ягын өскә куеп тезәбез

8 Зәйтүн җимеше белән бизибез

9 Лимон согы сыгабыз

10 Бальзамик соусы сибәбез

11 Теләк телибез

– Үз эшегездә иң авыры нәрсә дип уйлыйсыз? Ә иң рәхәте нәрсә?

– Теләсә кайсы эштә иң катлаулысы, бигрәк тә югары, җаваплы вазыйфа башкарсаң, намуслы һәм кешелекле булып кала белү дип саныйм. Башкаларның кайгы-борчуларына, чит проблемаларга ваемсыз булмау.

– Моңа ничек ирешеп булганлыгы турында бирәр нәтиҗәле киңәшегез бармы? Җирдә кешеләрнең кайгы-борчулары хәттин ашкан бит!

– Ешрак күктән җиргә төшеп, халык белән очрашырга, аларның ничек яшәгәнен, ничек көн күргәнен карарга кирәк. Аларның проблемаларын, берсен генә булса да, хәл итәргә омтылырга. Менә шул вакытта намуслы һәм тәртипле кеше булып каласың, минемчә.

Ә минем өчен иң рәхәте – кешеләр белән дусларча очрашып, ихлас гәпләшү. Мондый әңгәмәләр аша күп бәхәсләрне хәл итәргә мөмкин, киңәш белән булышып, бергәләп дөрес карарга килеп була.

НИНДИ МАТУР!

– Бик матур килеп чыкты, – ди Ришат Наил улы, салат ингредиентларын сәгать теле уңаена салып чыкканнан соң үз хезмәтенең нәтиҗәсенә сокланып. – Беренче тапкыр әзерлим – һәм шундый матур килеп чыга!

– Бездә күпләр беренче тапкыр әзерли. Аннан соң ул осталарыбызның хатыннары үз ирләренә ризык әзерләүнең тәмен белдергән өчен безгә рәхмәт әйтә. Яки күптән онытылган шул хисне кире кайтарган өчен...

– Әйе... Хәзер баш тартып булмаячак инде, – дип елмая прокурор, салатына лимон согы сибеп. – Мин лимонны бик яратам. Һәр иртә лимонлы су эчәм. Әгәр кешеләр лимонның файдасы турында барысын да белсә, аны тонналап ашар иде. Һәм без бик тиз лимонсыз калыр идек. Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә аны әче итеп ясаган да.

БАБАКАЙ ӨЧЕН АЛИМЕНТ

– Прокурорлык хезмәтегездә нинди эшләр иң катлаулысы санала?

– Үзен бөтенләй яклый алмаучыларның авыр хәлдә калуы белән бәйле эшләр – иң катлаулысы. Балалар, өлкән яшьтәгеләр, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр турында әйтүем. Әти-әниләре турында кайгыртмаган бәндәләргә каршы судка дәгъва белән мөрәҗәгать иткән очраклар да булды. Әйтик, яше 80нән узган бабай ялгыз кала, үзен карый алмый. Балалары үз тормышы белән яши, аны кайгыртмый. Безгә аның балаларын алимент түләргә мәҗбүр итәргә туры килде. Чөнки алиментны ваемсыз этиләр генә түгел, ә менә шундый балалар да түләргә тиеш... Яклаусыз гражданнарның хокуклары бозылуын күреп тору кыен. Хәзер балалары, барыбер карамаса да, этиләренә алимент

түли. Әлбәттә, ул-кызларның игътибарын һәм мәхәббәтен бернәрсә белән дә алыштырып булмый, тик, һәрхәлдә, бабай хәзер акчага мохтаҗ түгел һәм, кемне дә булса үзенә чакыртып, өен җыештырта, ашарга пешертә, кибеткә җибәрә ала...

КАЙСЫ РАЙОН ЯХШЫРАК

– Менделеевскидагы хокук бозуларның төп характеры Кукмарадагылардан аерыламы? Сез әле күптән түгел генә Кукмара районы прокуроры булган идегез бит. Бу ике район, аларның халкы ни белән аерыла?

– Мин Арчада тудым. Башта Биектауда, аннары Апаста, Кукмарада эшләдем, хәзер Менделеевскида – үз биографиямдә бишенче районда яшим.

Апаска җыенган чакта, Апас куркыныч район, диделәр. Кукмарага юл тотканда, анда барысы да хәллеләр, байлар, кешенең кешедә эше юк, дип әйттеләр. Менделеевскига китеп барганда, анда барысы да җинаятьчеләр дип куркыттылар. Һәркайсында да эшләдем һәм тулы җаваплылык белән әйтә алам: бөтенләй алай түгел! Кукмарада, Менделеевскида, Апаста күпчелек кешеләр бик дустанә, кунакчыл, законга буйсынучан – бар яктан да күңелгә хуш затлар. Әлбәттә, һәр районның үз үзенчәлекләре бар. Әмма бу районда кешеләр начар, ә монда яхшы, монысында – җинаятьчеләр, ә тегесендә законны бозмыйлар дип әйтеп булмый. Законга төкереп каручылар һәр җирдә дә бар. Ләкин андыйлар, Аллаһка шөкер, азчылыкны тәшкил итә. Кабатлыйм, инде бишенче районымда эшлим – чагыштырырлык нигезем бар.

– Кукмараны сагынасызмы?

– Әлбәттә, сагынам. Мин анда биш ел эшләдем. Дусларым, хезмәттәшләрем калды. Менделеевскида урынбасарым итеп Кукмара прокуроры урынбасарын билгеләгән өчен республика прокурорына рәхмәтлемен. Димәк, Кукмараның бер өлешен мин үзем белән алып киттем булып чыга, урынбасарым янәшәдә чакта, Кукмара да янәшәмдә дип тоям.


Дорогие читатели!
Нас, читающих журнал Татарстан, очень много – около 5 тысяч человек.
Представляем разные профессии и сферы жизнедеятельности.
Самое главное в жизни – оставаться человеком, какую бы должность ты не занимал.
Желаю вам всем легко справиться с этим!
С уважением,
прокурор Менделеевского района Республики Татарстан Р.Ш.Шакиров
27 января 2022 года

ПОГОННАРЫ – ИҢЕНДӘ, АЛТАТАРЫ – БИЛЕНДӘ

– Анда калырга теләмәдегезме?

– Кайчандыр иңгә погон тагып, менә шундый тормышны сайладым. Бездә, хокук саклау органнары системасында, телимтеләмим дигән нәрсә юк. Кая җибәрсәләр, шунда барасың. Боерыклар турында бәхәс куертылмый. Җитәкчелек мин бу районда кирәклерәк дип санаган икән, димәк, шул районга барам. Гаиләмдә хәлемә кереп, минем белән яңа хезмәт урынына күчеп йөргәннәре өчен рәхмәт. Хәзер 11 нче сыйныфта укучы өлкән кызым инде өченче мәктәбен алыштырды. Бишенче сыйныфтагы кечесенең бу – икенче мәктәбе. Хатыным, декабрист хатыны кебек, һичсүзсез миңа ияреп йөри.

– Әгәр сайлау мөмкинлеге булса, кайсы районда яшәп калырга теләр идегез?

– Бу хакта уйлаганым юк, тик әти-әнигә якынрак булырга теләр идем. Еллар уза бара, алар белән телефон аша гына аралашып калмыйча, үзләрен гел күреп, күн саен күзләренә карап сөйләшәсе килә. Өлкәнрәк булган саен, күңел туган якларга күбрәк тарта.

КЕМГӘ – ЯҢАЛЫК, КЕМГӘ – САЛАТ!

Шулай итеп, «Спорт» салаты әзер. Прокурор салатының хуш исенә хезмәттәшләребез – «Менделеевск яңалыклары» журналистлары да йөгереп килеп җитте. Алар өчен җирле прокурорның бик шәп аш-су остасы да булып чыгуы – үзе бер яңалык.

Аларга яңалык булса, безгә – салат! Барысы да гадел, барысы да закон кысаларында.

РИШАТ ШАКИРОВТАН АШ-СУ КИҢӘШЕ:

– Кәефем яхшы булганда, тәлинкәдә ризык кисәкләрен сәгать теле уңаена тезәм – ул чакта күтәренке кәефем әлеге салатны ашаучыларның барысына да күчә. Ә кәефем начар булса, сәгать йөрешенә каршы тәртиптә куям. Бу процесс минем кәефемне яхшырта, энергия өсти. Һәм һәркем канәгать булып кала.



МАРАТ КӘБИРОВНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Руфия Фазылова

Бу ковид дигәннәре тынычлыкны алды. Без аны башта шаяртыбрак, ышанмыйчарак, ышанырга теләмичәрәк кабул иттек. Хәзер инде шикләнүче юк бугай. Һәрхәлдә, мин шикләнмим. Авырып алдым. «Ашыгыч ярдәм» белән беренче тапкыр алып киткәч, өйдә генә дәваланырга дип кире кайтарганнар иде. Өч көннән соң тагын чакыртырга туры килде – үпкә зарарлануы 25 процентка җиткән. Хастаханәдәге табиблар мине сокландырды. Ходай үзләренә сәламәтлек бирсен. Чирне мин җиңел үткәрдем. Бөтен сызлануларым хатыным өчен булды. Аның үпкәсе 45 процентка зарарланган иде. Аны хастаханәдә калдырып киткәч, еладым. Аерылышкан чактагы мөлдерәмә карашлары күз алдымнан китмәде. Аллаһка шөкер, табиблар коткарып калды. Бәхет бит инде бу, бер карасаң.

Ковидны уйлап чыгарылган дип сөйлиләр, бу вакыйганың сценарие да төзелгән булган, диләр. Чыганакларын эзләп караганым юк. Минем моңа ышанасым килми. Кеше турында артык югары фикердә түгелмен, дип әйткәнем бар, анысы. Шулай да мин, барыбер, кешенең әйбәтлегенә ныграк ышанам бугай. Үзең ышанмаган чынбарлык ул беркайчан да дөреслек була алмый.

Бу бик зур акчалар китерә, дип тәфсилләп язалар. Әлбәттә, авыру таралгач, дару бәяләре генә дә ничек сикерде! Шәһәр транспортларында кодлар гамәлгә кергән көнне үк такси хаклары күтәрелде. Илгә килгән бәладә акча эшләү ул – мародерлык кебек нәрсә. Җәмгыять акча колына әйләнде. Менә монысы вирустан да хәтәррәк фаҗига. Кеше, үзенең кешелеклелеген югалтып, колланучыга әверелде.

Үзебезнең өлкәне генә алып карасак та, аңа син сары матбугат бир, җиңел укылышлы романнар бир, күңел ачудан ары китмәгән спектакльләр бир. Бөтен дөнья буенча шулай бу. Мин менә «бестселлер», «шедевр» дип тәкъдим ителгән китапларны укымый калмаска тырышам. Тик соңгы елларда аларда гел диярлек бушлык сизәм. Иң яхшы очракта – мавыктыргыч бушлык. Чын мәгънәсендә яхшы әсәрләр күләгәдә кала, хәтта басылып та чыкмый. Бу да начар. **Иҗатчы укучы зәвыгына көйләнергә тиеш түгел.**

Син бәйсез, диләр. Тик без, адәм балалары, бер-беребезгә шулхәтле нык бәйләнгәнбез, очраклылык дип уйлаган һәр нәрсәнең нигезендә шушы бәйләнеш ята. Мин иректә кеше. Ләкин бәйсез түгел. Мин бөтен кешегә караганда да ныграк бәйле, чөнки җаваплылык тойгысы белән бәйләнгәнмен. Язучы буларак та, шәхес, ир, эти буларак та. Телемә ни килә, шуны кычкырып йөрмим бит инде. Һәр сүзем – изге нияттән. Һәрбер сүзем өчен җавап бирәм. Әгәр җаваплылык тойгысы юк икән, ирек куркынычка әйләнә – ул фаҗигагә дә китерергә мөмкин.

Ә болай яшәүнең авырлыгы-җиңеллеге турында... Авыр. Һәм җиңел дә. Җанга җиңел. Ә җитәкчелек тарафыннан нинди дер әзәрлекләүгә дучар булганым юк. Монысы да бик мөһим. Һәр язучының иректә булуга

Фото: Рамиль Гали

мөмкинлеге бар, дигән сүз бу. Һәрхәлдә, хөкүмәт моңа киртә куймый.

Татарстанга Башкортостаннан бик күп иҗатчы килә, чөнки анда татарлар бик күп яши. Аннан соң, талантларның асыллары, үзенә ышанганнары килә. Үз оясын бер максатсыз гына калдырып китми бит алар. Аның әле туган ягы алдында да исәп-хисап тотасы бар. Киткән һәрбер иҗат кешесенең өстендә: «Үзеңне әллә кемгә санап, Казанга киткән булган идең, йә әйт инде, нәрсәгә ирештең?» дигәнрәк сорау тора. Шуңа күрә Казанга китү ул яшәү урынын алыштыру гына түгел. Казан бит ул Татарстанның башкаласы булу белән беррәттән, бөтен татар дөньясының үзәге дә. Калганнары – провинция, хәтта Мәскәү дә.

Күптән инде интернетта китапларымны сатам. Төрле кешеләр бар: иганәчеләр эзләп, теләнеп йөрүчеләр дә, хөкүмәттән таләп итүчеләр дә, зарланучылар да... Бу бик отышлы нәрсә, тик мин шул «әйбәт» гадәтне үзләштерә алмадым. Шуңа үз проблемаларымны үземә хәл итәргә туры килә. Китапларым чыкмый башлагач, Уфада чакта инде, аларны электрон вариантта укучыга җиткерү уе туды. Сайт ясадым. Әсәрләремне куйдым. Яратып укучылар, мактаучылар күбәйгәч, бушлай булганга гына шулай инде, түләүле булса, беркем дә сатып алмас иде, дип уйладым. Һәм интернетта электрон китап кибете булдырдым. Алдылар, укыдылар. Әле дә укыйлар. Хәзер мактаучы сирәк инде: безнең татарда шундыйрак гадәт бар бугай – акча түләп алган нәрсәне хурламый калсаң да, ул мактау кебек кабул ителергә тиеш. Ә чынында мин үземнең даими укучыларыма бик рәхмәтлемен, Аллаһка шөкер, алар күп. Язучының иң зур байлыгы – аның укучылары.

Бүген ни дип кенә хурласак та, совет чорында кешенең рухи үсешенә игътибар көчле иде. Рухи үсешнең нигезе – әдәбият. Шулай булгач, язучылар өчен шартлар ул дәвердә бик яхшы булды. Бүген вазгыять бүтән. Гонорарлар – адәм көлкесе. Мин бер журналның ике санында басылып чыккан повесть өчен бер мәлне биш мең сум гонорар алдым. Андый әсәрне язу өчен иң талантлы кеше дә башын күтәрмичә ким дигәндә ике ай эшләргә тиеш. Һәм шуның өчен – биш мең. Бу – хезмәт өчен түләү түгел инде, ә язучыга мөнәсәбәт. Димәк, халыкның рухи үсешенә дә мөнәсәбәт шул чама гына.

Хәлләрне бөтенләй үк өметсез дип тә булмый. Соңгы елларда һәртөрле әдәби бәйгеләр оештырыла. Татарстан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе уздыра аларны. Мин моны бик яхшы күренеш дип саныйм. Алар даими булсын, күп булсын. Бу әдәбият үсешенә дә яхшы йогынты ясый, бәйгедә җиңгән авторларның матди хәлен дә җиңеләйтә. Мин инглиз, француз, немец әдәбиятларын даими күзәтеп барам. Аларда әдәби конкурсларның чиге-чамасы юк. Күпләре хәтта географик яктан да чикләнми. Әгәр шул телләрдә яза белсәм, мин дә катнаша алам. Гади генә хикәя конкурсларының призы 500-1000 доллардан башлана. Романнар – 50-100 мең доллар тирәсендә. Өстәвенә, әсәрләрне нәшриятлар бастырып чыгара да авторларына гонорар түли. Америка да, Европа илләре дә үз әдәбиятын үстерү һәм таныту буенча җитди эш алып бара. Бу илләрнең дөнья җәмгатьчелегенә тәэсире көчле икән, монда әдәбиятның да өлеше зур. **Әдәбият ул күңелләргә күпер салу чарасы да.**

Авторларга юньле гонорар түли торган илдә булсам, мин инде күптән миллионнарда коенып яшәр идем. Шулай да ачтан үләрмен, дип уйламыйм. Мин күп эшлим. Татарның иң популяр җырчыларының бик күп «хит»лары минем сүзләргә. Концерт сценарийлары язам, анда минем юмористик яки лирик әсәрләр яңгырый. Театрлар белән хезмәттәшлек итәм. Татарстан һәм Башкортостан газета-журналларында махсус рубрикалар алып барам. Берничә әдәби журналда ел саен ниндидер повестем басыла, электрон китап кибете уңышлы эшли. Даими эш урыным да бар: республиканың төп газетасы – «Ватаным Татарстан».

Әсәрләремдә фантастик элементлар күп булса да, чиста гына фантастик әсәр дип әйтерлек әйбер язганым юк. Язасым да килми. Тиз искерә хәзер фантастика. Станислав Лемны мин бик яратам. Ләкин аның ерак киләчәктә полароид белән фотога төшереп йөргән персонажлары... Башка фантастлар да шундый ук. Минем «Китап» дигән роман бар. Унбиш еллар элек язылган инде. Хәтта андагы әйберләр дә хәзер фантастика булып тоелмый. Кайберләре кулланышка керде. Акыллы йорт, мәсәлән. Голограмма белән бәйле әйберләр... Кайберләре искерде. Сыек дисклар... Хәзер бөтенләй андый төшенчә юк. Мин ул романны яңадан бастырсам, күп нәрсәләрне үзгәртергә тиеш булачакмын.

Ә хоррор әсәрләре... Дөньяда иң популяр жанр бу! Россиядә алай ук түгел. Чөнки безнең чынбарлык һәм телевидение, кайбер матбугат чаралары тараткан яңалыклар теләсә нинди куркыныч әсәрне дә икенче планга калдыра. Чит илләрдә бу жанрны адреналин кузгату өчен үз итәләр. Татарда бу жанрны яратучылар бар – монысы бәхәссез. Үсмерләр, яшьләр, өлешчә 25–45 яшьләр тирәсендәгеләр. Мондый әсәрләрне, нигездә, ир-егетләр

үз итә. Дөнья буенча статистика шундый. Ә бездә – хатын-кызлар. Гомумән, соңгы елларда мин бер нәрсәне аңлыйм: татар ир-егетләре татарча китап укымый бугай... Хәтта русча китап укучыларның 65 проценты хатын-кыз, диләр. Ирләрнең 35 проценты укый булып чыга. Миңа калса, татарда алар 15 проценттан да артмый. Моны электрон китап кибетендәге күпьеллык күзәтүләр нигезендә әйтәм. Минем кибеттә шулай бу. Югыйсә, минем әсәрләрнең төп укучысы ирләр булырга тиештер кебек. Аларда – кырыслык, аяусыз киеренкелек, бераз тупаслык, кул сугышлары, атышлар, хәтта фәлсәфә, мәхәббәткә караш та – гомумән, анда барысы да ирләр өчендер кебек. Гаҗәп инде.

Мәхәббәт турында гына язучы авторлар бар. Кемдер детектив, кемдер фантастика, кемдер куркыныч сюжетлы әсәрләр, кемдер антиутопия гына яза. Шигырь генә язучылар бар. Җыр текстлары язып кына әллә кем булучылар бар. Ә мин, балалар әдәбиятыннан кала, бөтен жанрларда да язам. Укучыларым арасында яшьләр дә, урта буын вәкилләре дә, өлкәннәр дә бар. «Бердәнбер һәм кабатланмас» романын, мәсәлән, 90 яшьлек әбиләргә кадәр тетрәнеп укыган. Ә «Китап»ны 50 яшьтән өлкәнрәкләр кабул итә алмады. Югыйсә, бу романнарның икесе дә хоррор жанрына карый торган роман инде.

Дөнья беркайчан да мин дигәнчә генә бармады. Элек моңа үртәлә идем. Хәзер өйрәндем инде. Ходай миңа гел юл күрсәтеп торды, авыз турсайтып, үпкәләп утырырга мөмкинлек бирмәде. Безнеңчә бармаган чагында да ул бик үк начар дөнья түгел.

Менә узган елның декабрендә, коронавирустан соң, мин кулларны, бармакларны бөкләп компьютерда да яза алмас хәлгә килдем. Кызыкмы? Кызык түгел! Мин сыңар аягында иллешәр тапкыр чүгәли ала торган егет... Баштүбән басып кулларында йөри ала торган... Һәм кинәт – аякларында да юньләп атлый алмаган ир. Ышанасым килмәде. Шундый кеше шул хәлгә төшәргә мөмкинме, дип уйладым. Мөмкин икән. Шулай төшенкелеккә бирелеп хастаханә коридоры буйлап атлаганда юлыма кулсыз, аяксыз, хәтта инвалид арбасында йөрүче кешеләр очрады. Һәм мин аларга карап: «Аллаһка шөкер! Минем хәлем күпкә әйбәтрәк икән әле», – дидем. Чөнки аларның хәле аянычрак иде.

Нинди генә үрләр яуласак та, бездән югарырак менә алучылар бар. Нинди генә кыен хәлгә калсак та, бездән дә авыррак яшәүчеләр бар. Менә шуны аңлый алу бәхеткә дә, кайгыга да түзәргә ярдәм итә.

Гаилә мөнәсәбәтләренә килгәндә... Юньле хатын үз ихтыяҗларын гына кайгыртмый, ә бөтен гаилә турында хәстәрлек күреп сүз әйтә. Ирләр барысын да исәпләп бетерә алмый. Ә гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне аналар ныграк аңлый. Шуңа күрә хатын сүзенә колак салмыйча берничек тә мөмкин түгел. Мин хәзер тулы ышаныч белән әйтә алам: хатынымнан уңдым. Ул мине бәхетле ир, әйбәт кенә язучы итте. Һәр әйбәт әсәремнең автордашы ул шикелле тоела. Һәр әсәремне иң беренче ул укып чыга. Мин ашханә янындагы юлчылардан пирожки көткән эт шикелле, күзләремне мөлдерәтеп, аңардан мактау көтәм. Ә мактау гел эләкми... Ул һөнәре белән әдәбият укытучысы бит, бик әйбәт укытучы. Тәнкыйтьли дә, тик бу дошмани тәнкыйть түгел, ә әсәрне яхшырту хәстәрлеге. Мине укыганда ул үзе дә иҗатчыга әйләнә. Аның сүзенә колак салмый булмый.

Хатын баш дип аталамы ул, муенмы – һәркем үз урынында булырга тиеш. Менә мин идән юарга иренәм, кер юа белмим, өй җыештырырга яратмыйм. Кайчагында хатын кайтуына бик тырышып җыештырып куям өйне – тик барыбер нидер җитмәгән шикелле. **Ул кайтып берничә генә хәрәкәт ясый – өй балкып китә. Хатынсыз өйнең нуры юк аның. Дөнья белән нур идарә итә, ә ул хатын-кыз кулында.**

Мин әтисез үскән кеше, шуңа нинди әти булырга да белмәдем инде. Бик күп хаталар да киткәндер. Олы улыма каеш та эләккәләде. Өлкәннәр үрнәгендә инде, дусларымның әтиләре сыман кыланган булдым. Бәләкәенә тырнак белән дә чиртмәдем. Шулай кирәк булгандырмы-юкмы, хәзер берни дә әйтеп булмый. Тик мин нинди очракта да аларны шәхес буларак югалтмаска омтылдым. Аларның мин дә, әнисе дә түгел, ә үзгә бер кеше икәнлекләренә үзләрен дә, үзебезне дә ышандырырга тырыштык. **Улларыңа ышанырга**

кирәк, аларның үз-үзенә ышанычын ныгытып торырга кирәк. Моны этиләр генә эшли ала. Бәлки, этиләрнең төп бурычы улларын үз көчләренә ышандырудыр. Бүген мин улларымнан канәгать. Без аларны ким-хур булырлык итеп үстермәдек, бәхетләрен Ходай үзе бирсен.

Сәламәт яшәү рәвешенең нәрсә икәнен беркем дә белми. Менә минем бер танышым аракысын ташлады, тәмәкесен ташлады, көн дә иртән йөгерә, көндезләрен гер күтәрә. Һәм инфарктка юлыкты.

Мин дә хәзер режим белән ашыйм. Теге ризык ярамый, монысы ярый, дип сайланам – диета тотам. Физик күнегүләр ясыйм. Аракы эчмим, тәмәкене сирәгәйттем. Төннәрен йоклыйм. Таңнан торам. Тәртип белән эшлим. Эш арасында гимнастика ясап алам, йә җәяү йөреп килəм. Моны «сәламәт тормыш рәвеше» дип әйтәләр инде. Әкият! Авыру кеше алып барырга тиешле тормыш бу. Мин дә авырган өчен генә шулай яшәргә мәҗбүрмен. Чирле кешеләр алып бара торган тормышны сәламәт тормыш рәвеше дию гомерне мыскыл итү кебек яңгырый. Сау-сәламәт кеше чирлеләр тормышы белән яшәргә тиеш түгел. Үзеңне, мөмкинлекләреңне чикләргә ярамый. Үзеңне чикләү, яки теләмәгәнеңне эшләргә мәҗбүр итү – үзе үк бер чир кебек нәрсә.

Сәламәт яшәү рәвеше ул – үз организмың белән дус булу. Мин моны хәзер генә аңлый башладым. Элек ул организмны бар көченә эшләттем, кирәк-кирәксез нәрсәләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр иттем. «Сагындым. Кайт инде...» повестен мин ике атнада яздым. Бер көн йокламыйча. Юньләп ашамыйча. Хатын: «Үләсең бит инде», – дип тирги иде. Мин елмаеп кына куям, чөнки язу ул үзе көч бирә. Мин вокзалда поезд көтеп бер төн уздырсам да эт булып арыйм, ә язганда алай түгел. Ике атна буе йокысыз һәм бер арусыз. Ходайның бирәр хикмәтедер инде бу. Көз ахры иде. Әсәрне тәмамлагач, җиңелчә генә киенеп урамга чыктым. Сары яфраклар күрәсем килгән иде, ә анда инде бар дөньяны кар күмеп киткән. Күңелне сагыш басып алды. Сагыну. Көзнең алтын чагын бугай... Дөнья алтыннан көмешкә әйләнгәндер кебек тоелды. Әллә нинди сәер халәт инде... Һәрбер әсәрдән соң шулай була ул, син бер үлчәмнән икенчесенә күчкән шикелле... Менә мондый чакларымны мин әле дә сагынып искә алам. Организмны мәҗбүр итү түгел бу. Аның мөмкинлекләренә иярергә тырышу.

Менә без белер-белмәс көйгә, каратист булабыз, дип, штакетник, кирпеч вата идек. Күп очракта сынмый да әле ул, кул кырые яки терсәкләр генә оеп авырта. Бармаклар

хәрәкәтсез калгач, алар сызлаган саен мин: «Ни пычагыма кирәк булган ул?» – дип, шул чакларны искә төшердем. Ул кадәр кыланырга кирәкмәгән инде, бу организмны көчләү булган.

Сәламәт яшәү рәвеше миңа шулайдыр кебек тоела: үз юлыңны сайла да шуның буенча бар, бөтен булмышыңны шуңа буйсындыр, чөнки бу – синең язмышың. Син үз максатыңа ирешергә телисең икән, барысын да дөрес эшләячәксең. Сәламәт тормыш ул – үкенерлек нәрсәләреңнең азрак калуы. Берьюлы берничә юлдан барып булмый. Калган бөтен шөгылең дә – икенчел. Шуны аңлаган кеше үз организмын көчләми. Мин соң аңладым. Минем бөтен юлдан да берьюлы барасым килде. Беренче булып. Алай булмый икән. Әдәбиятта бөтен юнәлешләрне колачларга тырышуым да шуның нәтиҗәседер, бәлки. Бу миңа кайчагында нәфес кебек тә тоела. Ярый әле югары дәрәҗәдәге түрә булмаганмын, миннән дә комсызрак карак табылмас иде, дип уйлап куйганым да бар.

БЕЛЕШМӘ:

Марат Рафил улы Кәбиров 1970 елның 23 августында Актаныш районы Чуракай авылында туа. Әтисе үлгәч, әнисе үзенең туган ягы – Башкортостанның Илеш районы Сеңрән авылына кайтып китә. Булачак язучы шунда сигезьеллык мәктәпне тәмамлый. Аннан Югары Яркәйдәге һөнәр училищесында белем ала.

1990 елда Башкорт дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә. Ләкин аны тәмамламый. Шул елларда газета-журналлар белән хезмәттәшлек итә башлый. Аннан Башкорт дәүләт педагогика институтына укырга керә, читтән торып татар филологиясе бүлеген тәмамлый.

Язучылык эше белән бергә, төрле чараларга сценарийлар, көлкеле монологлар, җыр текстлары яза. Концертлар алып бара.

Бүгенге көндә актив иҗат итә. Роман, повестьлары – иң күп укылган әсәрләр арасында.

1

ӘТИ СҮЗЕ

Руфия Фазылова

Татарда тирән мәгънәгә ия «ир канаты астында яшәү» дигән гыйбарә бар. Хатынын, балаларын кайгыртып яшәүче, чын ирләргә карата кулланыла ул. Тагын әле «әти сүзе» дип тә әйтәләр. Монысы исә хәлиткеч вакытларда ата кешенең сүзен өстә калдыру була. Спас районы Иске Рәҗәп авылында яшәүче Фәйзиевләргә әлеге гыйбарәләрнең икесе дә туры килә.

«СОЛДАТТАН КАЙТКАН ЕГЕТЛӘР РӘХМӘТ ӘЙТЕРГӘ КИЛДЕ»

Гаммәр абый белән Мәсгудә апа Фәйзиевләр ике ул, бер кыз тәрбияләп үстергән. Төпчек уллары Илнур төп нигездә калган, ә өлкән уллары Рафаэль Сызрань шәһәрендә баш хәрби комиссар булып эшли. Кызлары Әлфия Спас районың Урта Йорткүл авылында гомер итә. Балаларның барысы да гаиләле, инде күптән үзләре әти-әни булган.

Әлеге гаиләне төрле яклап ачарга була. Бик кызык очрак – әти-әнидән башлап, балаларның һәркайсы булачак хәләл җефетләре белән бер сыйныфта укыган. Дуслык мәхәббәткә әйләнгән... Тик, аннан бигрәк, бу гаиләдә чын ирләр тәрбияләнгән. Ә эшнең башында әти кеше – Гаммәр абый тора.

Мәктәпне тәмамлап, бәхет эзләп туганнары янына – Үзбәкстанга чыгып китә ул. Бер елдан егет кире туган ягына әйләнеп кайта – хәрби хезмәткә чакыралар. Менә шунда егет хәрбиләр тормышына чын-чынлап мөкиббән китә.

– Венгриядә хезмәт иттем мин, – диде Гаммәр абый. – Яхшы хезмәт өчен миңа кече лейтенант дәрәҗәсе бирделәр. Шуңа да, армиядән кайткач, район үзәге хәрби комиссариатына эшкә алдылар. Серле кабинетның җитәкчесе идем. Моның ни дәрәҗәдә җаваплы вазыйфа икәнен аңлатып торырга кирәкмидер... Аннан соң милициядә биш ел эшләдем. Шуннан Иске Рәҗәп урта мәктәбенә физкультура укытырга чакырдылар. Мин ризалаштым.

Бу урында шуны әйтергә кирәктер: Гаммәр абыйның хәләл җефете Мәсгудә апа Иске Рәҗәп урта мәктәбендә математика укыта. Шуңа да аңа мәктәп тормышы якын була. Ул арада читтән торып КДПИның тарих факультетын тәмамлый. Ләкин хәрби өлкәне ташламый – тарих белән бергә хәрби хезмәткә өйрәтү дәресләрен дә алып бара. Гаммәр абыйның укытучы стажы – утыз өч ел. Хәрби дәрәҗәсе буенча капитан ул. РСФСРның мәгариф отличнигы да.

– Без эшләгән чорда патриотик тәрбия көчле иде бит, – дип сүзен дәвам итте Гаммәр абый. – Нинди генә чаралар оештырмый идек. Минутка автомат сүтеп җыю дисеңме... Хәрби хезмәттән әйләнеп кайткан егетләр өйгә килеп: «Гаммәр абый, зур рәхмәт. Сез өйрәткәннәр армиядә бик кирәк булды.

Фото: Илнар Әметбаев

Шундый яхшы әзерлек белән килгәнбез», – дип әйтә иде.

Фәйзиевләр өйләренең бер бүлмәсенә кечкенә генә музей да ясап куйган. Диварда – хәрби киемнәр, дәүләт бүләкләре, гаилә фотолары, Мәсгудә апа чиккән кул эшләре... Гаилә ядкарьләре булудан тыш, бу нигездә зыялы, белемле гаилә яшәвен күрсәтә торган әйберләр дә алар.

САБАК

Әйткәнемчә, Фәйзиевләр өч бала тәрбияләп үстергән. Әлфия белән Рафаэль үсеп бетте дигәндә, Мәсгудә апа тагын бер ир бала алып кайта. Малайга Илнур дип исем кушалар. Мөгаен, ул чагында алар картлыкларын шушы төпчек уллары янәшәсендә узар дип уйламаганнардыр. Ә бәлки киресенчәдер...

– Балаларның өчесе дә мәктәптә бишкә генә укыды, – диде бер горурлык белән Гаммәр абый. – Без аларга бармак белән дә чиртмәдек. Әби, бабай тәрбиясе дә йогынты ясагандыр, бергә яшәдек бит, тәртипле, тыңлаучан бала булдылар. Әлфия белән Рафаэль үсеп, мәктәпне тәмамлагач, безнең яннан чыгып киттеләр. Ул чакта: «Әле ярый Илнурны алып кайтканбыз», – дип сөенеште инде.

Әлфия әнисе һөнәрен сайлый – КДПИның математика факультетына укырга керә, ә Рафаэль этисе юлыннан китә. 1986 елда Казан хәрби артиллерия училищесын тәмамлый. Шуннан яшь егет Кавказга хезмәт итәргә китә. Әни кеше улы өчен бик борчылса да, Гаммәр абый улының нинди һөнәр сайлаганын аңлый һәм шуңа күңеле белән риза була. Ананың догалары кабул була – Рафаэль имин генә Кавказда хезмәт итә. Яшь хәрбигә Иске Рәҗәптән берьюлы ике хат килеп тора – этиәнисеннән һәм сыйныфташы, сөйгән кызы Гөлназдан... Чираттагы ялына кайткач, егет кызга тәкъдим ясый.

– Туксанынчы еллар иде ул, - диде Рафаэль абый. – Илдә тотрыксызлык. Шулай да туй ясарга мөмкинлек таптык. Әти-әнигә рәхмәт, гел без дип яшәделәр. Гаиләле булгач, мине Самара өлкәсенә күчерделәр. Инде менә гомер уртасына җиттек, һаман да шул якның суын эчәбез. Бүгенге көндә Сызрань шәһәрендә баш хәрби комиссар булып торам. Гөлназ белән бик күп дуслар таптык, татар гаиләләре белән дә аралашабыз, берберебезгә кунакка йөрешәбез.

Рафаэль абый белән Гөлназ апа ике ир бала үстергән. Олы уллары өйләнгән, үз тормышы белән яши. Ә кечкенәләре әлегә үзләре янында. Ике балалары да хәрби хезмәттә булган.

– Ир балалар булгач, тәрбияне күбрәк үзем бирергә тырыштым, – диде Рафаэль абый. – Әти кебек.

– Ә этиегез ничек тәрбияләде? – дим.

– Акыл белән. Әти белән әни – мәктәп дәресләрен генә түгел, тормыш сабакларын да өйрәтүчеләрем. Күңелдә гел йөртә торган бер мисал китерәм. Унынчы сыйныфта укыйм. Әти кушуы буенча, төне буе пилорамада такта ярдым. Өйгә иртәнге бишенче яртыда гына кереп яттым. Иртән торгач, этине кисәттем: «Дәрескә әзерләнергә вакыт булмады, бүген миннән сорамассың инде». Төнлә йокламау үзен сиздерде: дәрес барганда йоклап-йоклап китәм. Берзаман партадаш малай төртә: «Рафаэль, сине тактага чакыралар». Әллә нишләп киттем: эти әзерләнмәгәнемне белә бит! Нишлисең, укытучы чакыргач чыгасың. Нәрсә истә калган, шуны сөйләдем... Өйгә кайткач, эти әйтә: «Улым, молодец, дәрестә бүген югалып калмадың. Тормышта төрле чаклар була, һәр очрактан чыгу юлын табарга кирәк...» Шулвакыт этигә булган үпкәм бер секунд эчендә юкка чыкты. Әле киресенчә, этинең йөзенә кызыллык китермәвем өчен горурлык хисе барлыкка килде.

1
Фәйзиевләр гаиләсе

2 3
Иске Рәҗәп урта мәктәбе.

4

Рафаэль Фәйзиев полковник дәрәҗәсенә ирешкән.

5

Гаммәр абый төпчек улы Илнур белән бер нигездә яши.

6

Илнур Фәйзиев кечкенәдән танк рәсемнәре, уенчык танклар җыя. Коллекциясен әле дә тулыландырып бара..

«ЧЫНГА АШМАГАН ХЫЯЛ»

Рафаэль абыйсы хәрби юлны сайлагач, Илнурның да аның кебек хәрби киемнән йөрисе килә. Менә ул туган авылына кайтып керә, иңендә погоннар... Сыйныфташ кызы Гөлназлар тирәсеннән дә бер әйләнеп узар... Шуңа да, мәктәпне тәмамлагач, Казан танк училищесына барырга хыялллана. Тик уку елы беткәндә Илнурга абыйсы әйтә куя: «Татарларда төпчек малай төп йортта кала. Әти белән әнине ничек итеп үзләрен генә калдырып чыгып китәсең?!» Әлбәттә, Илнурның кәефе кырыла. Балачак хыялы бит! Кечкенәдән танк рәсемнәре, уенчык танклар җыя. Хәтта танкка утырып йөрүләре төшләренә дә керә. Тик... Үлчәүнең икенче ягында – өлкәнәеп баручы әти белән әни... Хәрби һөнәр сайлаган абыйсы гел еракта. Апасы тагын кырык чакрым ераклыктагы авылда, аның үз тормышы. Әлбәттә, танк училищесына китсә дә, әти-әнисе каршы түгел. «Үзеңә кара», – диделәр бит. Тик аларны ялгыз калдыру дөрес булырмы соң? Нишләргә? Шактый уйлаганнан соң Илнур ныклы карарга килә – укытучылыкка барырга кирәк. Югары белем алганнан соң әти-әнисе янына кайтыр. Гаилә корыр. Әти-әнисенә картлык көннәрендә таяныч булыр. Абыйсы Рафаэль бу карарны ишеткәч, энесенең иңеннән кага: «Бик киясең килсә, мин сиңа хәрби форманы биреп торырмын».

Ният тормышка аша – бүгенгесе көндә Илнур Фәйзиев хатыны Гөлназ белән Иске Рәҗәп төп белем бирү мәктәбендә эшли, әти-әнисе белән бер нигездә яшиләр. Гаилә башлыгы – директор, җәмәгате исә – татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Берсе КДПУның физика факультетын, икенчесе АДПУның педагогика факультетын тәмамлаган. Олы уллары Илназ Казанда эшли, кечкенә малайлары Таһир алтынчы сыйныфта укый.

– Сыйныфташ кызга өйләнү әтиегезне, абыегызны кабатлау булмадымы? – дип шаярткан булам.

– Юк, бу очраклы шулай туры килүдер (көлә – Р.Ф.). Балалар бакчасында ук Гөлназга күз төшердем. Үсә төшкәч Гөлназны ныграк ошаттым. Тик әни сыйныф җитәкчебез, әти дә мәктәптә укыта. Алар алдында кая инде кызлар белән сөйләшәсең. Шуңа күрә мәктәп елларында безнең арада фәкать дуслык иде.

Гаилә башлыгы үзенең эш бүлмәсенә чакырды. Өстәлдә компьютер тора, бер кочак кәгазь өелгән. Һәм шунда ук зур шкаф. Ә анда төрле-төрле уенчык танклар тезелгән.Ниндие генә юк аларның! Танклар коллекциясен әле дә тулыландыра икән...

– Димәк, танкист булу теләге күңелегездә калды? – дим.

– Калды... Балачак хыялы булып калды. Тик мин үкенмим, ихластан әйтәм. Укытучылык эшен дә бик яратам. Иске Рәҗәп мәктәбенә директор итеп билгеләнүемә өч ел булды. Хатыным да укытучы булгач, ул мине, мин аны аңлап яшибез.

...Анасына карап, кызын коч, атасына карап, улын сөй, ди халык. Фәйзиевләр гаиләсенә бик туры килә бу. Әлеге гаиләдә ир-атлар тәрбияле, зыялы, тырыш. Иң сөенечлесе – үзләре дә икешәр ул үстергән. Димәк, чын ир-атлар династиясе дәвам итә.

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ислам **НИЧЕК** җирле уңай традицияләрне үзенә сеңдерә

Галимҗан Ибраһимов тарихта **НИНДИ** эз калдырган

Безнең киштәдә **НИЛӘР** бар

100 еллык авыл **НИЧЕК** яши



РӘФЫЙК МӨХӘММӘТШИН: «ИСЛАМНЫҢ УНИВЕРСАЛЬЛЕГЕ ҖИРЛЕ УҢАЙ ГАДӘТЛӘРНЕ ҮЗЕНӘ СЕҢДЕРЕРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРГӘН»

Урта Идел буенда исламның таралуы турында безнең хәбәрчебез Россия ислам институты ректоры белән әңгәмә кора.

922-2022
1100-летие принятия Ислама Волжской Булгарией

– Ислам безнең территориягә моннан мең ел элек килеп, асылда күпме халыкның яшәү рәвешенә әйләнгән. Катгый кануннарга ия дөнья религиясе үз традицияләре, үзенчәлекле мәдәнияте булган җирдә төп дингә әверелгән. Бу ничек шулай була алган?

– Монда исламның төрле карашларны рөхсәт итә һәм төрледән-төрле милли һәм төбәк элементларын сеңдерә алган чагыштырмача түземлелеге төп рольне уйнаган. Идел буе – моңа мисалларның берсе. Төбәкнең географик урыны кайбер мөселман йолаларын үтәүдә аерым үзенчәлекләрнең буласын күз уңында тота. Мәсәлән, Багдад хәлифәсе Җәгъфәр әл-Мокътәдир илчелеге сәркатибе Ибне Фазлан 922 елның җәендә Идел буе Болгарына килгәч, классик кануннар буенча биш вакыт намаз уку мөмкинлеге булмавына бик гаҗәпләнә: кыска җәйге төннәрдә мөселманнар ястү намазын ахшам белән бергә укырга тиеш була.

Әмма төп үзенчәлекләр, һичшиксез, географик факторларга бәйле булмый. Шунысын аңлау мөһим: Көнчыгыш Европада, шул исәптән Идел буенда, исламны тарату мөселман дөньясы кысаларын территориаль яктан киңәйтүне генә аңлатмый. Беренче чиратта универсаль дини мохитне формалаштыру, аның сыйфат ягыннан башка халәткә күчүе дәвам итә. Ислам цивилизациясе үз чикләрен киңәйтү процессында гарәп телле дөнья чикләреннән һәм офыкларыннан чыга. Өстәвенә, әлеге процесс ислам Идел буена үтеп кергәнче үк башлана. Ислам фарсы-һинд, төрки (Урта Азиядә) мәдәни ареаллары казанышларын үзенә сеңдерә, һәм мөселманнар инде уртак мәдәни шартларда яши кебек. Шуңа күрә төрки дөньяда исламның таралуын алга таба да мәдәни һәи рухи экспансиянең чагылышы буларак карарга мөмкин. Ислам кайбер традицияләрне канунлаштыра, ләкин шул ук вакытта шундый зур киңлектә мөселманнар тормышын бөтенләй унификацияләү турында сүз дә була алмый. Мөселман җәмгатьчелеге исламга кадәр яшәп килгән күп кенә җирле гадәт һәм йолаларны танырга мәҗбүр була.

– Кайбер гадәт һәм йолалар барыбер мәҗүсилек системасына карамый. Мәҗүсилеккә мөнәсәбәт гомумән алганда шулай ук лояль буламы?

– Мәҗүсилек белән исламның көрәше, башка барлык урта гасыр дәүләтләрендәге кебек үк, аяусыз була. Идел буе Болгар дәүләтендә мәҗүсилек культына каршы көрәш бирегә ислам үтеп кергәннең беренче көннәреннән үк башлана. Ибне Фазлан Болгар хакиме Җәгъфәр бине Габдуллаһның үз кардәшләре арасында исламны тарату өчен иң кискен адымнарга әзер булуына игътибар итә: «Чыннан да, кодрәтле һәм бөек Аллаһ Тәгалә миңа исламны һәм дин кардәшләрем белән хакимлек итүне тапшырды, һәм мин, Аллаһ колы, үземә йөкләнгән эшне башкарырга тиеш. Һәм бу юлда миңа каршы килгәннәрне хәнҗәрем белән җиңәчәкмен».

Мәҗүсилек һәм аның нәтиҗәләре белән көрәш бер генә гасыр дәвам итми әле. Җирле болгар халкы, үз бабаларының динен саклаудан бигрәк, ислам тарафыннан мәдәни мирасларының да танылуына омтылган, дип гөманларга мөмкин. Исламның универсальлеге җирле уңай гадәтләрне үзенә сеңдерергә мөмкинлек биргән. Әлбәттә, алар диннең төп кануннарына каршы килмәгән һәм үз заманының таләпләренә җавап биргән очракта.

– Диннәр тарихы шуны күрсәтә: халыкны иманга китерү һәрвакытта да тыныч юл белән миссионерлар тарафыннан гына башкарылмый. Кайбер очракта ут һәм кылыч белән мәҗбүр итәләр...

– Идел буенда ислам тыныч юл белән тарала. Әмма процесс катлаулы була, озакка сузыла. Мәсәлән, Урта Идел буена күченгәнче болгарлар яшәгән Дон буендагы кайбер иң яңа археологик ачышлар халыкның шактый иртә мөселманлашуын раслый. «Мөгаен, 737 елгы вакыйгалардан соң ук – гарәп гаскәрие Мәрванның хәзәр җирләренә ясаган уңышлы хәрби яулары нәтиҗәсендә каганны һәм аның



Рәфыйк Мөхәммәтшин, ТР мөфтие урынбасары, Россия ислам институты ректоры. Сәясәт фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы.

922 елда Идел буе Болгар дәүләтендә исламны рәсми рәвештә кабул итү хөрмәтенә куелган Истәлек билгесе.

Фото: Александр Ефремов

Болгарларның ислам динен кабул итүе. Ислам мәдәнияте музее. 2012 ел. Фәрит Вәлиуллин.

яраннарын яңа динне кабул итәргә мәҗбүриләгәннән соң алар исламда булганнардыр. Шул рәвешле IX гасыр ахыры – X гасыр башындагы күченеп утыруларның икенче куәтле дулкыны нәтиҗәсендә Урта Идел буена килгән болгарларның бер өлеше шактый дәрәҗәдә мөселманлашкан булу ихтималын да инкарь итеп булмый».

Чыганакларга һәм тикшеренүләргә таянып, Идел буе төбәгендә исламны таратуның ике төп факторын аерып күрсәтергә мөмкин: гарәп миссионерлары эшчәнлеге һәм көнчыгыш дәүләтләре, беренче чиратта VII–VIII гасырларда формалашып килүче мөселман цивилизациясенең төп өлешенә әйләнгән Иран һәм Урта Азия илләре, белән күпьеллык сәүдә-икътисадый һәм мәдәни хезмәттәшлек.

– Һәм әлеге факторларның кайсысы өстенлекле булган?

– Һичшиксез, икенчесе. Исламның таралуына озак еллар дәвамында болгарлар һәм Көнчыгыш илләре арасындагы элемтәләр ярдәм иткән. Процесс үз заманына туры килә: болгар җәмгыяте инде сыйфат ягыннан башка халәткә күчәргә әзер була. Исламны кабул итү идеологик һәм мәдәни тормышта тамырдан үзгәрешләр белән бергә бара. Шул ук вакытта үсешенең югарырак баскычына күтәрелеп, болгарлар үзләренең үзенчәлеген дә югалтмый, алга таба үсү һәм камилләшү өчен этәргеч тә ала.

– Шулай да, сез әйткәнчә, исламны кабул итү процессы катлаулы була, озакка сузыла. Бу нәрсәләрдә чагылыш таба?

– Кайбер тикшеренүчеләр беренче вакытларда аксөякләр даирәсендә ислам христианлык белән көндәшлек итә, ярыша, дип гөманлый. Дон янындагы Бөек Болгарның беренче ханнары – Органа, Кубрат һәм аның уллары православие динендә була. VIII гасыр башыннан Хәзәр дәүләте Идел буенда яһүд динен тарату үзеге санала. Әле 1920 нче елларда күренекле татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин (Г. Газиз) язганча, «VIII гасырда Урта Азиягә ислам үтеп керү сәбәпле, төрки халыклар гарәп мәдәниятенә якыная. Нәтиҗәдә төркиләр арасында ислам идеологиясе таралыш ала, төрки тел ислам мәдәниятенең өченче теленә әйләнә, төрки дәүләтләр ислам идеологиясенә нигезләнгән монархия булып формалаша. Шулай итеп, шаман һәм мәҗүсиләргә бәйле иске идеология урынына алар мохитенә, бер яктан, буддачылык, икенче яктан, зороастризм калдыклары, өченче яктан, несторианлык һәм манихейлык дулкыннары, ә Идел буе төркиләренә – бер үк вакытта яһүд идеологиясе дә һәм, ниһаять, ислам тәгълиматы үтеп керә башлый».

– Ислам Урта Идел буена Урта Азия аша керә башлаган булып чыгамы?

– Нәкъ шулай. Сәүдә бәйләнешләры нәтиҗәсендә мөселман традицияләре һәм дини мәктәпләр (шул исәптән хәнәфи мәзхәбе) белемнәре акрынлап Урта Идел буенда да тарала. Сакланып калган иң борынгы чыганак – Андалусиядән гарәп сәүдәгәре һәм дипломаты Әбү Хәмид әл-

Гарнати хезмәтендә болай дип хәбәр ителә: «Болгар әмире исламны бер Бохара фәкыйһе тарафыннан дәваланганнан соң кабул итте». Безгә килеп ирешкән соңгырак тарихи язмаларда әлеге сюжет тулырак итеп тасвирлана. Болгарлар арасында исламны таратуны Мөхәммәд пәйгамбәрнең Болгар дәүләтенә шәхсән үзе җибәргән өч сәхабәсе эшчәнлеге белән бәйлиләр. Алар өч ел дәвамында Болгар шәһәрендә халыкны дин нигезләренә һәм шәригать кануннарына өйрәтә, Җәмигъ мәчете төзетә, мәдрәсә ача, имеш... Дөрес, галимнәрнең әлеге тарихның риваять кенә булуында шиге юк.

Шул ук вакытта болгарларның үзләренең «Идел буена исламның Урта Азия һәм Бохарадан килүен һәм күп гасырлар дәвамында болгарлар өчен нәкъ менә шул дини элемтәләрнең актуаль булуын» төгәл һәм туп-туры атауларын танымый мөмкин түгел. Әлеге хәлгә Ибне Фазлан да игътибар итә. Ул хәтта кайбер дини йолаларны үтәүгә үз төзәтмәләрен кертергә тырышып карый. Әйтик, ул «...мөәзин, намазга чакырганда, камәтне, ягъни азанның бер өлешен ике тапкыр яңгырата. Ә болай эшләү хәлифә сараенда кабул ителмәгән», дип, Болгар әмиренә әлеге очрак буенча үзенең канәгатьсезлеген белдерә.

Эш шунда ки, Багдад хәлифәсе илчелегенә «җаваплы, ахыр чиктә сәяси бурыч – Болгар ханлыгында исламны гына түгел, Урта Азия йолалары урынына Багдад мөселман йолаларын кертү дә йөкләнә».

– Йолалар һәм сәясәт. Монда нинди бәйләнеш бар?

– Урта гасыр мөселман Көнчыгышында теге яисә бу мәзхәбкә карау кайбер шартларда теге яисә бу хөкүмәткә хәерхаһлык күрсәтүне аңлата, чөнки төрле мөселман хөкүмәтләре мәзхәбләрне алыштыруда зур роль уйный. Шулай итеп хаким теоретик яктан караганда Багдад хәлифәсе файдасына сайлый алган. Өстәвенә, бу дәүләтне исламлаштыруның әле башлангыч этабы гына булган.

Әгәр югарыда аталган камәткә бәйле прецедент әле Ибне Фазлан чагында ук булганны күз уңында тотсак, хан мөәзингә «ул (Ибне Фазлан – Р.М.) сиңа әйткәнне эшлә, аңа каршы килмә» дигән икән, Идел буе Болгар дәүләтенең рухи (һәм сәяси) тормышында вакыйгаларның башка борылышы да ихтимал булырга мөмкин. Әмма, А.П. Ковалевский сүзләренә караганда, «хан Багдад мөселман йолаларын кабул итүдән баш тарта һәм Урта Азиянекендә кала... Урта Азия илләре белән тыгыз сәүдә һәм мәдәни элемтәләр яшәп килгәнгә, болгар ханлыгы өчен хәнәфи йолаларын сакларга кирәк була».

Шунысы мөһим: нәкъ шул вакыттан башлап, дип саный тикшеренүчеләр, дөньяның сәяси картасында Идел буе Болгары пәйда була. Илчелекнең килүе яңа ислам дәүләтен дипломатик яктан рәсми рәвештә тану ролен башкара. Шулай итеп, IX гасыр ахыры – X гасыр башы Идел буе Болгар дәүләте өчен дәүләтчелекнең дә, дини-хокукый системаның да торгызылуы чоры санала.

Әгәр X гасыр ахырында бөтен мөселман дөньясында казыйларның Коръән, сөннәт, Пәйгамбәр сәхабәләренең индивидуаль яки бертавыштан кабул иткән хәдисләре белән билгеләнмәгән сораулар буенча хөкем чыгаруда шактый ирекле булуын күз уңында тотсак, әлеге дәүләттә исламны массакүләм һәм рәсми рәвештә кабул итү белән генә әлеге процесс тәмамланмаган дигән нәтиҗә ясарга була. Башкача фикерләү һәм төрле халыкларда исламга кадәрге чорда барлыкка килгән җирле гореф-гадәтләрне киң куллануга чагыштырмача түземлелек күрсәткән хәнәфи мәзхәбе, ихтимал, әлеге процессның тиз арада тәмамлануына ярдәм итмәгәндер.

Сакланып калган чыганаклар һәм галимнәрнең тикшеренүләре Идел буе Болгар дәүләтендә дини-сәяси җитәкчелекнең бурычы хак дингә күчү генә түгел, шулай ук илдә тәртип, иминлек һәм тынычлыкка ирешү булгандыр дигән фаразларны расларга мөмкинлек бирә. Төрле конфессия вәкилләре, төрле мәзхәб дин галимнәре, төрле суфичылык җәмгыятьләре яшәгән Идел буе Болгары өчен бу гаять мөһим була.

Әңгәмәдәш: Әскәр Сабиров



МИРАЖГА АЛДАНГАН ЯЗУЧЫ: ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

Илдус Заһидуллин

Күренекле татар язучысы һәм совет дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның 15 томлык әсәрләре дөнья күрде. Авторның Кырымда кулга алынганнан соң югалган архивын санамаганда, бүген язучының язма мирасы тулысы белән халыкка кире кайтты дип, ышаныч белән әйтергә мөмкин.

Галимҗан Ибраһимов XX гасыр башы яңарышы дулкынында бертөркем яшьләр белән милли-мәдәни мәйданга чыга, үзенең киңкырлы иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән татарларда сәяси фикер үсешенә зур йогынты ясый. Ләкин күпчелек каләмдәшләреннән, мәсләктәшләреннән аермалы буларак, Ибраһимов, 1917 елда хакимиятне кулга төшергән большевиклар белән хезмәттәшлек итеп, Мәскәүдә бик югары дәүләт постлары били. Казанга кайтып, галим һәм җитәкче буларак, ТАССРда татар фәнен, әдәбиятын һәм, гомумән, милли мәдәниятне үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертә. Хезмәтләре югары бәяләнеп, 1928 елда Хезмәт Батыры, Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы исемнәренә лаек була, ТАССР Язучылар берлегенә беренче булып кабул ителә. Халкыбыз тарихында ул ике төрле идеологиягә хезмәт иткән шәхес буларак бәяләнә. Төркиядә яшәгән замандашы Габделбари Баттал аны «миражга алданган язучы» дип атый.

ШӘКЕРТЛЕК ЕЛЛАРЫ

Галимҗан Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасы Эстәрлетамак өязенең Солтанморат авылы мулласы Гыйрфан хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Берничә буын бабалары дин әһеле булган бертуган Шакирҗан һәм Галимҗанның кайсы юлдан китәчәкләре алдан язылган кебек була. Кешәнле авылы мәктәбендә һәм туган авылларында өч сыйныфлы рус-татар башлангыч мәктәбен тәмамлагач, Гыйрфан хәзрәт аларны 1898 елда заманының иң шәп җәдид уку йорты – Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә алып килә. Ләкин 11 яшьлек Галимҗанның укырга керергә яше җитми, малайның авырганын да исәпкә алып, «Хөсәения»гә кабул итмиләр. Шунлыктан ул кадим «Вәлия» мәдрәсәсе шәкерте булып китә һәм биредә сигез ел уку дәвамында төпле дини белем ала; алдынгы укучы буларак остазы Вәли хәзрәт белән мәҗлесләрдә дини бәхәсләрдә катнашып, фикерләү осталыгын чарлый.

1905 елда башланган Беренче рус инкыйлабы татар шәкертләрен уята. Галимҗан да остазына уку-укыту мәсьәләсендә каршы чыкканы өчен мәдрәсәдән куыла. Егет башта укуын Троицк мәдрәсәсендә дәвам итә. 18 яшьлек Галимҗан, әл-Әзһар университетын тәмамлап кайткан Зыя Камали Уфада «Галия» исемле уку йорты ачуын ишетеп, 1906 елда шунда ирекле тыңлаучы булып урнаша.

Шунысын да әйтергә кирәк: мәдрәсә мөдире Зыя Камали тарафыннан уку йортында ирекле фикер йөртү өчен мөмкинлекләр тудырыла, төрле темаларга диспутлар һәм шәкертләрнең иҗтимагый активлыгын арттыруга юнәлтелгән чаралар оештырыла. Хөр фикер даирәсендә үсмерлек максимализмы бертөркем яшьләрне мәдрәсәне тулысынча дөньяви уку йортына әверелдерү турындагы уйларга этәрә. Укыту тәртибен тәнкыйтьләп, Галимҗан Зыя Камалига хат яза, еш кына җыелышларда җитәкчелеккә

Фотолар автордан алынды

каршы чыгышлар ясый. «Коръән Алладанмы, түгелме?» исемле китап язгач, егет укудан куыла.

1909 елның азагында университетка укырга керү теләге белән Казанга юнәлгәнче, Галимҗан казах җәйләүләрендә һәм Төньяк Кавказда нугай авылларында мөгаллимлек итә, Уралдагы Миасс заводында эшләп ала. Бу елларда Галимҗан Ибраһимов уку әсбапларына зур кытлык кичергән татар мәдрәсәләре өчен дәреслек язучыларның берсе буларак таныла. Аның 1909 елда «Борынгы ислам мәдәнияте» исемле китабы дөнья күрә. Гарәп галиме Җөрҗи Зәйдан һәм француз тарихчысы Гюстав Лебон хезмәтләрен файдаланып язылган бу китапның концепциясе мөселман цивилизациясенең бөеклеген, аның алдынгылыгы яңалыкка омтылудан һәм башка халыкларның казанышларын үзләштерүдән башланганын күрсәтү, шулай күренекле галимнәрнең математика, медицина, астрономия, табигать фәннәре буенча хезмәтләренең Европа фәнен үстерергә ярдәм итүләрен тасвирлаудан гыйбарәт була. Мөселман булуны ритуаллар үтәүдән һәм намаз укудан гына тора дип фикерләгән кешеләрдә шул рәвешле исламга карата яңача караш формалаштырырга тырыша.

Шулай ук яшь язучының беренче әсәрләре укучыга барып ирешә: «Татар хатыны ниләр күрми» повесте һәм «Гыйшык корбаннары», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» исемле хикәяләре дөнья күрә. Галимнәр бу әсәрләр татар әдәбиятында романтик метод урнашуга уңай йогынты ясый дип саный.

КАЗАН КАЛАСЫНДАГЫ ТОРМЫШЫ

Галимҗанның 1910 елда университетка керү теләге гимназия дәрәҗәсендә белем кирәклеге, ә русча уку өчен акча булмау белән киселә. Бу уңышсызлык егетнең күңелен төшерми, киресенчә, максатчан рәвештә даими белемен арттыруга этәрә. Автобиографиясендә Галимҗан Ибраһимов болай дип искә ала: «Миңа озак еллар мохтаҗлык кичерергә, ялангачлыкны татырга, шул ук вакытта бик тырышып, системалы рәвештә үзлегемнән белемемне күтәрүне дәвам иттерергә туры килде». Чыннан да, Казанда яшәгәндә Ибраһимов күренекле галим, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе булып таныла. Егет каланың иҗат интеллигенциясе белән якын мөнәсәбәтләр кора, зыялылар, нәширләр белән таныша, аралаша.

Казанда Ибраһимов иҗатының яңа юнәлешләре калку күренә.

Беренче нәүбәттә, Галимҗан Ибраһимов «өлгергән» язучы буларак дан ала. 1912 елда үз идеаллары өчен көрәшүче яшьләр образларын тудырган «Яшь йөрәкләр» романы дөнья күрә. Саф романтизм юнәлешендәге «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1910), «Сөю-сәгадәт» (1911) хикәяләре укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Бер үк вакытта Галимҗан әдәбият фәнен тирәнтен өйрәнә, әсәрләрендә татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре турында күзәтүләре белән уртаклаша. Автор фәнни эшчәнлекнең өч юнәлешен аерып ала: 1) татар әдәби теле теориясе һәм аны куллану мәсьәләләре; 2) татар теле методикасы; 3) татар әдәбияты теориясе һәм принциплары. Шәкертләргә ана телен укытуда кулланма итеп бер-бер артлы «Татар сарыфы» (морфологиясе, 1911) һәм «Татар нәхүе» (синтаксисы, 1911), «Татар имлясы» (орфографиясе, 1914) исемле китаплар да бастыра.

Аның публицистик мәкаләләренең ныклы фәнни нигезгә корылган була. 1910–1913 елларда вакытлы матбугатта күтәрелгән «Без кем: татармы, төрекме?» исемле бәхәстә катнашыр өчен, булган тарихи әдәбиятны өйрәнә. Мәкаләләрендә һәм бәяләмәләрендә татар тарих фәненең торышына, аерым хезмәтләргә бәя бирә, «Ни өчен татарлар җиңелгәннәр, чигенгәннәр?» дигән сорауга җавапны рус халкы тарихы белән чагыштырып эзли, татарларның шанлы үткәнен һәм әйдәманнары батырлыкларын пропагандалауның үсеп килүче буында милли горурлык тәрбияләүдәге бик мөһим ролен билгеләп үтә, моңа ирешү юллары турында уйлана. Нәтиҗә ясап, Галимҗан Ибраһимов галимнәр алдына милли тарихны язу бурычын куя.

1910 елда «Шура» журналында ачылган «Тел ярышы» рубрикасындагы мәкаләләрендә без дөньядагы төрки кавемнең бер өлеше, ләкин без татарлар дигән фикер уздыра. Шунысы кызык: туган халкының тарихи этапларын барлаганда, Ибраһимов Идел буе Болгар дәүләте чорын аерып чыгармый, ягъни турыдан-туры әйтмичә генә Шиһабетдин Мәрҗанинең татарларның килеп чыгышы концепциясенә каршы чыга.

1915 елда татар җәмәгатьчелеге милләткүләм зур вакыйга итеп Шиһабетдин Мәрҗанинең 100 еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнгәндә, Галимҗан Ибраһимов та ике мәкалә яза. Аның «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле хезмәтен – милли тарихның нигезе, ә Мәрҗанинең үзен даһи дип атый. Шулай ук галимнең кыюлыгын, җәмәгатьчелек фикеренә колак салмыйча, үз сүзен кистереп һәм тәнкыйди яңгыратуын ассызыклый.

Бу планда ул үзе дә Мәрҗанигә охшатып, хәтта арттырыбрак һәм тагын да кискенрәк яза. Үзенең һәм башкаларның әсәрләренә бик югары таләпләр куйган Галимҗан вакытлы матбугатта яңа әдәби әсәрләргә, уку әсбапларына һ.б. басмаларга күпсанлы бәяләмәләр, шул исәптән тәнкыйди яктан дөреслектән ерак торган язмалар белән катнаша. Алар арасында җәмәгатьчелектә тирән ризасызлык уяткан Дәрдемәнд, С. Рәмиев һәм Г. Тукай иҗатларына багышланган «Татар шагыйрьләре» хезмәтен атарга кирәк. Автор басмада «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дигән сорау куя һәм бөек татар шагыйрен хаксызга гаепләп, рәнҗетүле юллар яза. Ибраһимовның 1912 һәм 1914 елларда кинәттән Киевка китеп баруына язучының Казан зыялылары белән ике арада туган киеренке мөнәсәбәтләр дә сәбәп була.



Галимҗан Ибраһимов белән Шаһит Әхмәдиев. Ялта, 1928 ел.

Галимҗан Ибраһимов Киевка беренче китешендә берничә студентка һәм татар баласына ана теле һәм әдәбиятын укыта, гимназиядә имтихан бирергә әзерләнә, социалистик фикерләр белән мавыккан «Мөселман студентлары түгәрәге» утырышларына йөри. Көтмәгәндә фатирында тентү уздырылып, полиция тарафыннан 16 студент белән бергә кулга алына. 1913 елның 17 апреленнән 13 июненә кадәр төрмәдә утыра. Җәйне туган авылы Солтанморатта әтисе хуҗалыгында ярдәм итеп, эшләп уздыра.

Төрмәдә утырып чыгу язучының иҗатын яңа чалымнар белән баета. Аның яңа әсәрләрендә социаль мотивлар, гади халыкның авыр тормышы сурәтләнә башлый. «Карт ялчы», «Көтүчеләр» (1913), «Табигать балалары», «Мәхдүмнең дәфтәреннән» (1914) хикәяләре шундыйлардан.

Галимҗан Ибраһимов Әхмәтгәрәй Хәсәни чакыруын кабул итеп, 1913 елның 13 сентябрендә кабат Казанга килә һәм айга ике тапкыр басыла торган «Аң» журналының сәркатибе булып урнаша. 1914 елның 13 февраленә кадәр шушы вазыйфаны башкарганда «Аң»га зур үзгәрешләр кертә. Журналда «Фән вә фәлсәфи мәсьәләләр», «Хатын-кыз галәменнән» исемле рубрикалар ачыла, «Милләтне ничек аңлыйсыз?» һәм «Яңа елда ни телисез?» дигән анкеталар һәм аларга җаваплар урнаштырыла. Бу яңалыклар журналны кызыклырак итәргә, язмаларны көнүзәк темаларга юнәлтергә мөмкинлек бирә. Тагын бер яңалык – журналга кушымта рәвешендә автор-төзүченең әдәбият-сәнгать турындагы сүз башы белән «Альбом (Сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» исемле нигездә дөньякүләм танылган рәсем сәнгате әсәрләрен туплаган басма әзерли. Бер үк вакытта Габделбари Баттал белән төрле сыйныфларда орфография, морфология, синаксис һәм язу дәресләре өчен татар әдәбияты үрнәкләре – язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләреннән өзекләр – кергән «Яңа әдәбият» исемле китап-хрестоматия әзерли.

Язучы 1914 елда Казаннан кабат Киевка юл тота, беркадәр Кырымда яшәгәч, туган авылына юнәлә. 1914 елның 2 октябрендә кабат Казанга килә. Аңарчы бер ай элек аның «Йолдыз» газетасында басылган Г. Тукайны тәнкыйтьләүгә корылган «Талант трагедиясе» исемле мәкаләсе киң җәмәгатьчелектә көчле протест һәм шау-шу тудырган була. Казан зыялылары, моңа җавап итеп, язучыны изоляциядә калдыру турында карар кабул итә...

УФАДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Галимҗан Ибраһимов 1915 елның февралендә Беренче бөтендөнья сугышына алынган абыйсын озату өчен туган авылына кайта. Яңа уку елы башлангач, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укытырга алына. Шулай ук губерна земствосының өч еллык педагогика курсларында һәм кызлар мәктәбендә, кыска сроклы мөгаллимнәр курсларында дәресләр бирә. Ул педагогик эшчәнлеген фәнни һәм методик эзләнүләр белән үреп алып бара: «Әдәбият кануннары» (1916), «Татар телен ничек укытырга?» (1916) исемле теоретик һәм методик хезмәтләр яза.

Мөгаллим Февраль инкыйлабыннан соң сәясәт өлкәсенә кереп китә. 1917 елның башында аның сәяси карашлары әле мөселман милли хәрәкәтенең сул канаты карашларына тәңгәл килә. Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Ш. Сүнчәләй белән 30 марттан «Ирек» газетасын нәшер итә башлый. Редакция «Солдат теләге» газетасы белән кушылып, Галимҗан Ибраһимов редакторлыгында 21 сентябрьдән «Безнең юл» исемле матбугат органын нәшер итә башлый.

1917 елда Галимҗан Ибраһимовның исеме милләткүләм дәрәҗәдә яңгырый башлый. Ул Уфа губернасы мөселманнары вәкиле буларак 1–11 май көннәрендә Мәскәүдә узган Беренче һәм июль-августта Казанда узган Икенче Бөтенроссия мөселманнары съездларында катнаша, мәсләктәшләре белән социалистлар фракциясен оештырып, туфраклы автономияне, алпавыт җирләрен конфискацияләүне яклап сөйли. 1917 елның ноябрендә Уфада ачылган Милләт мәҗлесе эшендә катнаша.

МӘСКӘҮ ТОРМЫШЫ

Галимҗан Ибраһимов карашларының сулга авышуы Уфа губернасында зур йогынтыга ия булган социалист-революционерлар белән 1917 елның язында хезмәттәшлек итүдән башлана. Август аенда Уфада аның җитәкчелегендә татар-башкорт сул эсерлар партиясе оеша. Ул Уфа губернасыннан Россия республикасының киләчәген хәл итәргә җыелган Учредительное собраниегә дә сайлана.

Ибраһимов, сул эсер буларак, 1918 елның 5 гыйнварында большевиклар белән бергә Учредительное собраниене ташлап чыгып китә. Ике көннән Ленин һәм Сталин белән очрашуда катнаша. Галимҗан Ибраһимов, большевиклар сәясәтен тормышка ашырып, Идел-Урал штатларын оештыруга каршы чыга, аңа альтернатив рәвештә 1918 елның мартында Татар-Башкорт республикасы проектын эшләүдә турыдан-туры катнаша.

Ул 1919–1920 елларда милли гаскәрләр оештыру һәм Гражданнар сугышы елларында хәрбиләр арасында агитация алып баручы Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясендә әгъза булып тора, ВКП (б) ның Үзәк комитеты каршында Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясендә һәм «Кызыл Шәрык» журналында эшли һ.б. 1919 елда разведчик сыйфатында Колчак гаскәрләре тылында, Ак армия ягына чыккан татар милли хәрәкәте вәкилләренең, Милли идарә әгъзаларының эшчәнлеген күзәтеп, мәгълүмат җыеп кайта. Шунысы кызык: Мәскәүдә дәрәҗәле вазыйфалар биләсә дә, Галимҗан Ибраһимов, патша заманындагы кебек, большевикларның яшерен күзәтүе астында яши.

Сәламәтлеге какшау сәбәпле, 1920 елда Галимҗан Ибраһимов бөтенләйгә Казанга килә һәм вакытлы матбугатта татар укучысына атап совет идеологиясе рухында күпсанлы мәкаләләр яза. Шул исәптән, аның Гражданнар сугышы темасына кагылышлы истәлекләре, «Яңа кешеләр» драмасы һәм «Кызыл чәчәкләр» (1920) повестьлары дөнья күрә.

1920 нче елларда Галиҗан Ибраһимов актив рәвештә иҗат белән шөгыльләнә. 1921 елда Урта Идел төбәгендә узган коточкыч ачлыкны тасвирлаган «Адәмнәр» повесте (1923) языла. Шулай ук татар әдәбиятының классик әсәре дип танылган «Казакъ кызы» романын бастыра.

1920 елда Галимҗан Ибраһимов большевиклар партиясенә керә. Партия йөкләмәләрен үтәү рәвешендә, ул марксизм-ленинизм рухындагы мәкаләләр һәм тарихи хезмәтләр язуга алына, Владимир Ленин хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итүне оештыра. Татарлар арасында революцион фикерләр таралу турында сыйнфый күзлектән чыгып эшләнгән «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «1905 елгы революциядә татарлар» (1925), «Урал» һәм «уралчылар» (1927) хезмәтләрен яза.

«Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында. Икенче рәттә утыралар: сулдан икенче – Галимҗан Ибраһимов, өченче – Зыя Камали, бишенче – Галимҗан Нигъмәти. Уфа. 1916 ел.

Бу китапларда XX гасыр башы татар буржуазиясе һәм милли хәрәкәттә катнашкан татар зыялылары кискен тәнкыйть утына тотыла.

1925–1927 елларда ул ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты каршында Гыйльми үзәк җитәкчесе, шулай ук Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе, Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты һәм ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы булып тора. Галимҗан Ибраһимовның оештыру осталыгы, хәзерлекле тарихчы, әдәбиятчы һәм татар теле белгече булуы, зур тормыш тәҗрибәсе аңа бик кыска вакыт эчендә Гыйльми үзәк эшчәнлеген тамырдан үзгәртеп корырга мөмкинлек бирә. Гыйльми үзәкнең фәнни һәм методик җитәкчелегендә татар мәктәпләренә программалар һәм дәреслекләр язу, татарча фәнни терминнар һәм сүзлекләр эшләү, театр репертуарларын булдыру, төбәкләргә экспедицияләр оештыру, археология, этнография һәм тарих буенча ТАССР халыклары турында фәнни эзләнүләр алып бару кебек эшләр башкарыла.

1926 елда Бакудагы Беренче тюркология съездында гарәп имлясыннан латин хәрефләренә күчү мәсьәләсен тикшергәндә, Галимҗан Ибраһимов җитәкләгән Татарстан делегациясе бу яңалыкка каршы тавыш бирә. Ахыр чиктә, 1929 елда Совет хакимияте, галим-голәмәне мәҗбүриләп, барыбер теләгенә ирешә.

Шулай бөтен көчен куеп татар фәнен һәм мәдәниятен үстерү өчен тырышып йөргәндә, 1927 елның мартында Галимҗан Ибраһимовның сәламәтлеге нык начарая. Үпкә туберкулезын дәвалау өчен, язучыны җылы һавалы һәм кояшлы Кырымга дәваланырга җибәрәләр. Гаиләсе белән Ялтада яшәгәндә ул социалистик реализм кысаларында иҗат ителгән «Тирән тамырлар» романын, элек язылган кайбер әсәрләрен төзәткәләп, кабат бастырырга әзерли.

1937 елның 25 августында Галимҗан Ибраһимов «Уң троцкийчы милләтчеләрнең хакимияткә каршы оешмасы»нда катнашкан дигән ялган гаеп белән кулга алына. 1938 елның 21 гыйнварында Черек күл төрмәсе хастаханәсендә вафат була. Казанның Архангел зиратында халык дошманнары өчен билгеләнгән тәртиптә күмелә. Кабере билгесез.

КАНГА СУСАУ, ЯКИ АЛЬТЕРНАТИВ ЧЫНБАРЛЫК ЧЫНЛАП ТА УЙДЫРМАМЫ?

Фотолар: kinopoisk.ru, start.ru, kinoafisha.info

Луиза Янсуар

20 гыйнварда START Россия видеосервисында бу елның иң көтелгән һәм кыйммәтле проектларының берсе – Данила Козловский төшергән һәм продюсерлык иткән «Карамора» сериалы дөнья күрде. Затлы һәм бик тә уйланылган промо, бай бюджетлы, моңарчы безнең экраннарда күренгән сериаллардан шактый нык аерылып торган, Көнбатыш һәм АКШ киноиндустриясе юнәлешен алга сөргән эстетика, технологияләр, менә дигән каст, кызыклы прокат форматы... Кыскасы, «Карамора» – кино өлкәсендәге яңалыкларны күзәтеп баручылар өчен чын мәгънәсендә вакыйгага әверелде.

Моңа өстәп, күпсанлы пыран-заран китереп ташлаган яки мактаган рецензияләрне, сериал тирәсендә барган бәхәсләрне, профессиональ, киң җәмәгатьчелекнең реакциясен дә исәпкә алсак, ягъни сыйфатлы, заманча «хайп»ны тиешенчә бәяләсәк, Данила Козловский үз максатына ирешә, дип әйтергә буладыр. Чөнки сериалны әзерләү барышында ук аның берән-сәрән биргән интервьюлары аша шуны аңларга була иде: Россия һәм дөнья киноиндустриясен эчтән күреп белгән, тәҗрибә тупларга өлгергән Козловский чираттагы бер конвейер материалына гына йөз тотмый, ә чыннан да «бомба» әзерли. Тамашачы өчен дә, кино дөньясындагы экспертлар, тәнкыйтьчеләр өчен дә провокациягә йөз тота. Әйтергә кирәк, заман һәм вазгыятьне, сәяси аренада барган вакыйгаларны күз уңында тотсак, шактый кыю, хәтта ки дуамал эксперимент бу. Әмма – гаҗәеп зәвыклы, тәмле итеп хәстәрләнгән, эчтәлеге белән дә, бизәлеше белән дә сокландыра, тел шартлатырга мәҗбүр итә торган экзотик, авыздан сулар китерә торган десерт.

Мине шәхсән Козловскийның тәвәккәллеге һәм колачы шаккатырды. Афәрин, диясе һәм кул чабасы килә. Үзенә генә дә түгел, ә бөтен иҗади һәм техник командага!

БЕЛЕШМӘ

Исеме: «Карамора»
Жанры: маҗаралы триллер, альтернатив тарих, детектив, мистика
Эпизодлары: 8 серия
Идея һәм сценарий авторы: Александр Фомин
Режиссеры һәм генераль продюсеры: Данила Козловский

Иң беренче, проектның исеменә тукталып узыйк әле. Нинди колак ияләшмәгән атама соң бу? «Карамора» дип гадәттә Россиянең көньягында яши торган озын аяклы черкиләрне атап йөртәләр. Максим Горькийның шул исемдәге хикәясе бар – ул Петр Каразин атлы элеккеге революционерның монологы рәвешендә язылган. Сюжет буенча, әлеге каһарман ахыр чиктә патша сагына хезмәт итә башлый. Хикәянең азагында өзлексез уйлар агымын туктата алмый тилмергән Каразинның күңеленнән менә мондый уй йөгереп уза: «Ә мин бердәнбер дөреслекне күрә алган теге малай булсам, нишләргә?!»

«КАРАМОРА» – ТАРИХИ ДРАМА ТҮГЕЛ, Ә СЫЙФАТЛЫ, ЯХШЫ КОМИКС, ШАРТЛАГЫЧ АТТРАКЦИОН. ӘММА АНДАГЫ ВАКЫЙГАЛАР ТАРИХИ ҖИРЛЕКНЕ БАРЫБЕР ДӘ КҮЗДӘ ТОТА, АЛАР РЕВОЛЮЦИЯГӘ КАДӘРГЕ РОССИЯДӘ, АЛЬТЕРНАТИВ ЧЫНБАРЛЫКТА БАРА.
«Комсомольская правда» газетасыннан

Сериалдагы каһарманның исеме нәкъ шул ук – Петр Каразин. Ул – анархист һәм төрле сәяси акцияләр оештыручы, бер үк вакытта Өченче бүлек (сәяси сак һәм эзләү бүлеге) белән дә элемтәдә тора. Шул рәвешле сценарий авторы белән режиссер, ягъни төп авантюристлар, безгә алдан ук кагыйдәләрне билгеләп куя: бу үзенә күрә интеллектуаль һәм комарлы уен, интертекстуаль полигон, әйдәгез, бергәләп күңел ачабыз, ә? Моны хәтта бер гасыр буена ваемлап та ваемлап җиткерә алмаган дәвер һәм аның битлекләре турындагы миф, диярге дә буладыр. Ләкин Козловский беренчел миф турында икенчел миф аша сөйләмәсә, Козловский булмас иде. Гомумән, сүз уңаеннан, игътибар итеп узасы килә – бу янә бүгенге заман трендларының берсенә әверелеп бара. Уен, квест, башваткыч, параллель чынбарлык аша җитди темаларга сөйләшү, аларның серле дә, моңарчы беркем җөрьәт итмәгән дә япмасын ачып карау. Озакламый без гомумән «эзоп теле»нә кайтырга да бик мөмкинбез, дигән шик һәркемдә бардыр.

Иң беренче кадрлардан алып, «Карамора» Россия сериалларына хас булмаган масштаб һәм динамика белән җәлеп итә. Вакыйгаларны абайлап бетерергә, аллюзияләрне, метафораларны укып өлгерергә күз иярми. Әлбәттә, бу әзерлекле тамашачы өчен эшләнгән картина, ләкин Козловский, тозлап-борычлап, бөтенләе белән тарихи һәм мәдәни контекстны белмәгән караучыга да кызыклы була алырдай әсәр тудырган. Кемдер геройларда аларның прототипларын танып алып, реминисценцияләргә ләззәтләнеп карап утырса, гади тамашачы сериалдагы экшнга тәэсирләнеп хушланачак. Бер атуда ике куянны тотып булмый диючеләргә шул рәвешле, кепкасын кыңгыр салып, сәлам дә бирә Козловский: җәмәгать, менә бит, була, янәсе. Эһе-һе-һей!

Голливуд колачы белән эш итәргә алдан ук йөз тотып, продюсерлык хокукларын үзенә яулаган режиссер проектында йөздән артык актер катнаша, локацияләр саны шулай ук җитәрлек. Шунысы да билгеле: сериалны төшереп бетерер, монтажлар һәм пиар-кампанияне ерып чыгар өчен, Козловский кредитлар ала, шул исәптән, Абрамович фондыннан да. «Карамора» иң баштан нәкъ менә ТВ форматы өчен режиссер Илья Найшуллер тарафыннан әзерләнә башлаган булса да, канал бераздан проекттан баш тарта. Пандемия чорында берәү дә мондый кыйммәтле проектны тормышка ашырып бетерергә алынмый. Шул рәвешле ул Данила Козловский кулына килеп эләгә һәм яңа сулыш ала.

Козловский кат-кат кабатларга ярата – картинада компьютер графикасы юк дәрәҗәсендә, аның өчен чын фактура беренче урында тора. Һәм бу – юкка гына әйтелгән сүзләр түгел, чөнки «Карамора»да һәр икенче эпизод саен декорацияләрне яндыралар, җимерәләр, катлаулы трюклар ясыйлар. Натуралистик яктан

БУ – ДАНИЛА КОЗЛОВСКИЙ СЕРИАЛЫ, ДИЛӘР, ЯГЪНИ АВТОР КИНОСЫ, АРТХАУС, ФЕСТИВАЛЬ КАРТИНАСЫ... МИН МОНДЫЙ БҮЛЕНЕШЛӘРНЕ ӨНӘМИМ. МИНЕМ ӨЧЕН «КАРАМОРА» – ЧЕП-ЧИ МЕЙНСТРИМ. АНДА БАРЫСЫ ДА АҢЛАШЫЛА, УЛ – ТАМАШАЧЫНЫ ИСӘПТӘ ТОТЫП ТӨШЕРЕЛГӘН ПРОЕКТ. МИН, РЕЖИССЕР БУЛАРАК, АНЫ АВТОР КАРАШЫННАН ТӘКЪДИМ ИТӘМ, БИЛГЕЛЕ, Ә ТАГЫН НИЧЕК БУЛСЫН, ДИ? МОНДЫЙ ТӨР ФИЛЬМНАР БИК ЗУР БЮДЖЕТ ҺӘМ ВАКЫТ БЕЛӘН ТӨШЕРЕЛЕРГӘ ТИЕШ. БЕЗНЕҢ БЕР СЕРИЯ ӨЧЕН 9–10 КӨНЕБЕЗ БУЛДЫ НИБАРЫ. БОЛАЙ ЭШЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ! ӘММА МИН ИСКИТКЕЧ КОМАНДАГА БАШ ИЯМ, АЛАРДАН БАШКА БЕРНИ ДӘ БАРЫП ЧЫКМАС ИДЕ, ФИДАКАРЬ КЕШЕЛӘР...

Данила Козловский, ТАСС өчен әңгәмәдән

да тамашачыны кызганып тормыйлар – биредә кан чиләкләп кенә түгел, цистерналап түгелә (әйтүләре буенча, 510 литр махсус әзерләнгән сыекча кулланылган), детальләр соң чиккә җиткерелеп бар нечкәлегендә күрсәтелә. Каскадерлар исемлеге генә дә титрларда 40 лап кешене тәшкил итә.

Инкыйлаб белән бәйле вакыйгалары булсын да, кан түгелмәсен инде, диярбез. Ә, юк, бөтен хикмәт тә шунда шул... Авторлар большевиклар белән аклар көрәше мифопоэтикасына төреп, безгә, беренче карашка, бөтенләй башка килмәстәй вульгар да, шул ук вакытта инде тәмам ялыктырган, моветонга әйләнгән популяр теманы тәкъдим итә: баксаң, без вампирлар сагасын карыйбыз икән. Һәм менә бу урында инде чын-чынлап шаркылдап көлеп җибәрәсең: «Сез нәрсә, чыннан дамы?!» Сүндереп куярга да мөмкин булыр иде, билгеле, әмма сүндерә алмыйсың, ниндидер тарту көче сине алга таба да карарга мәҗбүр итә. Авторларның ирониясе һәм башбаштаклыгы ни дәрәҗәгә җитәр икән – кызык ич! Моннан тыш, бу альтернатив чынбарлыктагы пейзажлар, тарихи аллюзияләр белән каһарманнарны да күзәтү үтә мавыктыргыч: менә, режиссер безне тарихи Дракула эзләре буенча Карпат тауларына алып китә, менә без Көмеш чор шагыйрьләре һәм иҗат әһелләре, сәясәтчеләр (ә бәлки, масоннар) җыелган Петербург вакханалиясе үзәгенә барып эләгәбез һәм Маяковский, Шаляпин, Столыпин, Нобель белән очрашабыз, менә без дуамал Пацияне очратабыз, аның белән Тифлис төрмәсенә юл алабыз да яшь Коба (Сталин) белән гәп куертабыз, менә без төп каһарманнарның берсе кенәз Руневскийга хатын-кыз киеменнән кунакка килгән Феликс Йосыповның демагогиясен тыңлыйбыз, менә без Россиядә бердәнбер вампирдан кабат кешегә әйләнә алган могҗиза иясен эзләп, Ясная Полянага барып эләгәбез һәм анда Толстойның үзе, толстойчылар белән очрашабыз, менә без Распутинның мистик көче артында нәрсә торганын аңлыйбыз...

Әйтергә кирәк, гротеск, китч эчендә Данила Козловский-режиссер бер генә мизгелгә дә уйлый торган тамашачысын рефлексиядә утырудан азат итми – күр әле син боларны, бу бит Көнбатышка, Голливудка һәм аның трендларына да, Россия чынбарлыгы белән аның бүгенге сәяси позицияләренә дә, мәдәни өлкәдәге коллапс белән яңа кануннарга сусауларга да җавап. Җавап кына да түгел, урыны-урыны белән яңаклап алу да. Россия халкының канын эчеп, үзләре гасырлар дәвамында типтереп яшәп яткан вампирлардан инде тәмам гайрәтең чигә башлауга, сюжет кабат борылыш ала. Баксаң, вампир-аксөякләрнең үзләренә балаларыннан, оныкларыннан куркыныч яный булып чыга, аталар белән балалар темасы дивардагы мылтык кебек ата.

Озын сүзнең кыскасы, «Карамора» – быелгы сезон премьералары арасында иң шау-шу һәм бәхәс кузгатканы. Аның киләчәктәге язмышы ничек булыр һәм прокат нинди нәтиҗәләргә китерер, вакыт күрсәтер.

МИН ҮЗЕМ КАНЛЫ ТАРИХЛАРНЫ БЕР ДӘ ЯРАТМЫЙМ. ӘММА «КАРАМОРА» ЧЫНБАРЛЫГЫНДА ШУШЫЛАЙ ДӨРЕС ДИП ТОЙДЫМ. ТАМАШАЧЫНЫ ШОК ХӘЛЕНДӘ КАЛДЫРАСЫ КИЛДЕ – КОНТРАСТЛАР АША АЕРМАНЫ ДА, АВАЗДАШЛЫКНЫ ДА ТОЙСЫН, ДИДЕМ.

Данила Козловский, ТАСС өчен әңгәмәдән



ВАХИТ: 100 ЕЛЛЫК АВЫЛ НИЧЕК ЯШИ?

Югары Ослан районында чын татар авыллары берничә генә. Вахит – шуларның иң атаклысы. Сиксәненче елларда биредә совхоз оешкан, урта мәктәп ачылган. Озак еллар әлеге белем учагы районда татар телендә белем бирүче мәктәп булып саналган. Ни кызганыч, өч ел элек мәктәп ябылган. Җирле халык әлеге яңалыкны ничек кабул иткән? Вахитлылар бүген ниләр белән шөгыльләнә? Язма шул хакта.

Фото: Александр Ефремов

ВАХИТ

Руфия Фазылова

ЯҢА УРАМ, ЯҢА КЕШЕЛӘР...

Авыл зур түгел, 260 кеше яши, 80 хуҗалык бар. Шулай да Вахит авыл җирлеге идарәсе булып тора, биш саланы берләштергән. Әйткәнемчә, мәктәп ябылган, җиде бала хәзер Матюшино урта мәктәбенә йөреп укый. Узган ел көзен балалар бакчасы ишегенә дә йозак эленгән. Нибары өч бала өчен бинаны ягып, тәрбиячегә акча түләү кыйммәткә чыга дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Авылда зур булмаган мәдәният йорты, китапханә, мәчет, ФАП, ике кибет эшләп тора.

Вахит яшь салалар рәтендә йөри, 1919 елда оешкан. Шуңа да авылның тарихын биредә яхшы беләләр. Ул чорларның шаһиты булган кешеләр вафат инде, ә менә бер бина тора – 1930 елда салынган беренче мәктәп ул. Иң кызыгы, анда бүген бер гаилә яши.

– Ул мәктәптә башлангыч сыйныфлар гына була, – диде Вахит авылы китапханәчесе Сания Сәлимуллина. – Аннан балалар күрше Болгар авылына укырга йөргән. Ә менә 1986 елның 1 сентябренә Вахитта сигезьеллык мәктәп ачылды. Дөрес, ул бина башта ике яклы йорт итеп төзелде, аннан җирле җитәкчеләр теләге белән мәктәп өчен бирелде.

Вахит авылында сигезьеллык мәктәп ачылганда, күрше Болгар авылында балалар саны кими, ә биредә киресенчә арта бара. Моның сәбәбе бик гади була – авылда «Ташовский» совхозы гөрләп эшли. Мәктәпкә бирелгән бинаны да совхоз үз акчасына төзетә.

– Ул чорларда совхоз эшчеләре өчен ике яклы йортлар сала, – дип дәвам итте сүзен Сания апа. – Нәтиҗәдә, Вахитка башка авыллардан да кешеләр күченеп килә, яшьләр дә туган авылларында калу ягын карый. Ә нәрсә, эш бар, хезмәт хакы әйбәт, иң мөһиме – яшәргә торак бирәләр. Шул рәвешле Вахитта янә бер урам барлыкка килә.

2000 елда Вахитта урта мәктәп ачыла. Монысы инде йорттан белем бирү үзәгенә әйләнгән бина гына булмый, ә баштан ук мәктәп итеп төзелә. Авылда балалар саны арта, шуңа да яңа белем бирү үзәгенә ихтыяҗ туа.

Үзгәртеп кору чорында совхоз таркалмауда яңа җитәкченең өлеше зур була. Кама

Тамагының Бортас авылында туып-үскән Ринат Гатин Вахит өчен күп нәрсәләр эшли – мәчет салдыра, аннан урта мәктәп төзеттерә, асфальт түшәттерә. Нәтиҗәдә, Вахит, совхозның үзәге булып, бөтен тирә-як авылларны үзенә җәлеп итә. Ә урта мәктәпкә исә тирә-яктагы барлык татар авылларыннан килеп белем алалар. Районда бердәнбер татар телендә белем бирүче мәктәп була ул.

– Соң шулай гөрләп эшләп торган совхоз ник таркалды соң? – дим.

Җавапны мәдәният йорты җитәкчесе Гөлназ Фәттахова бирде:

– Районга «Кызыл Шәрык» оешмасы килде, бөтен җирләрне аларга бирделәр. Ринат абый 2020 елны һич көтмәгәндә арабыздан китеп барды. Үзе исән булса, бу турыда сезгә күбрәк сөйләр иде... РФнең атказанган агрономы иде ул. Урыны оҗмахта булсын, авыл кешеләре аны гел яхшы яктан гына искә ала.

КӘҖӘ МАЛ УЛ!

Вахит авылында татарлар гомер итә дидем. Баксаң, бер рус гаиләсе дә бар икән – Спиридоновлар. Владимир белән Светлана 2013 елдан бирле нәселле кәҗәләр асрый. Ир белән хатын унбиш ел элек Норильскидан күченеп кайткан. Вахиттан йорт сатып алып, фермерлык эшенә керешкәннәр. Спиридоновларның кәҗәләрен күреп шаккаттык: коңгырт, күксел төсләләр, озын колаклылар... Аларның хәтта мөгезләре дә юк.

1 – Совхоз авылга яңа сулыш өрде, – диде Сания Сәлимуллина.

2 Мәдәният йорты җитәкчесе Гөлназ Фәттахова.



– Бездә нәселле кәҗәләр – альп һәм нубия төрләре, – диде Светлана. – Башта без бу йорт хайваннары турында ныклап өйрәндек. Нәкъ шушы нәселләргә тукталганга, сөенеп бетә алмыйбыз.

– Тышкы кыяфәтләреннән башка, гади ак кәҗәләрдән кай ягы белән аерыла соң? – дим.

– Беренчедән, аларның сөте тәмле, иссез. Һәм сөтнең майлылыгы югары, дүрттән алты процентка кадәр җитә. Чагыштыру өчен, ак кәҗә сөтенең майлылыгы өч-дүрт процент була. Шулай ук әлеге нәселле кәҗәләрнең сөтендә аксым да күбрәк.

Владимир белән Светлана әле Норильскида чагында ук: «Татарстанга кайткач, кәҗәләр үрчетәбез», – дип үзара хәл итеп куялар.

– Авылда җир күп бит, шуңа да йортны моннан алырга уйлаштык, – диде гаилә башлыгы. – Шәһәрдә үскән бала буларак, Светлананың кәҗәне дә, сыерны да күргәне юк иде. Теләк көчле булса, максат чынга аша икән...

Ир белән хатын берьюлы өч кәҗә сатып алып кайта. Югыйсә берсе артыннан гына киләләр. Ә аннан... сакалбикәләрне күргәч, эреп китәләр.

– Бер кәҗәгә күңелсез булыр дип уйладык, – ди Светлана. – Шуңа да иптәшләрен дә алдык. Ә нәрсә, бер кәҗәне дә шулай карыйсың, өчне дә.

3

Спиридоновлар нәселле кәҗәләр асрый.

4

Владимир белән Светлана унбиш ел элек Норильскидан күченеп кайткан.



5

Авылда чишмә үзсалым акчасына төзекләндерелгән.

Хуш, кәҗәләр авылга кайтып җитә. Ләкин хуҗабикә аларны сава белми! Җиленне тартып карый, ә аннан сөт чыкмый. Шуннан сакалбикәләрне карарга күршеләр кереп җитә. (Ни дисәң дә авылда әле мондый озын колаклы, көрән төсле җан ияләрен күргәннәре юк бит!) Күрше хатыннары кәҗәләрне «әх» дигәнче савып бирә. Светлана тын да алмый бу хәлне күзәтә. Иртәгәсен исә чиләген тотып үзе чыгып утыра. Бер сәгать дигәндә бер кәҗәне савып бетерә...

– Шул чакларны искә төшерәм дә көлеп җибәрәм. Хәзер бер сәгать эчендә унар кәҗә савам, – ди Светлана.

– Бүген ничә кәҗәгез бар?

– Зурлары унбишләп. Әле алар хәзер берәмберәм бәти китерәчәк. Шуңа да бәтиләрне сатабыз. Быел бигрәк авыр – иген кыйммәт. Инде зур кәҗәләрнең дә баш санын киметергә уйлыйбыз. Дөресен әйтим, быел сакалбикәләр үз-үзен ашата алмый, өскә чыга.

– Саткан сөт азык бәясен дә капламыймы?

– Юк шул. Алдагы елларда каплый иде, быел печән, иген бәясен үзегез беләсез. Кәҗә сөтенә сорау зур түгел, күбрәк сыр ясыйбыз. Эремчек тә эшлибез. Сораучылар шактый. Шуңа күрә күбрәк сөт продуктлары ясыйбыз.

Спиридоновлар кәҗә бәтиләрен бөтен Россия буенча озаталар, хәтта Хабаровскига кадәр җибәргәннәр. Шулай ук БДБ илләренә, мәсәлән, Казахстанга да сатканнар.

– Тере кәҗәләрне меңәр чакрым ераклыкка ничек җибәрәсез? – дим.

– Самолет, поездлар белән.

–?!

– Әйе, тартмага салабыз да вагон җитәкчесенә яки стюардларга бирәбез. Бәтиләргә юлда ашатыр өчен сөт, салам да куябыз...

Светлана кәҗә сөтенең составын өйрәнгән. Алай гына да түгел, КФУ мөгаллимнәре белән кәҗә сөтенең ДНКсын тикшерүләрдә катнашкан.

– Кәҗә сөтенең файдалы үзлекләрен тирәнтен өйрәнәсем килә, – диде Светлана. – Мин һәр сакалбикәнең нәселе турында документ алып барам. Бәти кайчан туган, атасы, анасы кем, ничә литр сөт бирә. Хәтта саткан кәҗәләр турында да мәгълүмат туплыйм – шалтыратып белешәм...

«ЭШЛӘСӘҢ, БУЛА!»

Вахитта мал асраучылар гомергә күп саналган. Әлегә кадәр авылда көтү дә булган. Тик бүгенгесе көндә унсигез генә сыер калган. Көзен күпләр баш санын киметкән – иген, печән бәясе кыйммәт бит. Ә менә Миңнуллиннар гаиләсе, киресенчә, баш санын арттырырга ниятли. «Ничек кенә булса да, мөгезле эре терлек үз-үзен ашата ул», – диде гаилә башлыгы.

Рамил Миңнуллин үзмәшгуль статусы алган. Үзенең тракторы бар. Авыл җирлеге белән килешү төзеп, кышын юлларны кардан чистарта. Җәен исә авылдашларына җир эшләрендә ярдәм итә, печән, салам алып кайта.

Вахитта сөт җыймыйлар. Күрше авылларда өйләрен дача итеп тотучылар күп, шулар килеп ала икән. Үзләре дә илтеп бирәләр. Җәен сөт җитми дә, күрше Ташовка авылында чират торып алып бетерәләр.

– Бүген каралтыда җиде баш мөгезле эре терлек бар, – диде Рамил. – Сыер санын

арттырырга исәп, бер тана да калдырдык әле. Хатын эшкә киткәнче, аппарат белән сыерны савып китә. Ул күрше авылда хисапчы булып хезмәт итә. Мин исә, күбрәк авылда торгач, мал карау, бакча эшләрен үз өстемә алам.

– Иген, печән бәясе кыйммәт дип тормадыгыз алайса? – дим.

– Кыйммәт дип... Аның бит сөткә дә бәясе арта. Шулай булгач, ике исәп, бер хисап.

Техникасы булгач, Рамил «Кызыл Шәрык»-тан пай җирләрен дә алырга йөргән. Тик нияте тормышка ашмаган – документлар белән күп кыенлыклар килеп чыккан.

– Фермер булып эшләргә исәп бар үзе, – диде Рамил. – Җирең булып, игенне, печәнне үзең үстерсәң, күпкә файдалырак инде. Тик планнар барып чыкмады бит әле...

Күршедә генә Рамилнең әнисе – Динә апа Миңнуллина яши. Әби Вахит авылында туып-үскән. Тугыз дистәне ваклаган инде.

– Авыл оешкач та, эти белән әни бирегә килеп урнашкан, – дип сүзен башлады Динә апа. – Әти сугышка Вахиттан киткән. Шуннан әйләнеп кайтмаган да, мин аны белмим. «Сугышка чыгып киткәндә эти елый-елый сине итәгенә алып сөйде», – дип апам сөйли иде. Инде апа да дөньялыкта юк.

Динә апа башта колхозда, аннан совхозда сыер савучы булып эшләгән. Егерме биш ферма сыерын кул белән сауган буын алар. Җәмәгате белән алты бала – дүрт ул, ике кыз алып кайтканнар. Тик соңыннан туган игезәк кызларының берсе үлгән.

Динә апаның гомер иткән ире уналты ел элек дөнья куйган. Ләкин әби ялгызлыктан интекми, әйткәнемчә, күршедә улы белән килене яши. Казанда яшәүче балалары да атна саен кайтып йөри икән.

– Авылның иң гөрләп торган чагы туксанынчы елларга туры килде, – дип сөйләде Динә апа. – Совхозның оешуы авылны газлы, сулы, юллы да итте. Хәер, бүгенгесе тагын да матуррак – авыл шәһәргә әйләнде. Тик менә кешеләре генә картайды, ә яшьләр калмый.

Динә апа ике каенана, ике каената янына килен булып төшә. Каенанасы белән утыз еллап бергә яшиләр.

– Бик тату гомер иттек без, – ди әбекәй. – Балаларны каенанам үстерде. Без ирем белән гел эштә – фермада булдык. Ул заманда бит ферма эше яртышар көнгә сузыла иде. Совхоз зур, маллар күп. Барысы да кул хезмәте. Аннары гына ул саву аппаратлары чыга башлады.

– Без әбигә бик рәхмәтле, – дип сүзгә кушылды Рамил. – Тәрбия дә бирде, тамакны да кайгыртты. Әти белән әни өйгә ашарга гына кереп чыга иде – йә фермада алар, йә тышта, маллар янында. Без генә түгел, урамдагы һәр йортта диярлек шулай әбиләр оныкларын тәрбияләп үстерде. Урам тулы бала-чага иде.

– Ә үзегез әниегез белән яшәргә теләмәгәнсез, – дим, уенын-чынын кушып.

6

Күршедә генә Рамилнең әнисе – Динә апа Миңнуллина яши.

– Без башта бергә яшәдек үзе. Хәзер заман бүтән, мөмкинлекләр бар. Күршедә бер урын бушады да, хатын белән шунда заманча йорт салырга уйлаштык. Әнинең инде иялэнгән нигезе, һәр бүрәнәсе якын дигәндәй. Алай да көн дә әни янына керми калмыйм, туганнар да бик еш кайтып йөри.

...Төзек, матур авыл Вахит. Үзсалым акчасына юлларын, чишмәсен дә карап куйганнар. Авыл җирлеге башлыгы Фәрит Кәримов шул юнәлештә тагын эшләргә җыенуларын әйтте. Тик менә авылда мәктәп, балалар бакчасы ябылу гына бик кызганыч. Ә авыл кешеләре әле өметен җуймый – әнә, 1980 нче елларда совхоз оешкан да, авылга яңа сулыш өрелгән бит. Дәүләт тарафыннан тагын шундый берәр программа барлыкка килер дә, Вахит янә яшәрер, дип чын күңелдән ышана алар. Әбиләр әйтмешли, бирсен Ходай! Вахит белән бергә тагын бик күп татар авыллары да яшәрсен...

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН:

Сания Сәлимуллина, Вахит авылы китапханәчесе:

– Авылга 1919 елны Югары Осланның Мәмәтхуҗа авылыннан Фәйзрахман исемле кеше гаиләсе белән килеп утыра. Алар хатыны белән бу җирләр аша Казанга сәүдә эшләре белән йөри торган була. Бу әлеге урында кыр, болын җәйрәп ята. Икенче елны тагын өч гаилә килеп урнаша.

1924 елны Фәйзрахман абыйның беренче улы Хәбибрахман туа. Шуннан бер-бер артлы кызлар дөньяга килә – Сания, Суфия, Нурия. Бу гаилә бик уңган санала. Фәйзрахман абый умартачылык, терлекчелек белән шөгыльләнә. Аннан күрә башкалар да шулай көн итә. Нәтиҗәдә, авылның даны тирә-якка да тарала. Урыны да әйбәт – Казан юлында урнашкан.
Вахит исеме исә атаклы революционер Мулланур Вахитов хөрмәтенә куелган булырга тиеш. Һәрхәлдә, әби-бабайлар шулай сөйли иде.

ТОРМЫШ ТАНТАНАСЫ

«Бу сәнгать бер яктан затлы, зиннәтле, икенче яктан драматизм белән сугарылган», – сәнгать тарихы белгече Наталья Тележинская XVII гасыр Фландрия рәссамнарының иҗат җимешләренә әнә шундый бәя бирә. Тиздән казанлылар һәм шәһәр кунаклары Фландрия сәнгатенең иң күренекле вәкилләре – Рубенс, Ван Дейк, Йорданс, Кече Тенирс картиналарындагы җете купшылыкка һәм яктылыкка, «Җирдәге тормыш тантанасы» мохитенә чуму мөмкинлеген алачак.

Тиңсез күргәзмә «Эрмитаж-Казан» үзәгендә 23 февральдә ачыла. Анда Эрмитаж тупланмасыннан, төгәлрәге, аңа нигез салучы Екатерина II – Әби патшаның шәхси коллекциясеннән фландриялеләр һәм аларның замандашларының утыз картинасы тәкъдим ителәчәк.

Экспозициядә әлеге рәсем сәнгате җәүһәрләрен һәм башка мәшһүр картиналарны XVII гасырда Фландрия тормышында зур роль уйнаган басма графиканың бик югары дәрәҗәле әсәрләре, шулай ук Эрмитаж тупланмасыннан барокко чорына караган ике дистәдән артык төрле предмет тулыландыра. Бу әйберләр Рубенсның даһи иҗаты Фландриядәге гамәли сәнгатькә ничек йогынты ясаганын күрсәтә. Күргәзмә куратор экскурсияләре һәм балалар өчен кызыклы мәгълүмати чаралардан гыйбарәт «Казанда Эрмитаж көннәре» мәдәни-агарту программасы белән бергә үрелеп барачак.

1
Кече Давид Тенирс. «Крестьян туе».

2
Ян Фейт. «Чәчәкләр, җиләк-җимеш һәм тутый кош белән натюрморт»

23 ФЕВРАЛЬДӘН

«Эрмитаж-Казан» үзәге 6+

АФИША

МӘКТӘПНЕҢ ТИСКӘРЕ ЯГЫ

Спектакльнең беренче минутлары тамашачыларны ниндидер триллер мохитенә чумдыра. Ярымкараңгы залны прожекторның кызыл нурлары «кисеп» үтә. Сәхнәдә җиде зур, буш күн пиджак эленеп тора. Аларның эченә, тимер көбә кигән кебек, җиде хатын-кыз кереп баса. Караңгыда алар ниндидер мифик албастыларны хәтерләтә. Асылда, бу Казан мәктәпләреннән яшь укытучылар икән. МОҢ театр мәйданчыгындагы «Педсовет» спектакле – казанлылар театры проектының кала халкы катнашындагы тагын бер иҗат җимеше. Монда укытучылар үз башларыннан кичкәннәрне сөйли. «Педсовет»та күренешләрне бер-бер артлы күзәтә торгач, спектакльнең ни өчен шундый караңгы рухта башлануы аңлашыла бара. Замана мәктәбендәге хәлләр ата-аналар һәм укучылар өчен генә түгел, укытучылар өчен дә газаплы була ала. Әмма спектакльдә катнашучы яшьләр, үз һөнәреңне һәм балаларны яратуга нигезләнеп, күмәк көч белән бу вазгыятьне үзгәртергә мөмкин икәнлегенә ышана.

26 ФЕВРАЛЬ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге МОҢ театраль мәйданчыгы 12+

ЯЗ КИЛЕР ВАКЫТ!

Инде соңгы ае үтеп китәргә дә күп калмады – кыш тиздән тәмамланачак. Бу вакыйганы бик тәмле, күңелле һәм матур итеп Май чабу бәйрәмнәрендә билгеләп үтәргә мөмкин. Быел алар 28 февральдә башланып, 6 мартта тәмамланачак. Татарстанда, күнегелгән гадәт буенча, күңел ачулар берничә урында узачак. Иң күңелледәренннән берсе Зөя утрау-шәһәрендә көтелә. Биредә Май чабу бәйрәмен 6 мартта билгеләп үтәчәкләр.

Чәйле-коймаклы бәйрәмгә төрле тамашалар да өстәлә: тарихи реконструкция клубларыннан сугыш мизгелләре, халык уеннары, балалар һәм өлкәннәр өчен халык һөнәрләре буенча осталык дәресләре. Бу көннең төп тамашасы – үзешчән костюмнар һәм битлекләр конкурсында катнашучылар йөреше. Бәйрәм чаралары 16:00 сәгатьтә, Масленица карачкысын яндыруны да күздә тоткан театрлаштырылган тамаша белән тәмамланачак.

6 МАРТ

«Зөя утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы 0+

ХАКЫЙКАТЬКӘ – ҺИМАЛАЙЛАР АША

100 ел чамасы элек рус рәссамы, галим, мистик философ, язучы һәм сәяхәтче Николай Рерих хатыны һәм улы белән Индонезия, Цейлон, Кашмир, Кытай, Себер, Алтай, Монголия, Тибет тарафларына биш еллык сәяхәткә кузгала. Әлеге сәфәр – Үзәк Азия экспедициясенең максаты турында тикшеренүчеләр хәзергәчә бәхәсләшә. Рәссам бу территорияләрдәге халыкларның уртак мәдәни тамырларын эзләгәнме, буддизмны коммунизм белән бәйләп, «Махатма Ленин» проектын тормышка ашырырга теләгәнме, әллә ватаны файдасына разведка-күзәтү эше алып барганмы – фараз-фикерләр бик төрле. Шуңа да карамастан, сәяхәт нәтиҗәсендә берничә йөз картина туа, ике китап языла, бик күп этнографик материал туплана.

Рерихның искиткеч күләмле сәнгати һәм фәнни мирасын халыкка җиткерүдә тикшеренүче, язучы, Шәрык белгече Людмила Шапошникова зур роль уйный. 1970 нче елларда ул, кулына фотокамера тотып, ялгызы гына Алтай,

Монголия, Һиндстан, Һималай буйлап сәяхәткә китә һәм бөек рәссамның юлын тулысынча диярлек кабатлый.

Рерихның фантастик пейзажлары, шулай ук аның башка эшләре – барлыгы 70 картина һәм ярты гасыр соңрак үз сәяхәте барышында Людмила Шапошникова төшергән 120 фотосурәт Казандагы Заманча сәнгать галереясында тәкъдим ителә. Т

13 МАРТКА КАДӘР

Заманча сәнгать галереясы, Казан 6+

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясен күп еллар уңышлы җитәкләү өчен ныклы хуҗа булу гына аз. Биредә үзгә сыйфатлар кирәк! Сергей Аркадьевич Крайнов – нәтиҗәле идарәче генә түгел, ә нәкъ үзенә туры килгән урындагы шәхескә бер мисал да.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Сергей Аркадьевич!

Коллективыбыз һәм шәхсән үзем Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз! Сез республиканың торак-коммуналь хуҗалыгын үстерүгә чып-чын һәм әһәмиятле өлеш кертәсез. Сезгә хас компетентлык, югары һөнәри осталык һәм халык мәнфәгатенә тугрылык безне һәрвакыт сокландыра. Һәр көнегез оптимизм, яңа идеяләр һәм кызыклы очрашулар белән тулып торсын. Хезмәтегез Сезгә көч-куәт бирсен һәм яңа үрләр ачсын!

ПРИНЦИПИАЛЬ КЕШЕЛӘРНЕ ХӨРМӘТ ИТӘМ. БИК ТӨРЛЕ ВАЗЫЙФАЛАР БАШКАРГАН ХӘЛДӘ, ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ ҺӘРКЕМГӘ ДӘ ЯРЫЙ АЛМЫЙ. БУ ЭШ ДӨРЕСЛЕКНЕ ЭЗЛӘРГӘ ҺӘМ АНЫ ЯКЛАРГА КУРЫКМАУЧЫЛАР ӨЧЕН ГЕНӘ БАРА. СЕРГЕЙ КРАЙНОВ ТӨРЛЕ ЯКТАН ӨТЕП ТОРГАН УТЛАР АРАСЫННАН ИНДЕ УНӨЧ ЕЛ АЛГА БАРА!

Шикаятьләр, бәхәсләр, ызгышлар... Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгатьләр саны дистә меңнәр белән исәпләнә. Ведомство тарафыннан башкарыла торган тикшерүләр хисабы да шаккатарлык. Монда стратег та, тактик та, кайчагында килештерә белүче дә булырга кирәк. Сергей Аркадьевич җавапсыз идарәче компанияләр белән эшләүдә дә, коммуналь хезмәт күрсәтүчеләр белән уртак тел табуда да, хәтта җәмәгатьчелек активистлары белән сөйләшүләр алып барып, якларның килешүенә ирешкәндә дә осталыгын күп тапкырлар күрсәтте.

Кызганыч, бу вазыйфада хәл итәргә туры килә торган торак-коммуналь тармак мәсьәләләренең чишү юлларын эзләү хәтта эмоциональ яктан да җиңел түгел, чөнки һәр проблема кеше белән бәйле. Мондый эш җитәкчедән югары оешканлык һәм җаваплылык кына түгел, сизгерлек тә таләп итә. Синең кул астында күпфатирлы дистәләрчә мең йорт булганда, андый хис-тойгы күпме булырга тиештер! Казанда сөрем газы белән агулану очракларыннан соң, нәкъ менә Крайнов оешмасы ил күләмендә тәкъдим белән чыкты: Дәүләт Думасына яңа закон проектын кертергә! Бу канун газ приборларына техник хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнә торган оешмалар эшчәнлеген контрольдә тотуны җайга салырга тиеш. Закон чыгару инициативасы хокукына ия булмаган хәлдә дә, Татарстан торак инспекциясе шундый тәкъдимне күтәреп алды. Югыйсә, бу эштән читтә дә кала ала иде, әмма җитәкченең холкы андый түгел.

Хәл ителергә тиешле мәсьәләләрнең колачы ел саен зурая гына бара. Кайчандыр Дәүләт торак инспекциясенә торак йортларга капиталь ремонт ясауның сыйфатын контрольдә тоту һәм ТКХ өчен түләүләрне хисаплау, торак фонды белән идарә итү компанияләрен лицензияләү эшләре йөкләнде. Крайнов җитәкләгән оешма барысына да өлгерә. Илнең башка төбәкләрендәге коллегаларының Татарстан торак инспекциясенә охшарга тырышуы юкка гына түгел. Ә без – республиканың торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә аларның партнерлары – барлык бурыч-мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл иткән өчен рәхмәтебезне белдерәбез! Инде күп еллар бергә халык мәнфәгате сагында торабыз. Һәм Сергей Крайновның компаниябез эшчәнлеге белән якыннан таныш булуы аеруча сөендерә – аның хезмәт юлының берничә елы «Татэнерго»га багышланган иде.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КИЛӘСЕ САНЫНДА:

«Татарстан» журналының махсус проекты республиканың иң шәп улларын тәрбияләп үстергән яки үстереп ятучы иң күренекле әниләрне бергә җыя.

–БАШЫҢА КИ!

КҮРЕНЕКЛЕ ӘНИЛӘРНЕҢ ШӘП УЛЛАРЫ

– Бер кашыкны – әни, бер кашыкны әти өчен!

– Башыңа ки!

– Телисеңме-теләмисеңме – кем синнән сорап тора!

– Алдыңны-артыңны карап йөр!

– Еласаң да юк, еламасаң да юк!

Татарстанның танылган әниләре ана булу һәм сөекле җимешләренең ничек үсүе турында сөйли.

Ләйлә Сафина һәм аның улы Данат.

1 языл

2022 елның 21 гыйнварына кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от

электр иттарткыч, робот-пылесос, телевизор, кар көри торган җайланма. Төп бүләк — санаторийга 2 юллама

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 22.10.21 — 20.03.22 кадәр үткәрелә. Гаризалар 21.01.2022 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

сеть ювелирных салонов
ЭКСКЛЮЗИВ
Сезнең өчен кечкенә генә тылсым!
Теләсә кайсы зәвыкка туры килә торган гаҗәеп затлы зәркән эшләнмәләре бары тик бездә генә!
Салоннар адреслары:
Р. Зорге ур., 67, тел. (843) 268-94-95, факс (843) 268-25-24
Бутлеров ур., 29, тел. (843) 238-42-50
Восстание ур., 62, тел. (843) 564-77-67
Чистай ур., 16/15, тел. (843) 223-00-08, 223-00-09
Instagram: exclusive.kazan www.exclusive-jewelry.ru exclusive-kazan@yandex.ru
Сатуда шулай ук ТЕЛӘГӘН БӘЯДӘН БҮЛӘК СЕРТИФИКАТЛАРЫ бар.
«Эксклюзив» зәркән салоннары челтәрендә башка ювелир компанияләренең дисконт карталары да гамәлдә, шулай ук ПРОЦЕНТСЫЗ БҮЛЕП ТҮЛӘҮ* хезмәте дә күрсәтелә.
* Шнейдман А.М. Шәхси эшкуарлыгы тарафыннан бирелде. Реклама 12+